Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 18 (1434) 12 май 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga

1995 елның июленнән башлап чыга

8

Актанышның Байлар волосте вәкилләре нигезләгән Кормаш авылында башкорт катламы кайчан һәм ничек барлыкка килгән?

12

Рәссам Хәния Гәрәеваның чигеп ясалган чәчәкле, җиләкле картиналарыннан рухи җылылык бөркелә.



16

Татар халкын мәгърифәткә, яктылыкка илткән бик күп шәхесләрне авыр язмыш сынаулары көткән.

Җиңү һәрчак тылдан башланадыр
Ил ирεге өчен яуларда!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры актеры Фәнис Җиһаншага «Татарстан Республикасының халык артисты» исеме бирелде.

● Татарстан Милли музеенда «Байрак – Җиңү символы» дигән акция кысаларында Берлинны штурмлауда катнашкан 146 нчы укчы дивизиянең 280 нче артиллерия полкы байрагы халыкка күрсәтелде.

● Татарстанның халык артисты, режиссеры, Бөек Ватан сугышы ветераны Зәкия Туишевага Әлмәттә истәлек тактасы ачылды.

● Армия генералы Мәхмүт Гәрәевнең тууына 100 ел тулу уңаеннан чыгарылган истәлек медаленең беренчесе аның улы – генерал-майор Тимур Гәрәевкә тапшырылды.

● Мәскәүнең Берләшкән гуманитар нәшриятында Татарстан Язучылар берлегенең Әдәби тәрҗемә үзәге әзерләгән яңа китаплар – рус телендә Әхәт Гаффар һәм Надир Дәүләтнең әсәрләре басылып чыкты.

● Кол Шәриф мәчетендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы һиҗри календарь хисабы белән (3 май) Хәтер көненә багышланган утырыш үткәрде.

● Чаллы дәүләт педагогика университетында Алжир Халык Демократик Республикасы белән берлектә Гарәп теле һәм мәдәнияте үзәге ачу ниятләнә.

● Санкт-Петербургның Россия этнография музеенда «Файда» Татар мәдәни җәмгыяте «Туган авылым» дип исемләнгән бәйрәм оештырган.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Габдерәүф хәзрәт ЗӘБИРОВ, Казанның «Миргазиян» мәчете имам-хатыйбы:

«Истанбулда – Солтан Әхмәт мәчете бар. Солтан Сөләйман, Солтан Баязит мәчетләре... Бездә дә булсын – Олуг Мөхәммәд хан хәзрәтләре мәчете. Аның исеме яд ителер, халык килер. «Ә бу кемнең мәчете?» – «Олуг Мөхәммәд». – «Ә кем ул?» Һәм менә тарихка җанланырга бер сәбәп туа. Ә тарих ул – һәрбер милләтнең хатирәсе һәм милли тәҗрибәсе».

СЫНАМЫШЛАР

14 майда аяз булса, урак өстендә дә аяз көннәр фаразлана ● 15 майга каршы төндә сандугач сайраса, көн кояшлы булачак; бу көнне бодай һәм арыш чәчәләр ● 18 майда кәбестә үсентеләрен бакчага чыгарып утыртырга була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 39 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 42 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **16 сәгать 03 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **25 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **19 майда 16 сәгать 28 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

15 май – опера җырчысы, Татарстанның халык артисты Сәет Садыйк улы Рәинбәковка 75 яшь (1948);

– Әтнә театры артисты Фирдания Шәрипҗан кызы Хәйруллинага 70 яшь (1953);

– Халыкара гаилә көне.

16 май – Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Дамирә Нәҗмиҗан кызы Кузаеваның тууына 75 ел (1948–1993);

– актриса Татарстанның атказанган артисты Гөлнара Шәүкәт кызы Заһидуллинага 50 яшь (1973).

18 май – Халыкара музейлар көне.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Майның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(12-19 май)** организм кинәнүгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген шәүвәл аеның 22 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Рүзәл ЮСУПОВ

ГУМАНИТАР ҺӘЛАКӘТТӘН САКЛАНЫЙК

Без эшне, көчебезне мөмкин кадәр кимрәк сарыф итеп, тизрәк һәм җиңелрәк башкарып чыгарга күнегеп барган дәвердә яшибез. Бу күренеш тормышның төрле өлкәләрендә дә – җитештерүдә, акыл һәм сәнгать хезмәтләрендә дә чагылыш таба. Хуҗалыгыбызда ремонт яки төзү эшләрен «шабашниклар» бригадасының аннан-моннан гына, миннән киткәнче, иясенә җиткәнче, дип кенә эшләп куюларын күбебез белә. Мәктәптә һәм югары уку йортында белем һәм тәрбия бирүнең сыйфаты түбәнәю дә мәгълүм. Сәнгать, әдәбият өлкәләрендә дә проблемалар аз түгел. Халыкны борчыган мәсьәләләр укучыны дулкынландырырлык, тәэсирләндерерлек итеп язылган әсәрләрнең күзгә күренеп китүен сизми мөмкин түгел. Спектакльләрне фәкыйрь декорация белән яки бөтенләй декорациясез, ниндидер сәер шартлы сәхнә алымнары кулланып кую гадәтләрен дә, эстрада артистларының чын татар халык моңына нигезләнгән җырлардан йөз чөереп, җиңел башкарыла торган бик гади, моңсыз, такмак (компьютер) җырлары белән мавығу хәлләрен дә күреп торабыз. Татарча радио, телевидение тапшыруларын әзерләп эфирга чыгаруда да сыйфатка зыян китереп, эшне җиңеләйтү күренешләре күп.

Бүгенге көндә күңелне нык борчый, кәефне кыра торган тагын бер нәрсә: туган телебезне куллануда гафу ителмәслек битарафлык, җиңел караш хөкем сөрә. Татар теле соңгы елларда сан ягыннан да, сыйфаты мәсьәләсендә дә дәрәҗәсен югалта бара. Сан ягыннан дип әйткәндә, аны кулланган, белгән һәм өйрәнгән кешеләрнең азаюы күздә тотыла. Рәсми мәгълүматлар буенча, татарларның яртысыннан күбрәге үз телендә аралашмый. Татарстан башкаласындагы урамнарда, җәмәгать урыннарында татарча сөйләшкән кешеләрне очратып буламы? Казанда үзләренчә сөйләшкән азәрбайҗаннар татарча сөйләшкән татарлардан күбрәктер. Укучы балаларның өчтән береме, әллә дүрттән бере генәме күпмедер дәрәҗәдә татар телен өйрәнүгә җәлеп ителгән. Хәзер хәтта авыллардагы татар мәктәпләрендә укучылар да үзара күбрәк русча аралашырга омтыла.

Татарча газета-журналларны укучылар ничә процент кына икән?! Татар китаплары күпме сатыла?! Бик аз. Татарча газета-журналларның тиражлары 3-4 әр, 5-6 шар мең белән исәпләнә. Газета киоскларына татарча газеталары 2–3 әр, 4–5 данәләп кенә китерәләр. Күбрәк булса, сатылмый. Татарларның саны исә кимендә 5-6 миллион! Соңгы елларда татар мәктәпләренең аз дигәндә өчтән бере бетерелүен һәм рус мәктәпләрендә татар телен өйрәтүнең формаль рәвештә генә башкарылуын да белеп торырга кирәк.

Бу хәлләр телебезне куллануның сан ягыннан нык кимүен расласа, телебезнең ифрат дәрәҗәдә ялгыш, бозылып куллану күренешләренең көннән-көн артуы камил татар теленең сыйфаты түбәнәюен, табигый төзелеше бозыла баруын күрсәтә. Моны китап, газета-журнал укымый яки бик аз укый, татарча радио-телевидение тапшыруларын тыңламый һәм карамый яки сирәк кенә тыңлый-карый торган кешеләр сизмиләрдер дә, бәлки. Әмма элегрәк вакытлардан бирле татар әдәбиятын һәм матбугатын укып барырга күнеккән зыялы затлар телебезнең хәзерге күңелсез хәлгә төшә баруы турындагы бу фикер белән килешми калмас.

Бүген милләттәшләрнең күбесенең татарча сөйләмендә дә, газета-журналлар, телевидение-радио тапшырулары телендә дә, хәтта үрнәк телдә язылырга тиешле матур әдәбият телендә дә тупас ялгышлар күп. Алар берән-сәрән, сирәк-мирәк кенә очрап калмый, хилафлы сүзләр һәм формалар һәркайда һәм һәрчак кулланылып, күп тапкырлар кабатланып килеп, законлы, норматив рәвешкә керә бара. Гаҗәп хәл: кайсыдыр бер каләм иясе ниндидер ялгыш сүз һәм грамматик форма кулланса, аны каләмдәшләре, дөресме-юкмы икәнлеген тикшереп тормыйча, тиз арада шатланып дигәндәй күтәреп алып, дәррәү кулланырга керешә. Бу мәсьәләдә русларның «Дурной пример заразителен» дигән гыйбарәсе туры килеп тора.

Телебезне бозып, ялгыш куллану күренешләре аның барлык тармакларына да – лексика-фразеология, грамматика, стилистика өлкәләренә дә, орфоэпия һәм орфография нормаларына да кагыл. Бу мәсьәләдә шунысы аяныч һәм гаҗәпләндерә: кайбер сүз әһелләренә соңгы вакытларда телебезнең күп йөз еллар кулланылып килгән, тотрыклы кагыйдәләрен тупас бозу чире йога: көннәрдән бер көнне кинәт «ике икең – дүрт» дигәндәге кебек элементар сөйләм нормаларын бозып кулланырга керешәләр һәм зур ялгышларны башкалар да кабатлый башлый.

Телебезне газета-журнал материалларында, радио-телевидение тапшыруларында һәм шулай ук кайбер китапларда бозып куллану очракларын анализлау шуны күрсәтә: күп санлы хаталар каләм ияләренең татар телен тиешенчә белми торган, язмабызның башында әйтеп үткәнчә, эшләренә тиешле җаваплылык белән карамыйча, төптән уйламыйча, өстән-өстән генә, җиңелчә генә эш итүләре аркасында барлыкка килә. Алар үзләренең ни язганын, аны укучының аңлавы-аңламавын уйлап та тормый, кайчакта үзләре язган боткага үзләре дә төшенмиләрдер. Югыйсә, үтә мәгънәсез нәрсәләр язып куймаслар иде бит инде!

Хәзерге вакытта татар әдәби телен чүпләүгә, пычратуга гына түгел, хәтта аның табигый төзелешен, нигезен какшатуга китерә торган җитди ялгышлар да бар. Шундыйларның иң күп таралганы һәм аеруча хәтәре – сөйләмдә (текстта) сүзләрнең үзара мәгънәле бәйләнешен бозу һәм бу бәйләнешне тәэбир итү чараларын ялгыш куллану. Бу җитди тискәре күренешнең дә нигезендә, һәр телнең үзенә генә хас үзенчәлекләрен исәпкә алмыйча, рус телендәге сөйләм калыпларын, грамматик формаларын механик яки автоматик рәвештә татар теленә күчереп кую ята.

Рус теленең һәр сүзен татарчага ялгыш аның төп мәгънәсендәге тәңгәллеге белән тәрҗемә итү, калькалаштыру аркасында, рус сүзтезмәсе компонентларының мәгънә бәйләнеше өлгесен (семантик моделен) механик рәвештә татар теленә күчереп кую ысулы белән ясалган калька-әйтелмәләр соңгы елларда безнең телебезнең табигый төзелешенә зур зыян китерә: татар теле рус теленнән ялгыш калькалаштырып алынган чит-ят тәгъбирләр белән нык чүпләнә һәм бозыла. Мондый гайре табигый әйтелмәләр безнең телдә хәзер йөзләрчә һәм меңнәрчә исәпләнә. Татар телендәге матбугат һәм радио-телевидение тапшырулары телебезнең бай фигыль формаларын куллана белмәүләре аркасында да нык бозыла. Ялгышлар бигрәк тә үткән заман хикәя фигыльләреннән һәм сыйфат фигыльләрдән файдалану өлкәсендә бик күп. Алар турында бу язма авторының мәкаләләрендә һәм китапларында күп һәм тулы итеп язылган.

Радио-телевидение, ягъни эфир теле турында да берничә сүз әйтик. Матбугатта һәм китапларда күрсәтелгән тел ялгышларының күбесе эфир тапшыруларына да хас. Шуның белән бергә радио һәм телевидение тапшыруларының үзләренә генә була торган тел хилафлыклары да бар.

Телевидениедә һәм радиода, татарча тапшыруларда катнашучылардан татар телендә дөрес, матур итеп, иркен сөйләүче һәм әңгәмә ясаучылар аз һәм, киресенчә, кирәксезгә рус сүзләре кушып, ык-мык килеп, тиешле фикерне тиз генә белдерерлек сүзләрне таба алмыйча һәм татар теленең үзенә генә хас авазларны дөрес әйтә алмыйча сөйләүчеләр күп. Авазларны әйтү димәктән, радио-телевидениедә генә түгел, гомумән, татарча сөйләүчеләрдә бер оялырлык күренеш бар: милләттәшләребезнең бик күбесе һ авазын дөрес кулланмый, аны х авазы белән алмаштырып, һәмне хәм яки хам дип, шәхәр (шәһәр), хәрбер (һәрбер), хәммә (һәммә), хава (һава) h.б дип әйтә.

(Дәвамы 4 нче биттә).

ЮЛНЫ ЮЛДАГЫЛАР ҮТӘР

Урталык җирләрендә һәм ислам дәүләтләрендә илаһи яңарыш турында сүз барганда, иң элек хак динебезнең тәүхиди-иҗтиһади асылын ислам метафизикасы (Мәңгелек һәм тәҗрибә ителә алмый торган илаһи башлангычларның даимилеген таный торган фәлсәфи тәгълимат) югарылыгында аңлау вә аңлату, шул нигездә инде яшәү рәвешен дә үзгәртү күздә тотыла. Андый үзгәреш моңа кадәр төрле мәзһәбләр арасында ясалма рәвештә (йола дәрәҗәсендә) яшәп килгән каршылыкларның акыл вә ихтыяр көче белән отыры юк ителүенә дә китерәчәк. Нәтиҗәдә, хак дин тарафдарлары (Аллаһ юлындагылар) Җирдә илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүнең ныклы нигезен тәшкил итәчәк һәм глобаль метасәясәти борылыш өчен дә уңай шартлар вә бәрәкәтле җирлек булдырачак. Ә мондый күпкырлы әзерлек чаралары инде иҗтимагый аң дәрәҗәсендәге рухи үсеш һәм Җирдәге хаятны илаһи нигездә үзгәртү кебек глобаль дәрәҗәдәге мөһим поблемаларны эволюцион юл белән хәл итү мөмкинлеге бирә.

Мәгълүм булганча, Урталык җирләрендә дөньякүләм диннәрнең (беренче чиратта ислам һәм православиенең) уртак геосәяси шартларда мең елдан артык янәшә яшәү тарихы бар. Ул тарих төрле битләрдән тора, чөнки мөшриклек диннәре, геосәясәт коралы да буларак, үзара бәйлелектә иңдерелгән һәм сәяси максатларга да хезмәт иткән (һәм бүген дә хезмәт итәләр). Әмма бүген инде Җирдә илаһият кануннарына нигезләнгән яңа дөньяви тәртип урнаштыру вакыты да җитте. Димәк, дөнья тотучылар мәнфәгатьләренә хезмәт иткән һәм хәзер глобаль кризис та кичерә торган геосәясәткә алмашка, метасәясәт (илаһи кануннар буенча яшәүгә күчү сәясәте) килергә тиеш була. Ә алар арасында төп аерма шундадыр ки, беренчесендә диннәр сәясәт коралы да булып хезмәт итсә, икенчесендә инде, киресенчә, сәяси алымнар Җирдә илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү ниятенә хезмәт итәчәк.

Аңлашыла булыр, хәзер алгы планга, үзеннән-үзе, Урталык җирләрендә ислам-нәсара мөнәсәбәтләренең бүгенгесе һәм киләчәгенә кагылышлы мәсьәләләр дә чыга. Рәсми даирәләр аны тигез итеп күрсәтергә тырышса да, нәсара динендәгеләрнең Мәскәүдә һәм кайбер башка җирләрдә мәчетләр төзелешенә каршы чыгуы (гәрчә бу эштә зур диспропорция сакланса да!) ул мөнәсәбәтләрнең әлегә катлаулы булып калуын күрсәтә. Әлбәттә, мондый хәл гасырлар дәвамында илдә үткәрелгән бөекдержавачыл шовинизм рухындагы сәясәт белән дә бәйле. Шуңа күрә, бу мөнәсәбәтләрне илаһи нигездә җайга салу бүген мөһим бурычлардан санала. Ә Илаһыбыз бер һәм бердәнбер, димәк, Аның кануннары барлык диндәгеләр өчен дә уртак. Бүген бу инде барлык конфессияләр өчен дә аңлаешлы хакыйкать һәм ул илаһият юлында глобальләшүнең рухи асылын тәшкил итә. Әмма аны төрле диндәгеләргә һәм гади халыкка үтемле, гади, шул ук вакытта заманча да итеп аңлату җитми. Әлбәттә, бу инде руханилардан да югары әзерлекле булуларын таләп итә. Илаһи миссияле кавем буларак, зур җаваплылык татар милләтенә дә төшә. Ә бер үк милләттә бу җирлектәге ике төп дин тарафдарларының да булуы – аның илаһи миссияле кавем булуына янә бер дәлил. Шуңа күрә, ошбу изге эшләрдә үзенчәлекле һәм мөһим рольне керәшен кардәшләребез дә башкара алыр иде.

Бүгенге глобаль кризиска метасәяси караш милләттән үз миссиясен үтәүдә булган бөтен резервларның нәтиҗәле кулланылуын да таләп итә. Андыйлар рәтенә дин кардәшләребезне, шулай ук тел уртаклыгы сакланган тугандаш төрки халыкларны да кертергә була. Әлбәттә, Урталык җирләрендә һәм ислам дәүләтләрендә илаһи яңарыш мәсьәләсендә мөһим рольне Татарстан һәм Башкортстан кебек милли республикалар да башкара алыр иде. Татарстанда, әйтик, моның өчен мөмкинлекләр тарихи яктан да, метасәяси планда да җитәрлек һәм хәтта символлар дәрәҗәсендә дә хәл ителгән: Изге Болгар җирендә урнашкан Ак мәчет Урталык җирләрендә ислам яңарышы символы булып хезмәт итсә, Иске Аракчино бистәсендә төзелгән «Бөтен галәм гыйбадәтханәсе» исә төрле диннәр һәм мәдәниятләрнең гармонияле яшәүдәге мигъмари символы рәвешендә төзелгән һәм диннәр вә цивилизацияләр арасында гармониягә ирешү символы булып хезмәт итә. Татарстанда ислам югары уку йортлары һәм мәдрәсәләр дә җитәрлек. Дөрес, кайчандыр мәдрәсәләрне җәдитчелек яңарткан кебек, бүген аларда хак динебезнең тәүхиди-иҗтиһади асылын һәм илаһият нигезләрен дә яңача укытуга күчү лязем. Ә ислам дөньясында да илаһи яңарышка ирешүдә Татарстанда һәр елны үтә торган «Изге Болгар җыены», «Россия – Исламский мир: KazanForum» дигән икътисад форумы, татар дин әһелләренең «Милли үзенчәлек һәм дин» дигән XIII Бөтенроссия форумы кебек чаралар да үз ролен уйный алыр иде.

Фоат УРАЗАЙ.

Сөембикә ханымга 103 яшь

Язучысы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның бертуганының кызы, күренекле абыйсы белән аралашкан, хәзерге вакытта Ташкентта яшәүче Сөембикә Шәрипова 103 яшьлеген билгеләп үтте. Ташкент шәһәренең татар иҗтимагый оешмасы вәкилләре аны шушы истәлекле дата, шулай ук Җиңү көне белән тәбрик итте.

Сөембикә Шәрипова сугыш вакытында хәрби госпитальләрдә табиб булган, аннары район сәламәтлек саклау системасында хезмәт куйган. Гаяз Исхакыйны әзәрлекләү шартларында аның гаиләсе Ташкентка күченгән була.

«Сөембикә ханымны Җиңү бәйрәме һәм туган көне белән котлаулары бик куанычлы хәл. Коллегаларыбызга – бер ветеранны да игътибардан читтә калдырмаучы татар иҗтимагый оешмасы вәкилләренә тиешле бәя бирергә кирәк», – дип искәртте төрки халыкларның традицион мәдәниятен өйрәнүче Рәмзия Кашапова. Аның сүзләренчә, С.Шәрипова үзен яхшы хис итә, яшьлеген әйбәт хәтерли. Тормышын искә алганда, ул сугыш елларында көнне төнгә ялгап эшләвен әйтә һәм хәрби госпитальләрдә яралыларга ярдәм күрсәтүе хакында сөйли. Сугыштан соң Сөембикә Шәрипова 58 ел Үзбәкстан сәламәтлек саклау системасында эшләгән, шул исәптән күп еллар туберкулез диспансерының баш табибе булган.

Данлы журналистны искә алдылар

Башкортстанның Чакмагыш районының Аблай авыл китапханәсендә эшләп килгән «Ахирәтләр» клубы катнашында изге рухиятле, матур-матур кичәләр, әдәби очрашулар үтеп тора. «Җыр булып кайтты ул Аблаена» исемле әдәби кунакханә чарасы язучы, шагыйрь, дистәгә якын китап авторы, «Чакмагыш чаткылары»на нигез салучы, журналист Әгъдәл Низаевның якты иҗади мирасына багышланды. Якташыбыз бар гомерен районның «Игенче» газетасына, туган ягы халкына багышлады. Халыкны борчыган, иң четерекле темаларны яктыртты, көн үзәгендәге материаллары, кайнар репортажлары белән дан казанды.

Алып баручы, китапханәче Айсылу Сираева әдипнең тормыш юлы, аның иҗаты белән таныштырды. Китапларыннан һәм иллюстратив материалларыннан торган күргәзмә тәкъдим итте.

Әдәбият сөючеләргә СССР һәм Башкортстанның Журналистлар берлекләре әгъзасы, Вәзих Исхаков исемендәге әдәби премия лауреаты Әгъдәл Әхмәтсафа улының Аблай авылы, район өчен кылган изгелекләре, заманында 5 ел Аблай авыл китапханәсен һәм мәдәният учагын җитәкләгәне хакында да бәян ителде.

Әдәби кунакханә кысаларындагы очрашу барышында «Ахирәтләр» клубының нәфис сүз осталары Ә. Низаевның шигырьләрен укыдылар, әсәрләре буенча фикер алыштылар.

Юлай САФИН.

Яд итү мәрасиме

Казанда татар җәмәгатьчелеге Яңа Татар зиратында артист, режиссер Габдулла Кариев каберенә чәчәкләр салды. Искә алу чарасында Г.Кариев театры коллективы, Г.Камал, К.Тинчурин театрлары артистлары, язучылар, җәмәгать эшлеклеләре катнашты.

Мәрасимне Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрит Мифтахов алып барды. Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты ректоры Роза Әхмәдиева Г. Кариевның эшчәнлеге зур кыйммәткә ия булуын әйтте: «Ул татар театры, профессиональ режиссурага нигез сала, образларны психологик яктан тирән гәүдәләндерә».

Кариев театры директоры Луиза Янсуар татар театрына нигез салган шәхесне хөрмәтләп искә алучы яшьләр булуына сөенүен белдерде. «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге мәдрәсә җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин һәм аның шәкертләре Г.Кариев рухына Коръән укып, дога кылды.

Г.Кариевның тууына 137 ел тулуга багышланган чаралар Норлат районында дәвам итте.

Энже ГАБДУЛЛИНА

Әлмәндәр бабайның кайтуы

Бу көннәрдә «Татармультфильм» оешмасы яңа иҗат җимеше белән сөендерде – «Әлдермештән Әлмәндәр» дип аталган тулы метражлы анимация фильмын тамашачыга тәкъдим иттеләр. Мультфильм шул исемдәге пьеса мотивлары буенча төшерелгән, тик спектакльне тулысынча кабатламый. Премьера «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле 30 елдан артык уйналган Камал театрында күрсәтелде.

Мультфильм олылар өчен дип билгеләнсә дә, гаилә белән рәхәтләнеп карарлык булып чыккан. Әлеге әсәр буенча мультфильм эшләү идеясе 10 ел элек үк туган. Төшерү эшләре бер елга сузылган. Төп персонажларны актерлар Равил Шәрәфи, Эмиль Талипов, Илнур Закиров тавышландырган. Фильмны төшерүчеләр спектакльдә булган фәлсәфи кыйммәтләрне сакларга тырыштык, диләр. Мультфильм комик элементларга бик бай. Фильмдагы Әлмәндәр бабайга – йөз яшь, ул без күнеккән кебек үк шат күңелле, җор телле бабай. Мультфильмда «Ала карга» җыры төп лейтмотив булып бара, яңа җырлар да язылган.

Яңа мультфильм республикабыз президенты ярдәме белән төшерелгән, «Татнефть» оешмасы да химаялек кылган. Фильмны рус һәм башка чит телләргә дә тәрҗемә итәргә ниятлиләр. «Әлдермештән Әлмәндәр»не төшерүчеләр аны прокатка чыгарырга тырышуларын хәбәр итте. Яңа мультфильм үз тамашачысына барып ирешер һәм балаларның да, олыларның да күңелләренә хуш килер, шәт.

Эльмира СИРАҖИ.

1 нче биттә – «Казан – хезмәт батырлыгы шәһәре» стеласы һәм аны ачу тантанасы күренеше. Фото: rais.tatarstan.ru

Батырга һәйкәл куелды

Татарстанның Мөслим районы Бүләк авылында туып-үскән Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов бюстын ачтылар. Ул Бөек Ватан сугышының беренче елында ук герой исеменә лаек була һәм Ленин ордены, ә 1943 елда «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.

Сугыштан соң Маннанов сәүдә техникумын тәмамлый, Чаллы сәүдә учреждениеләрендә эшли. Хатыны Җәмилә белән бер ул һәм бер кыз тәрбияләп үстерә. Өлкән яшьтәге пенсионер булуга карамастан, күп кенә иҗтимагый чараларда актив катнаша. Советлар Союзы Герое 89 яшендә вафат була, ул Чаллыда җирләнгән.

Бюстны ачу тантанасында район җитәкчелеге, ветераннар, яшь солдатлар, авылдашлар һәм Маннановның туганнан туган сеңлесе Альбина Әбүбакирова катнашты.

Мөслим районы башлыгы Альберт Хуҗин сәламләү чыгышында бюстны урнаштыруга ярдәм итүчеләргә рәхмәт белдерде.

Илдар Маннановның сеңлесе тантанада абыйсының яхшы күңелле, ярдәмчел кеше, Ватанының чын патриоты булуы һәм аның исемендәге мәктәп отрядларының эше турында сөйләде.

Татар яшьләре фикер алышты

Татар яшьләре Ульяновскиның Татар мәдәният үзәгенә төбәкара форумга җыелды. Өлкә татар милли-мәдәни автономиясе, Татар мәдәният үзәге һәм Ульяновск татар яшьләр оешмасы тарафыннан үткәрелгән форумда өлкә районнарыннан вәкилләр, шулай ук Казан һәм Оренбург шәһәрләреннән кунаклар катнашты. Фойеда татар мәдәниятенә багышланган күргәзмәләр һәм Идел буе халыкларының тарихы буенча өстәл уеннары оештырылган иде.

Милләт җанлы егетләр һәм кызларны Ульяновск өлкәсенең яшьләр үсеше министры Артем Мирошников, өлкәнең милли мәдәниятләрне яңарту һәм үстерү үзәге җитәкчесе Светлана Ковшенина, өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Рәмис Сафин һәм Казанның «Идел» яшьләр үзәге директоры Зөлфия Ибләминова сәламләде. Алар Ульяновск татар яшьләренең соңгы вакытта активлык күрсәтүен билгеләп үтте һәм истәлекле бүләкләр тапшырды.

Милләт язмышына битараф булмаган яшьләр үзләренең чыгышларында төбәктә милләтара тынычлык һәм татулыкны саклап калу, татар телен һәм мәдәниятен, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне киләчәк буыннарга тапшыру кирәклеге турында сөйләде.

Рәшит Ваһапов айлыгы

Тууына 115 ел тулу уңаеннан, Казанда профессиональ татар эстрадасына нигез салучы бөек җырчы Рәшит Ваһапов һәйкәленә чәчәкләр салу тантанасы узды. Чарада мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы вәкилләре, күренекле сәнгать әһелләре катнашты. Алар арасында – шагыйрь Ренат Харис, актер Ринат Тажетдин, профессор Фоат Галимуллин, җырчылар Зөһрә Шәрифуллина, Мирсәет Сөнгатуллин һ.б. бар иде.

Казан кунаклары катнашында Р.Ваһапов юбилеена багышланган бәйрәм аның туган ягында – Нижгар өлкәсенең Актүк авылында булды. 16 май көнне 13:30 сәгатьтә Казанда Рәшит Ваһапов һәйкәле янында митинг-концерт узачак. Тантанада Ваһапов фестивале лауреатлары Азат Абитов, Гөлсирин Абдуллина, Рәнис Габбазов, Алмас Хөсәенов, Рөстәм Асаев, Руслан Сәйфетдинов һ.б. чыгыш ясаячак. Программада шулай ук 2023 елгы Яшь башкаручылар конкурсы лауреатларын игълан итү дә каралган.

Исмәгыйль хәзрәт укулары

Башкортстанның Октябрьский шәһәре Нарыш бистәсе мәчетендә «Башкортстан Республикасы авыл җирлегендә мөселман мәхәлләсе үсеше: тарихы, гореф-гадәтләре һәм киләчәге» темасына I төбәкара Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин (1893-1975) укулары оештырылды. Җыен 1950-1970 елларда Нарыш бистәсендә имамлык иткән Исмәгыйль хәзрәтнең тууына 130 ел тулуга багышланды.

Сәлимшин укуларын Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте, Бөтендөнья татар конгрессы, Россия мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе, Башкортстанның Октябрьский шәһәре, Миякә, Бишбүләк һәм Ярмәкәй районнары мөхтәсибәте, «Нуруль-Ислам» мәдрәсәсе, Бөтенроссия татар авыллары ассоциациясе, Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты һәм Нарыш бистәсе мәчете үткәрде.

Укуларда татар авылының йөзен, гаилә гореф-гадәтләрен саклау, нәсел шәҗәрәсен төзү һәм авылда мөселман мәхәлләсен үстерү, хәйриячелек эшчәнлеген җәелдерү мәсьәләләре күтәрелде. Татарстаннан гына түгел, Самара өлкәсеннән дә кунаклар килде. Җыенда күренекле дин әһелләре, галимнәр, журналистлар, җәмәгать эшлеклеләре Мәүлемҗан хәзрәт Сибгатуллин, Нияз хәзрәт Сабиров, Рамил-Габдулла хәзрәт Кәримов, Айдар Шаһимәрданов, Фәйзелхак Ислаев, Эльмира Сәләхова, Резедә Сафиуллина-Ибраһимова, Ленар Гобәйдуллин, Фәнир Галимов һәм башкалар чыгыш ясады.

Уңышлы кияүгә чыгыйм дисәң...

Диния нәзарәтенең мөселман яшьләре арасында зур популярлык казанган проектларның берсе – «Яшь килен» курслары яңадан үз эшен башлап җибәрде. Әлеге проект 8 нче тапкыр тормышка ашырыла, монысында дистанцион форматны сайлаганнар. Бу исә курсларда катнашучыларның географиясен киңәйтергә мөмкинлек биргән. Бу юлы проектта Казан, Мәскәү һәм Уфа, Чиләбе һәм Самара, шулай ук Дубай, Татарстанның шәһәр-районнарыннан, Башкортстаннан, Мәскәү, Оренбург өлкәләреннән, Казахстаннан 70 мөслимә катнаша.

Киленнәр мәктәбе Аллаһ Тәгалә кануннары буенча бәхетле гаилә корырга һәм гаилә учагын саклап калырга теләүчеләр – 17 яшьтән өлкәнрәк, кияүдә булмаган, ярәшелгән мөслимәләр һәм кызларын кияүгә бирергә җыенган әниләр өчен оештырыла. Белем бирү курслары Коръән, сөннәт һәм ислам дин галимнәренең гыйлемнәренә нигезләнгән.

Мөслимәләрне биредә тирән белемле танылган остазлар һәм шәехләрдән никахта ир-хатынның бурычлары һәм хокуклары, мәһер, никахлашу өчен хәерле ир сайлау, яшь гаиләдә проблемалар, балалар тәрбияләү, никахта җенси мөнәсәбәтләр һ.б. турында тәфсилле лекцияләр көтә. Кызлар никах, үз хокуклары һәм бурычлары турында хакыйкый гыйлемнәр алачак һәм ир сайлаганда төптән уйланган карарлар кабул итәргә өйрәнәчәк.

Дөньяның теләсә кайсы почмагыннан кушылырга мөмкин булган онлайн-курс телеграм челтәрендә алып барыла. Дәресләр сишәмбе көнне 19:30 сәгатьтә башлана – нәкъ шушы вакытта остаз, курсны оештыручылар һәм катнашучылар туры эфирга чыга. Мөслимәләр шулай ук эмоциональ интеллект һәм көнкүрешне сөннәткә нигезләнеп алып бару буенча марафоннарда катнашачак.

Көзен исә проект үз эшен гадәти формата дәвам итәчәк.

Эльмира СИРАҖИ.

● Европа илләрендәге айлык минималь хезмәт хакы күләме шаккатыра. Быел гыйнвар аенда ул Люксембургта 2387 евро, Германиядә – 1981, Ирландиядә – 1910, Франциядә – 1709, Бельгиядә – 1955, Нидерландта – 1934, Словениядә – 1304, Литвада – 840, Грециядә – 832, Польшада – 746, Эстониядә – 725, Чехиядә – 717, Хорватия белән Словакиядә – 700, Латвиядә – 620, Венгриядә 579 евро тәшкил иткән. Россиядә исә минималь хезмәт хакы күләме 180 еврога тәңгәл.

● Yle басмасы хәбәр итүенчә, быелтыр Финляндиядә уртача пенсия күләме 1845 евро тәшкил иткән: ир-атларныкы – аена уртача 2070, хатын-кызларныкы – уртача 1685 еврога тәңгәл. Россиядә быелның 1 гыйнварыннан уртача пенсия күләме 21 864 сум (242,5 евро чамасы) тәшкил итә, бу фин пенсионерыныкыннан 7,6 тапкырга азрак.

ГУМАНИТАР ҺӘЛАКӘТТӘН САКЛАНЫЙК

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Мондый сөйләүчеләрне тыңлау ямьсез тәэсир калдыра һәм шундый сорау туа: ни өчен хәтта руслар немец теленең яки башка чит телләрнең рус телендә булмаган, мәсәлән, шул ук һ авазын дөрес итеп әйтергә өйрәнә алалар, ә безнең татарлар үз телләрендәге авазларны да җиренә җиткереп әйтә алмый? Хурланырлык хәл бит!

Бүген татар теленең кулланылышы өлкәсендә проблемалар бик күп. Мәсәлән, топонимика исемнәренең язылышында һәм әйтелешендә тәртипсезлек бар. Гомумән, сүзләрнең язылуында һәм тыныш билгеләрен куюда, ягъни орфографиясе һәм пунктуациясе мәсьәләсендә башбаштаклык күренешләре хөкем сөрә. Терминнар куллануда да хәл итәсе мәсьәләләр күп.

Йомгак ясап әйткәндә, татар телен белү, куллану, укыту-өйрәтү эше белән кызыксынып, аны тикшереп торырга, бу өлкәдәге проблемаларны хәл итү белән максатчан һәм җитди шөгыльләнергә тиешле дәүләт органнарының, җаваплы кешеләрнең булуы сизелми. Тагын да хәтәррәге: халыкның үзенең дә күбесендә туган телебездән мәхрүм калуыбыз ихтималы бар дип нык борчылу, үз телен сакларга омтылыш күренми.

Татар теле хәзер үги бала хәлендә. Аның дәүләт теле булырга тиешле роле көннән-көн кими, дәрәҗәсе түбәнәя бара. Моннан соң да шушы хәл дәвам итсә, мең еллык тарихлы, камил төзелешле татар әдәби теле, үзенең әһәмиятен, куәтен югалтып, кухняда, базарда аралашу чарасы гына булып калырга мөмкин. Бу исә татарларның югары культуралы, алдынгы милләт буларак яшәвен гуманитар һәлакәткә китерәчәк.

Татарстан Фәннәр Академиясендә ике көн дәвамында Гаяз Исхакыйның тууына 145 ел тулуга багышланган «Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, гамәл» дигән темага халыкара фәнни-гамәли семинар узды. Аның эшендә Азәрбайҗан, Казахстан, Кыргызстан, Төркия, шулай ук Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Новосибирск, Уфа, Чаллы, Чабаксар, Ижау, Алабуга һ.б. шәһәрләрдән галимнәр катнашты. Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган семинар «Гаяз Исхакый һәм XX-XXI гасырлар татар дөньясы» дигән темага утырыш белән ачылды.

ИСХАКЫЙ БЕРЛӘШЕРГӘ ЧАКЫРА

Гаяз Исхакый – язучы, сәясәтче, татар милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе, төрки халыкларның һәм аеруча үз милләтенең киләчәге өчен эзлекле көрәш алып барган, шуны яшәешенең максаты итеп куйган шәхесләребезнең иң күренеклесе. Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты, тәнкыйтьче Дания Заһидуллина Г.Исхакыйның «Таң йолдызы» газетасында милләттәшләренә: «Берләшегез дә берләшеп тартышыгыз, чөнки тартышуда гына табарсыз үз хакыгызны», – дип эндәшүен искәртеп үтте. «1906 елда ул үз фикерләрен лозунг итеп белдерә. Әдип тормышының соңгы көннәренә кадәр туган халкының иминлеге һәм бәхете өчен көрәшә, әлеге идея ярдәмендә бүлгәләнгән татарны берләштерергә, бер йодрык, бер агым итеп алгарыш мәйданына чыгарырга мөмкин дип саный», – дип аңлатты галимә. Әдип бу идеяне тормышка ашыру өчен публицистик мәкаләләр яза, газеталар нәшер итә, төрле очрашуларда чыгышлар ясый.

Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитет җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Данис Шакиров да Исхакыйның шәхес кенә түгел, ә бәлки мирасы, тормышы, иҗаты белән дә үзен милләткә багышлаган милләт каһарманы булуын искәртте. «Һәр әсәре, мәкаләсе, милли горурлык чыганагы булып тора», – диде ул. Бөек Тукаебызның Исхакыйга багышланган «Кем ул?» әсәрендә үзенең соравына болай дип җавап бирә: «Ул – милләтебезне уяткан, күтәргән кеше, ул – безне телле иткән, караңгыдан яктыга чыгарган кеше; ул – инкыйразның, ягъни бетүнең нәрсә икәнен аңлаткан кеше», дип әйтүен искә төшерде: «Тукай бик төгәл һәм дөрес итеп әйтә белгән. Шушы бер җөмлә белән ул әдипнең бөтен асылын күз алдына китереп бастыра». Ирексездән татар әдәбиятында Исхакыйның әдәби байлыгыннан мәхрүм ителгән еллар күз алдына килә. Бер яктан, аның кебек милләтпәрвәрләргә җитмеш елдан артык тарихыбызда, әдәбиятыбызда урын булмавына җан әрнесә, икенчедән, шул әдәби мирастан мәхрүм халкыбызның күпме байлык югалтуын яхшы аңлыйсың. Д. Шакиров «Көндәлекләр»нең аерым басма булараk чыгуын да уңай бәяләде, аларның фәнни эзләнүләрдә кулланылыш табачагына ышаныч белдерде.

Язучылар берлеге исеменнән Татарстан халык шагыйре Рәдиф Гаташ чыгыш ясады. Ул Исхакыйның поэзиягә, шагыйрьләрне үстерүгә, бигрәк тә Г.Тукай иҗатына зур әһәмият бирүенә игътибар юнәлтте, хатларында Тукайны Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиевләрдән дә өстенрәк итеп, аны, безнең милли шагыйребез дигән карашта торуын, Тукайны Төркиядә язган мәкаләләрендә дә, Петербургта да, чит илгә чыгып киткәч тә, милләтне күтәрүче ул – Тукай дигән позициядән баруын әйтте.

Профессор Хатыйп Миңнегулов Исхакыйның шушындый мәйданга килүе очраклы хәл булмавын, халкыбызның 1000 елдан артык әдәбият тарихы, язма мирас тарихы булуы турында сөйләде. Хәзер аның һәрбер чорында аңа өлеш керткән шәхесләребез, иң әүвәл гомумтөрки әдәбиятта Йосыф Баласагуни, Әхмәт Ясәви, Сөләйман Бакыргани кебек шәхесләребез янына шушы гасыр башында бөек Кол Гали барлыкка килә. «Аны гомумтөрки генә түгел, асыл татар әдәбияты вәкиле дип карыйбыз», – диде ул. Бу – татарның халык булараk формалашкан, милли әдәбиятын шәхесне, халыкны дөньяга таныткан Алтын Урда чоры. Анда фән, мәдәният та үсә, шәһәр тормышы да алга китә. Галим Алтын Урда чорының һаман күләгәдә калуын, Болгар белән күбрәк мавыгып китүебезне дә искәртте. «Болгар – безнең бер генә өлешебез. Әстерхан да, Татарстан да – татар халкы яшәгән җирләрнең бер генә өлеше. Башкортстанда, Чиләбедә, Самарада яшәгән татар диаспорасы, дип язалар. Алай түгел, алар – татарның тарихи җирләре. Шуннан бөек әдипләребез Котб, Хисам Кятиб, Сәиф Сараи һ.б. чыккан. Татар халкының дәүләтчелеге булган XVI йөзнең урталарына кадәр Алтын Урда зур үсешкә ирешә, аннан соң колониаль чор башлана. Халкыбызның бер өлеше руслаша, рухи байлыгы тарала. Шуңа карамастан, татарның тарихи җепләрен саклап калган әби-бабаларыбызга, ислам диненә рәхмәтле булырга тиешбез. Соңрак чорда Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Габделҗәббар Кандалый, Шәмсетдин Зәки һ.б. иҗат итә. Иҗатлары – халкыбызның авыр шартларда яшәвенең бер билгесе. XIX гасырда инде халкыбызның тарихы, мирасы белән кызыксынуы арта. Моның үзгендә Ш.Мәрҗани, К.Насыйри һәм Х.Фәезханов кебек галимнәребез тора. Шул чорда драматургия, реалистик рухтагы әсәрләребез барлыкка килә. Заһир Бигиев, Муса Акъегетзадә иҗат итә. Менә шундый рухта әдәбиятка Гаяз Исхакый килеп керә. Хатыйп ага әдипнең иҗат иткән вакытын да бутап әйтүебезгә игътибарны юнәлтте: «XIX йөз ахыры, XX йөз башында гына иҗат иткән, күренекле урын алган, дибез. Алай түгел. Исхакый әдәбиятка XIX гасырның ахырында килә, XX гасырның 30-40 нчы елларында дәвам итә». Совет чорында миллилекне бетерү төп сәясәткә әйләнә, күп кенә зыялыларыбызны, милләтчелектә гаепләп, юкка чыгаралар. Мөһаҗирлектәге Исхакый һ.б. шәхесләребез милли традицияләрне дәвам иттерә. XIX гасырның ахырында милли хәрәкәт көчәйгән икән, монда Исхакыйларның роле зур булды. Галим аның гаярь табигатьле, тырыш кеше булуын искә алды. 1990 елларда Хатыйп агага өч ай дәвамында Финляндиядә эшлекле сәфәрдә булырга туры килә, шул чакта милләттәшләребез белән очраша. Алар арасында Исхакый белән аралашып калучылар да була. «Гаяз абыйны тыңлау үзе бер тамаша булып истә калды. Ул сөйләгәндә, авызына гына карап тота иде» – дип сөйли торган булалар. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» – Г.Исхакыйның үзәк әсәре. Ул анда татар җәмгатьчелегенең авыруларын күрсәтә. Шул ук вакытта әдип күпкырлы эшчәнлеге, әдәби иҗатында милләтебезнең гореф-гадәтләрен, йолаларын теркәп калдыруы белән дә халыкка хезмәт итә. Галим Исхакыйны киң даирәдә билгеләп үтү кирәклеген дә ассызыклады. «Язучылар берлеге, Мәдәният министрлыгы инициативасы белән Исхакыйга багышланган зур кичә оештырырга кирәк иде», – диде ул. Хатыйп ага Исхакыйның Чистай районы Яуширмә авылындагы музее хакында да әйтеп узды: «Ул 1993 елда ачылган зурлап ачылган музей баштагы елларда шаулап эшли. Әмма соңгы елларда хәтер йорты авыр хәлдә калды. Бөек затларыбыз туган, яшәп алган урыннар күп түгел. Ә Яушырмә бетә бара. 100 дән артык кына бала бар. Мәктәп беттеме, авыл да юкка чыгачак». Х.Миңнегулов истәлекле авылларны саклау өчен махсус программа кирәген, аларның район җитәкчелеге карамагында булырга тиешлеген басым ясап әйтте: «Авылларны яшәтү өчен, эш белән тәэмин итү сорала. Исхакый – бер генә, авылны һәм музейны туристик маршрутка кертергә кирәк. Без Исхакый мирасын файдаланыйк, милләтебезне бүгенге авыр хәленнән чыгарыйк».

Исхакыйның эшчәнлеге һәм иҗаты, Япониядәге тормышы, төрки дөнья белән бәйләнеше, милли телләрне, мәдәниятләрне, әдәбиятларны өйрәнү методологиясе һ.б. темаларга чыгышлар ясалды. Моннан тыш җыенда язучының «Гаяз Исхакый. Көндәлекләр. 1 китап (1919-1920)» һәм «Гаяз Исхакый. Милли куәтләр бардыр» җыентыклары да тәкъдим ителде. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының татар белемен чагыштырма тикшеренүләр лабораториясе мөдире, доцент Марсель Ибраһимов «Милли куәтләр бардыр» дигән китапка язучының әдәбият, сәнгать, мәдәниятка караган хезмәтләре керүе турында сөйләде. Алар төрле темаларга язылган. Әйтик, гарәп һәм латин алфавиты мәсьәләренә багышланган мәкаләсе кызыксыну белән укыла. Гаяз ага аны мөһаҗирлек чорында язган. Шунда ул төрки татарларга гарәп алфавитын саклап калырга кирәклеген белдерә, чөнки зур мирасыбызны югалту ихтималын әйтә. Бу җыентыкта шулай ук Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Й.Акчура, И.Гаспралы, Г.Тукай кебек татар лидерларына багышланган мәкаләләр дә урын алган. Ул аларның татар мәдәниятендә һәм тарихындагы ролен кат-кат күрсәтә. Китапта Исхакыйның татар әдәбиятының башка халыклар һәм рус әдәбияты белән мөнәсәбәтләре турындагы хезмәтләре бар. Ул «Толстойның татар әдәбиятына тәэсире» дигән мәкаләсендә үзенең, бу рус язучысының әсәрләренә югары бәя бирсә дә, толстойча булмавы, аның дөньяга карашын кабул итә алмавы турында яза. Ул рус язучыларыннан Иван Тургенев, Антон Чехов, Николай Гогольне үзенә иң якын язучылар, дип белдерә.

Семинарның икенче көнендә «Мәдәниятара чикләр: проблемалар һәм тикшеренү методлары» темасына түгәрәк өстәл утырышы үтте. Аны филология фәннәре кандидаты М.Ибраһимов һәм филология фәннәре докторы, «Казан фәнни үзәге»нең күп факторлы гуманитар анализ һәм когнитив филология лабораториясе җитәкчесе А.Арзамазов алып барды.

Сөембикә КАШАПОВА.

Әтнә театрында ярымтатарча тамаша

Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театры үзе өчен көтелмәгән спектакль чыгарды – театрның кече залында Ярослава Пулиновичның «Наташаның хыялы» спектакле куелды.

«Наташаның хыялы» әсәрен «Пушкин картасы» белән күрсәтеп, Әтнә театры яшьләр тарафыннан «крутой театр» дигән бәяне горурлык белән күтәреп йөриячәк әле – залда яшьләрнең игътибар белән каравыннан шундый нәтиҗә ясарга мөмкин. Бәлки, заманча драматургияле театр фестивальләрендә дә балкыр – мондый караңгы әсәрләрне яратучылар бар һәм байтак.

* * *

«Наташаның хыялы» – 2008 елда язылган һәм 15 ел эчендә байтак театрларда, нигездә яшьләр театрларында куелган, ике монологтан торган сәхнә әсәре. Әтнә театрында аның бер өлеше генә – ягъни беренче яртысы куелган.

Әтнә театры репертуарында «Наташаның хыялы» спектакле барлыкка килүнең алтарихы бар. Театр җыелышларының берсендә, чираттагы «мозговой штурм» вакытында, маркетинг буенча директор урынбасары, шагыйрә Гөлүсә Батталова театрда яшь режиссерлар өчен мәйдан бирү тәкъдиме белән чыккан. Әлбәттә, ул Казан дәүләт мәдәният институтын күздә тоткандыр инде. Ә театр директоры Ленур Зәйнуллин «арттырып җибәргән» – театрның бу хыялын, танылган театр белгече Олег Лоевский Татарстанга килгәндә, аңа әйткән, әйтеп кенә дә калмаган, Олег Соломоновичны Әтнәгә алып кайтып, театрны күрсәткән. Лоевский исә, ГИТИС белән килешеп, Әтнә театрын ГИТИС өчен диплом спектакльләре мәйданчыгы итеп тә куйган. Хәзер елга бер мәртәбә режиссер, сценограф һәм хореографтан торган ГИТИС студентлары командасы биредә спектакль куячак.

Быел ГИТИС Әтнәгә Олег Кудряшов остаханәсендә белем алучы Ичэнь Люны, Евгений Каменькович һәм Дмитрий Крымов остаханәсендә белем алучы рәссам-сценограф Мартын Степановны һәм Владимир Кириллов остаханәсендә укучы хореограф Елизавета Матвиевичны юллаган. Яшьләр кыска гына вакыт эчендә спектакль чыгарган.

Спектакльдә театрның яшь артистлары Лиана Каюмова, Гөлия Гыйлэҗева, Зөһрә Хөсәенова, Алсу Зыятдинова, Зөһрә Хәмәтгалиева һәм Фаяз Хөсәенов катнаша. Театрның яшь артисты Лиана Каюмова өчен дә менә дигән презентация булды бу спектакль. Шәп актриса чыгачак бу кыздан!

* * *

«Наташаның хыялы» – балалар йортында үскән кызның үз гамәлләре өчен җавап бирүе, аклануы. Тамашачы алдында – мәхәббәт һәм шаһзадә турындагы хыяллары, өметләре белән тулы кыз бала һәм шушы хыяллар мизгел эчендә чәлпәрәмә килә. Алга таба ул үзен саклап кала алырмы, әллә кырыс дөнья тегермәне аны иләп, тузан итәрме?

Кыскача эчтәлеге болай. Наташа исемле кыз балалар йортында яши. Ул, бәхәсләшеп, өченче каттан сикерә. Хастаханәдә дәваланганда, аның янына журналист егет килә. «Синең хыялың нинди?» – дип сораган егет кыз бала өчен шаһзадәгә әверелә. Әмма журналист өчен кыз бала бары тик авыр язмышлы мәкалә герое гына була... Тамаша хэппи-энд белән тәмамланмый, дөресрәге берничек тә тәмамланмый.

Беренче сорау: ни өчен Әтнә театры шушы әсәргә алынган? 30 елдан артык районны җитәкләгән Габделәхәт Хәкимов тузан бөртеге дә кундырмый саклаган биләмәләр – Әтнә районы өчен спектакльдә тасвирланган вакыйгалар ят булып тоелды. Икенче сорау: гомер-гомергә Тукайлы һәм театрлы булган яклардан без азмы-күпме әдәби тел көтәбез. Әлбәттә, Әтнә яшьләре дә, бергә җыелганда, Әмирхан Еники, Марсель Галиев әсәрләрендәге тел белән сөйләшмиләрдер – аңлыйбыз. Әмма Әтнә театрының бренды шундый инде – матур тел һәм тәртипле балалар.

Ичэнь Лю: «Театр заманча әсәр сорады. Вакыт тә аз иде. Шуңа да шушы кыска әсәрне сайладым. Әсәр миңа кеше тарихы буларак кына таныш – мәхәббәт, өмет һәм кыенлыклар, ә балалар йорты тәртипләрен белмим. Дөрес күз алдына китергәнмендер, дип өметләнәм. Төп рольне башкарган актриса балалар йорты турында күп сөйләде, чөнки әнисе шунда эшли икән».

Наташа ролен башкарган Лиана Каюмова: «Әйе, бездә приют бар. Минем әнием шунда эшләде. Тәрбиячеләргә бит көндез дә, төнлә дә эшләргә туры килә иде. Мин әни белән төнгә дә баргаладым. Шул балалар белән уйнап, дус булып үстем. Ул балалар безнең белән бергә мәктәптә дә укыды. Мәктәптә балалар йортындагыларга кимсетеп, түбәнсетеп карау булмады. Алар бездә 16 яшькәчә яшиләр дә, аннары училищега керәләр иде. Ул балалар үзләре дөрес юл сайларга теләсәләр, аларга мөмкинлек булды. Әтнә театрында пьеса бик йомшак вариантта сәхнәләштерелде. Пьесаның үзендә – барысы да күпкә кырысрак».

Тел мәсьәләсенә килгәндә, бу пьесаның проблемалары сәхнәләштергән команда килгәнче үк башланган. Театрның тәрҗемә эшләрен яратып башкара торган үз актеры – Татарстанның атказанган артисты Марат Хәбибуллин бу эштән баш тарткан. Театр тәрҗемә һәм инсценировка эшләрен профессиональ башкаручы, Татарстанның атказанган артисты Илтөзәр Мөхәммәтгалиевка да чыгып караган, шагыйрә Йолдыз Миңнуллинадан да сорап караган – алынучы булмаган. Шулай итеп, бу эш театрның үз шагыйрәсе Гөлүсә Батталова өстенә өелеп калган. Гөлүсә тәрҗемә иткән итүен, татарның халык телендә булган чын татарча сүзләренә кадәр эзләп тапкан, ди. Әмма без сәхнәдән Гөлүсә тәрҗемәсен ишетмәдек, диярлек. Артистлар рус теле нык катышкан бүгенге яшьләр телен сайлаган. Кыскасы, татар әдәби «урам теле» белән «гопниклар теле» бергә болгатылып, җитмәсә, татар сүзләре рус теле грамматикасы буенча ботарланып, «винегрет тел» барлыкка килгән.

«Нәрсә булганын сөйләргәме? Тагын нәрсә? Менә бу җиремне дә төреп бирмимме? Сүгенмим мин. Нормаль сүз бу!» «Мин черки һәм Танькаңың арт санынан башка бүтән бернәрсә дә күрмәдем». «Лёханы жәлләдем. Ну чё, аңа кызык дип беләсезме әллә?» «Ә кайда мин тагам ул заколканы? Мин уйладым, что аны егетләр белән йөрергә чыкканда тагачакмын. Ә пока минем егетем юк, ятсын шунда! Конечно, минем егетем бар иде, без аның белән бөтен бухаловоларда бергә идек». «Ә слабо сикерергә? Ты чё, дура? Кайда сикерергә? Третий этаж». «Чё, лохушка какая-то?» «Это мин аңа могу үземнең бөтен хыялларым турында сөйләргә... Ә ул башка бер сүз дә әйтмәде. Әйтте, что мин тереләдем. Терелгәч, газета артыннан редакциягә килдем». «Коза прыщавая булса да, ул минем бик яхшы дус кызым иде».

Спектакль 45-50 минут чамасы барды. Әтнә театрының Кече залына чакырылган яшьләр, сәхнәдәге артистларны үзләрен генә калдырып, телефон дөньясына «китеп бармадылар», азаккача Наташа янәшәсендә калдылар – аның белән бергә Наташа яшәгән кырыс дөньяны күзәттеләр.

Тормышның караңгы ягын күрсәткән мондый спектакльләрне карарга теләмәү – страус кебек башны комга тыгу, әлбәттә. Әтнәлеләр тәрҗемәсендәгечә, «арт сан», барыбер, күренеп калачак.

Сәхнәдәге телнең колакны авырттыруы да – тамашачы проблемасыдыр. Безнең милли «урам теле» юк лабаса, яшьләребез, яхшымы бу, начармы, үз туган телендә сүгенми, кыйнашканда, туган телендә кычкырмый. Димәк, Әтнә театры гына татарча «урам теле» барлыкка китермәс бит инде.

Ә сез ничек уйлыйсыз – безнең саф татарча урам теле булырга тиешме? Әллә рус телен генә файдаланып торыйкмы?

Рузилә МӨХӘММӘТОВА

intertat.tatar

Ялгыз җилкән аксыллана Зәңгәр диңгез томанында...

Михаил ЛЕРМОНТОВ

КӨЗ

Яфраклар да саргайдылар,
Тынып калды чыр-чулар;
Моңсу яшеллеккә чумды
Урмандагы чыршылар.
Кыялар арасындагы
Чәчәкләр сулган төштә
Сукачы да ял итәргә
Яратмый инде һич тә.
Батыр җанвар ирексездән
Качар өчен җай эзли.
Төнлә тонык ай басуны
Томан аша көмешли.

1828

ЧИРКӘС КЫЗЫ

Сезне күрдем: үр, басулар,
Куаклар, тауда үскән,
Кыргый дөнья матурлыгын –
Көләч йөзләргә күчкән;
Киң далада тын гадилек
Һич тә чыгалмый истән.

Чиркәс кызы... Терек аккан
Урында күрдем аны, –
Күз карашы әсир итте,
Әйләндерде дөньяны;
Кыяларда йөрү уе
Юкка чыкты, уяның.

Җәннәт тавышын ишетеп,
Тәүбәле җаным бара –
Күк матурлыгын күрергә
Оча серле дөньяга –
Сөю, дәрт, газап тавышы
Хәтердә гел яңара.

1829

ДУСЛАРЫМА

Җаным кызу булып туган,
Дусларымны яратам,
Кайвакытта шешә белән
Вакыт үткәреп ятам.

Көчле данга һәвәслек юк,
Җанны сөю җылыта,
Лираның моңлы тавышы
Кан дулкынынннан тота.

Еш кына күңел ачканда,
Газаплар моңсулата,
Каты махмыр шау-шуында
Йөрәгем уйга бата.

1829

ГРУЗИНОВКА

Сиңа әйтәм, и ягымлы дустым,
Минем өчен шундый мәзәк син,
Илһам чыганагын яратасың,
Алар өчен хәтта үз-үзеңне
Корбан итәсең бит... гаҗәп син!..
Юкка гына мәкерлеләр белән
Юк ла, дустым, бергә йөргәнең! –
Хатын-кызлар болай да бит – илһам,
Ә рәхмәтле булган хатын-кызны
Бармы синең берәр күргәнең?..

1829

* * *

Гүзәллегең белән җәлеп итмә!
Рухым сүнде инде, чаларды.
Күпме еллар, үзгә караш булып,
Акылыма тирән эз салды!..
Онытылмас бу минутлар өчен,
Мин ваз кичтем матур дөньядан;
Ләкин хәзер хәерче сир кебек,
Чит зат сыман җирдә уянам!
Әгәр юлчы төннең карасында
Адашкан бер утка юлыкса,
Ул артыннан чаба... тотып ала...
Аста – тайгак упкын, тын кыса!..

1829

ҖЫР

Узган көннәрнең өрәге,
Әйт, ни өчен
Йоклаган дәрт, мәшәкатьнең
Бүлдең төшен?
Син тиз узар дәрт, теләкне
Сеңдерәсең!
Каян табыйм бәхет, гамьне –
Хет берәрсен?..
Кайда дуслык анты, гайрәт,
Уйлар төпле?
Еллар чоңгылы юк итте
Рәхәтлекне!..
Яшь булсам да, яңакларым
Тоныкланды;
Йөрәктә күралмау, суык
Урын алды!

1829

СУГЫШ

Дусларым, сугыш башланды;
Күктә – намус байрагы;
Кан үче алырга дәшеп,
Изге быргы сайрады!
Гафу, шау-шулы мәҗлесләр,
Җанга моң сибәр көйләр,
Вакхның зур бүләкләре,
Изге Русь, чибәркәйләр!
Онытырмын сине, сөю...
Мәшәкать, яшьлек шуннан...
Ирекле булып очармын
Мәңгелек дан артыннан!

1829

РӘХМӘТЛЕМЕН!

Рәхмәт ясусын!.. кичә сөю сүзен,
Шигыремне тыныч кабул иттең;
Аңламадың тик асылын хиснең,
Ялган игътибарың булды түзем –
Рәхмәтлемен!

*

Синең барлык һәрчак әсир итте;
Гаҗәп караш белән үткен сүзең
Күңелемдә мәңге калыр минем,
Ләкин, зинһар, әйтмә инде, җитте:
Рәхмәтлемен!

*

Яшь көенчә һич тә калмас идем
Гамьле колларыңның төркемендә,
Зәһәр шелтә урынына бер дә
Мин бу сүзне генә алмас идем:
Рәхмәтлемен!

*

Салкынлыгың карашында яшәр
Һәм юк итәр өмет-хыялларны,
Йөрәгемдә чыккан янгыннарны;
Шул вакытта җаным сиңа дәшәр:
Рәхмәтлемен!

1830

АХМАК ГҮЗӘЛГӘ

1

«Шәрабымны эчәсеңме?..» –
Диеп Амур сорау атты.
Бик теләгем булмаса да,
Мин савытны тиз бушаттым.

2

Хәзер телим чылатырга
Иренемне, ялкын алган,
Чөнки дәртнең дым кәсәсе
Башың кебек бушап калган.

1830

* * *

Димәк, сау бул! Тәүге тапкыр шушы аваз
Күңелемә каты хафа, борчу сала.
Сау бул! Алты хәреф күпме газап бирә,
Мин яраткан бар нәрсәдән бушлык кала.
Аның гүзәл күзләре – җан ярасында,
Соң мәртәбә күрәм... бәлки... карашын да!

1830

САУБУЛЛАШУ

Гафу, гафу!
Күпме газап
Китерала
Бу сүз азак.
Сизәм синдә
Серле ымны –
Тәмуг, оҗмах,
Хыялымны
Чакырасың
Алыс якка.
Синең кулың
Бик еракта
Иренемнән.
Мин ялварам:
Бер мизгелгә
Кил яныма,
Күкрәгемә
Тының өреп,
Сөю утын
Кабат терелт.
Мин биредә
Чирле килеш,
Ялгызлыкмы
Минем өлеш?
Үзем генә
Ятимлектә,
Сагыш белән
Хакимлектә.
Бу халәтне
Кичәрменме?
Сине көтәм –
Исәрменме?
Сине кысып
Иренемә,
Үләр идем
Бүген менә,
Язмышыма
Бер үч итеп.
Мохтаҗлыктан
Булмый китеп.
Болай булгач,
Хәтер аксын –
Саубуллашу
Ишек каксын!

1830

* * *

Өметсезлек рухы сыман
Җанны кысып кочакладың;
О! ни өчен соң син аны
Бөтенләй үк, йә, алмадың?

Җаным сиңа мәңгелек храм;
Анда бары синең сурәт;
Күктән түгел, бары аннан
Котылуны көтә йөрәк.

1831

ҖИЛКӘН

Ялгыз җилкән аксыллана
Зәңгәр диңгез томанында. –
Нәрсә эзли ерак илдә?
Туган җирнең тын ягында?

Дулкын уйный, җил сызгыра,
Мачта сыгыла һәм шартлый.
Юк! Ул бәхет тә эзләми,
Бәхеттән дә качып ятмый! –

Аның өсте – зәңгәр киңлек,
Аста кояш нуры ага;
Ул, тынгысыз, давыл сорый,
Гүя шунда тынгы таба.

1832

* * *

Хуш, исән бул, юынмаган Рәсәй,
Түрәләр һәм коллар дәүләте,
Сау булыгыз, зәңгәр мундирлылар,
Гади халык, күндәм гадәтле.

Пашаңнардан Кавказ арьягында
Качып котылырмын, мөгаен,
Күпне күргән күздән, күп ишеткән
Колаклардан инде, Ходаем.

1840

ГӨТЕДАН

Тау өсләре йоклый сыман
Төнге караңгылыкта;
Үзәннәр дә күмелгәннәр
Тылсымлы бер тынлыкка.

Юлда да тузан күренми,
Селкенми һичбер яфрак.
Чак кына көт, озакламый
Ял алырсың син азрак.

1840

Ленар ШӘЕХ тәрҗемәләре.

Мәдәни җомга
12 май
№18, 2023

Кормаш – элекке Бүләр волосте җирләрендә барлыкка килгән иң өлкән авылларның берсе. Волость үзе бүгенге Татарстанның – Актаныш, Минзәлә, Мөслим һәм Башкортстанның Бакалы белән Илеш районнары мәйданына җәелгән була. Волость 1620 елларда ук тарихи документларга керә. Әүвәл авылларны татар белән мари крестьяннары тәшкил итә, 1798 елда Оренбург губернасы кантоннарга бүленгәч, бүләрлеләрнең зур өлеше Башкорт-мишәр гаскәре составына кертелә. Әмма 1855 елда әлеге гаскәрне фәкать «башкортныкы» гына дип атау һәм аның составындагы татар, типтәр, мишәрләрне «башкорт» катламына күчереп кую, ахыр чиктә 1863 елда «Башкорт гаскәрен тарату» турында фәрманнар дөнья күргәч, җир волостьлары үзләренең элекке әһәмиятен югалта. Бүләр волостен да юкка чыгарып, әлеге мәйданны Байсар, Пучы, Әмәкәй волостьлары арасында бүлгәлиләр.

АКТАНЫШТАГЫ КОРМАШ

Кормаш авылы барлыкка килүнең төгәл датасы юк, әмма аны Байлар волосте күчмәннәре нигезләү – бәхәссез. Алары Кормаш урынына XVII гасыр башында күчеп килгән. Моны 1808 елның 27 ноябре белән тамгаланган документ дәлилли. Кормаштагы типтәрләр ышанычлысы булган Габделбәшир Монасыйпов власть ияләренә Бүләр волосте җирләренә башкорт вотчинникларына бернинди дә оброк түләмичә, ерак бабалары булдырган саклау грамоталары нигезендә 200 ел чамасы элек үк килеп төпләнүләре һәм генераль межалау үткәргәннән соң, казнага башкортлар белән бер үк күләмдә сусар тиресе белән ясак түләп барулары турында бәян итә. Әлеге хатирә кормашлыларның Бүләр волосте җирләренә «бобыль» сыйфатында килеп төпләнүе һәм вотчинникларга буйсынмыйча гомер итүен исбатлый. Алар бераздан Уфа приказлар ызбасыннан җирләрен саклау грамоталары алуга да ирешә. Димәк, типтәр Г.Монасыйповның бабалары Бүләр җирендә әүвәл бобыль сыйфатында төпләнгән, ә аннары башкорт вотчинниклары белән бер үк төрле «сусар ясагы» түләп яшәгәннәре өчен, тора-бара «башкорт катламы»на да күчеп куйган. «Башкорт катламы» XVIII гасыр башына кадәр нәкъ менә бобыльлар хисабына тулыланып торган.

Бобыль – Россия дәүләтендә XV-XVIII гасырларда япа-ялгыз көенчә, дәүләт алдында кое казу, күпер салу, юл төзү кебек бернинди бурычларга да тартылмыйча, хәтта абзарында ат та тотмыйча гомер иткән крестьян ул. XVII гасыр башында алар Уфа өязе җирләренә дә бер рөхсәтсез килеп утырган, аларны баерак күршеләре «әтәмби» дип тә атап йөрткән. Атсыз крестьян булганга, аларны юл салу, күпер төзү эшләренә дә җәлеп итмәгәннәр. Ләкин җанисәп үткәрелә башлагач, мондый «әтәмби»ләргә дә салым җиткерергә кирәк бит, менә шуңа күрә алар үзләре хуҗа булып алган җир өчен «бобыль ясагына» тартылган. Хуҗалыгы вотчинникларга буйсынмыйча, аларга бернинди салым да түләмичә, үзбаш көе генә алып барган. Тора-бара алар вотчинниклар талавыннан азат булу өчен, җирләрен саклау-яклау грамоталары да алуга ирешкән. Кормаштагы «бобыль-әтәмбиләр» мондый грамоталарны 1701 елда ук алган. Андый грамоталар казнага вотчинниклар дәрәҗәсендә ясак түләп баручы җир хуҗаларына да бирелгән. Менә шул сәбәпле, тора-бара, бобыльларга «башкорт» катламына күчү дә җиңелрәк булган. Күп очракта тулы бер татар авыллары да «башкорт» катламына күчеп куйган.

1747 елгы реформа буенча, бобыльларны «типтәр» дип аталган катлам белән берләштергәннәр, ә дәүләт кәгазьләрендә моннан ары бобыльлар да типтәр, дип кенә атала башлаган. Гәрчә типтәрләр – алар вотчинниклар рөхсәте белән аларның биләмәләренә яшәргә кертелгән һәм шуның өчен аларга ел саен салым түләп баручы крестьяннар бит. Менә шушы аерма 1762 елгы җанисәптә чиновникларны типтәр белән бобыльларны аерым-аерым теркәргә мәҗбүр иткән. Нәкъ шул чорда мариларны да шушы типтәр-бобыль катламында хисапка кертә башлаганнар.

Шул вакытта кормашлылар авылларга бүлеп бирелгән җирләрнең чикләрен межалау өчен килгән чиновник Лисицинга да үзләренең канәгатьсезлеген белдерә.



Кормашлылар монда соңгы тапкыр ясаклы татарлар дип теркәлгән. 1762 елгы ревизия язмасы. РГАДА, ф. 350, оп. 2, д. 3801, л. 523.

Курмаш Тангатаров һәм башка татарлар телгә алынган килешүнең беренче бите. НА РБ, ф. И-172, оп. 2, д. 20, л. 77.



Айтуган Сабаков һәм Байсар Козяшев исемнәре искә алынган документның бер өлеше. РГАДА, ф. 1173, оп. 1, д. 468, л. 14.

Бу вакытта, нәкъ кормашлылар шикелле үк, күршедәге Карач авылы типтәрләре дә үзләренең җир хуҗасы, ягъни «башкорт» булуларын раслап буза куптара. Чөнки Йәнәй волостеның Камбарка түбәсеннән (йорт, аймак) килеп, Байлар белән Бүләр волостьларын чикләп торган Шәбез елгасы буенда үз утарларын булдырган карачлылар да казнага башкортлар белән бер күләмдәге бобыль ясагын түләп барган була. Алар Үзләрен «җир хуҗасы – вотчинник», дип түгел, бәлки «типтәр» катламына язып куюы белән ризалашмый. Үзләрен аклау өчен, алар бабалары 1723 елдан 1747 елга кадәр сусар ясагы түләп барган квитанцияләрен чыгарып сала һәм үзләрен «типтәр» түгел, ә «башкорт» дип теркәп куюларын таләп итә. Формаль яктан – ясак түләү тәртибе буенча нәтиҗә ясаганда алар, чыннан да, хаклы була. Ә инде бабалары 1701 елда ук алуга ирешкән «саклау-яклау грамоталарын» да чыгарып салгач, үзләрен «башкорт» катламына күчереп куюларына өмет баглый.

Җ да чиновниклар каршына бабаларының 1691 елдан башлап 1745 елга кадәр сусар тиресе белән ясак түләп баруларын раслаучы квитанцияләр чыгарып сала. Бүләр волостеның тагын берничә авылында яшәүче типтәрләр дә нәкъ шундый ук квитанцияләрне тәкъдим итә һәм үзләрен типтәр катламыннан «башкорт» катламына күчерүләрен дәгъвалый. Бикчәнтәй авылы татар-типтәрләре хәтта 1842 елда да бабаларының 1700 нче еллар башында ук бобыль ясагы (сусар тиресе белән) түләп барулары һәм бүгенге авыл җирләренә бернинди акт йә килешүләрсез рәвештә килеп төпләнүен тәкрарлый. Шулардан соң ук Чалманарат, Ахун, Кормаш авылларының ышанычлылары да бабаларының типтәр-бобыль катламында торуын һәм сусар ясагы түләп баруын дәгъваларының төп нигезе итә. Әмма Бикчәнтәйдәге – 20, Кормаштагы 34 ир-ат, барыбер, 1762елда ясаклы татарлар булып исәпкә алына әле. Бер өлеше Байлар волосте вәкилләре булганга күрә, алар – старшина Муса Хәсәнов, ә Ахун авылындагы 9 гаилә Бүләр волосте старшинасы булган Минәй (Миңнәхмәт-?) Бикбауов кул куйган кәгазьләр нигезендә эш йөртә.

Сез ул замандагы волость мәйданын берникадәр күз алдына китерсен өчен, 1762 елда Байлар волосте старшинасы Муса Хәсәновка кайсы авыллар буйсынуын саныйк. Ятау авылы (34 ир-ат, старосталары Акчүәк Хәсәнов, ышанычлылары Тө(ү)бәк Мәүлиев), Кырык Каен Түбә (7, Исәнмәт Әсәнев, Ибраһим Мәмәдәлин), Әмәкәй (42, Кадергол Кадермәтов, Мәһди Айдагулов), Карач (34, Мортааза Сәетов, Иман Аманов), Бикчәнтәй (20, Шәһиәхмәт Ишмәтов, Зәет Әитов), Кормаш (34, Шәфи Гавәзев, Игүмәт Әиткулов), Коллар (6, Йосыф Туйчин, Дусмәкәй Теләүлиев), Илтимер (29, Уразай Уразмәтов, Бакый Аб(ю)кин). Әлеге авыллардагы ирләрнең барысы да турыдан-туры йөзбаш Булат Мостафинга буйсына, писарь ролен Мөэмин Мөслимов башкара.

1762 елда Кормаш авылының үзендә Мостай Юлдашев, Булат Мостафин, Муса Мөслимов, Таһир Мөслимов, Нәдер Мөслимов, Игүмәт Әиткулов, Гавәс Гасәнов гаиләләре һәм Гавәс йортында яшәүче Усман Мурзакаев – барлыгы 34 ир-ат исәпкә алынган, соңгысы типтәр-бобыль катламына кертелгән.

1795 елда Кормаштагы халык саны 72 ир-атка һәм 69 хатын-кызга җиткән. Барысы да йөзбаш Бикташ Булатов буйсынуында саналган. Кормашлылар «башкорт» катламына язылган Әгъбәс, Әҗәкүл, Аккүз, Байсар, Бикбау, Исәммәт, Карач, Такталачык, Тыңламас, Теләкәй, Шәрип, Бәкәбез, Бикчәнтәй, Җизмыек, Мерәс, Мөшегә, Чөгәнә, Үмәнәй авылларыннан татар кызларын килен итеп алып кайткан. 1782 елгы җанисәптән соң үз җирләренә Яхшый авылыннан килгән Мәүмүт Му(и)рсәлимов гаиләсен яшәргә керткән. Күренәдер, бер төбәктәге татар-



● Иске Кормаш авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл.

лар арасында килен алышу, туганлашу, ярдәм кулы сузу гаиләләрнең кайсы катламда саналуына бәйле булмаган.

1816 елгы 7 нче ревизия вакытында Кормашта 129 ир-ат һәм 117 хатын-кыз гомер итә. Алар 3 нче типтәр командасында санала. Авылда һаман Бикташ Булатов (өч хатыны бар) өстенлек итә. Аннан тыш авылда аның туганнары Биктимер, Мохтар, Мөвәшшәр гаиләләре яши.

Без Кормаш авылын Байлар волосте вәкилләре нигезләве турында әйткән идек инде. 19 гасыр уртасында бу авылдан бер төркем гаилә аерылып чыга да Яңа Кормаш авылын нигезли. Кормаш авылында беренче «башкорт» катламына язылган татарлар 1742 елда исәпкә алына. Алар арасыннан «башкорт» Искәндәр Кормашев, Дауд Сөләйманов, аларга кушылып, Әмәкәй авылыннан Уразмәт Тукушев, Исәнсефтән Сәет Мәскәүев, Уразай Ишмәкев, Йосыф Сөләйманов, Качкын авылыннан Иткүнә, Мәет һәм Әсән Морзакаевлар, Үтәй Сөләйманов, Сөякәйдән Кадермәт Ишәлин, Котлы(мөхәм)мәт Мәскәүев, Кормаштан типтәр катламындагы Мөслим Бигәшев, Мостафа Таймәтев, Илтимердән Йосыф Иткинин, Зәет Илмурзин һәм Әбки (Габдулла-?) Уркин нәкъ шул елда Кыр-Елан волостена күчеп китә. Алар арасыннан Йосыф Иткинин белән Әбки Уркин гына кире кайтып, 1762 елда Илтимер авылында вафат була.

Исемлектә беренче булып телгә алынган Искәндәр Кормашевның авылны нигезләүче Кормаш атлы ир нәселеннән булуы бәхәс тудырмый, әмма авылның нигезләнү датасын тагын да ераккарак этәрә. Моңа 1842 ел белән тамгаланган бер документ сәбәп. Байлар волостеның Кормаш авылындагы вәкилләре Курамша Мөхәммәтрәхимов белән Бикмөхәммәт Сатыев шул елда стряпчий (суд яки хөкүмәт документлары белән эш итүче) Скорятиновка мөрәҗәгать итә. Алар бабалары кулында вотчинниклар белән татар телендә язылган бик борынгы килешү булганлыгын, әмма әлеге кәгазьнең 1770 елгы янгын вакытында янып юкка чыгуын тәкрарлый. Ә килешүдә бабаларының әле янгынга кадәр 100 ел элек үк килеп урнашуы турында бәян ителә. Юкка чыккан килешүдә вотчинник Әхмәт Исәмматов, Айдагол Байдалин, типтәрләрдән – Курмаша Тангатаров, Даут Сөләйманова, ясаклы татар Мостафа Туймәтов, Мөслим Бигашев исемнәре дә санап үтелгән була.

Әлеге документ Кормаш авылының исемен Курмаш Тангатаров аты белән бәйләргә мөмкинлек бирә. Чөнки бу Курмаш 1703 елның 16 ноябре белән тамгаланган документта Баржы авылындагы (ул Түбән Кама ГЭСын төзи башлагач, 1965 елларда су астында калып юкка чыкты) ясаклы татар буларак та телгә алына. Тарихи чыганак аның Вятка өязендә яшәгән морзалар нәселеннән булуын исбатлый. Көчләп чукындыру чорында «чабатасыз морза» булып калуы сәбәпле, ул Уфа өязендәге Баржы авылына күчәргә мәҗбүр була. Анда гаиләсе белән бергә үзенә беркетелгән җиргә саклау грамотасы алуга ирешәләр һәм бобыль ясагы түләп баралар. Соңыннан алар җиңел генә «башкорт» катламына да күчеп куя. Димәк, Курмаш-Кормаш Тангатаров Кормаш авылына 1703 елдан соң гына күчеп утыра ала. Шулай икән, 18 гасырның беренче чирегендә Кормаш авылында морзалар гаиләләре дә яши, аларның бер өлеше 1742 елда бүгенге Башкортстанның Ярмәкәй, Илеш, Туймазы, Шаран, Чакмагыш, Татарстанның Баулы районнарын үз эченә алган Кыр-Елан волостена күчеп китә. Әлеге волостьны әле озак еллар буе Кыр-Елан – Байлар волосте дип тә атап йөртәләр.

Оренбург губернасының Уфа өязе оештырылгач, Кормаш Минзәлә өязе буйсынуында йөри. 1811 елгы җанисәп вакытында авыл элеккеге старшина Муса Хәсәновның улы Дәүләтбай Мусаевка буйсына. Авылда 77 ир-ат яши, 31 е бүләрләр булып санала.

1834-1850 еллар аралыгында Яңа Кормаш авылы пәйда була, дидек. Яңа авыл нигезләү дә, Кыр-Елан волостена күчеп китүләр дә чәчүлек җирләр җитмәү кытлыгыннан туа. 1880 елда Яңа Кормаштагы «башкорт типтәрләре» власть ияләре каршында үзләренең элек Байлар волостена буйсынган Баржы авылында вотчинник яки «асаба башкорт» булуларын дәлил итеп китерә. Ул вакытта инде Баржы Алабуга өязе составында исәпләнә. Яңа кормашлылар үзләренең морза Дәүләтьяровлар нәселендә саналуын һәм кулларында вотчинник грамоталары булуын бәян итә һәм үзләрен кабат Баржы утарларына кайтаруын үтенә. Кәгазьгә Мөхәммәтгали Корбангалин, Хамат Ибәтуллин, Әхмәтша Курамшин, Шаһиәхмәт Биккулов һәм тагын 12 крестьян кул куйган. Аңлашыла булыр, власть ияләре татар морзалары булып йөргән татарларның үтенечен колагына да элми. Алар бераздан үзләрен Вятка өязенә күчерүләрен дә сорап карый, тик нәтиҗә шул ук...

Бүләр волосте игенчеләре арасында саналучы кормашлылар арасында Айтуган Сабаков (Субаков) оныклары да була. Ә Айтуган үзе – Байсар авылына исем биргән вотчинник, 1630 елларда Кыргыз волосте старшинасы булып торган Байсар Козяшев тарафыннан Бүләр волосте җирләренә яшәргә кертелгән крестьян. 1653 елның 5 мартында төзелгән документта Турыш авылы «башкорты» Айтуган Бүләр волосте «башкорты» Байсарга ел саен казнага 5 сусар тиресен ясак рәвешендә түләп баруда ярдәм итәргә тиеш, дип тәгаенләнә. Элек Турыш авылында «гулящий» булып йөргән Айтуган вотчинник Байсарга ярдәме өчен «башкорт» булып китә. Соңрак Айтуганның оныклары Кормаш, Сәфәр, Чалманарат авылларына да тарала. Кормаш авылы өчен Айтуган нәселе менә бу рәвешчә күз алдына килә: Субак-Айтуган-Татлыбай-Юлдаш-Максут-Мәсгуть (1776).

Кормаш авыллары турында 1859 елгы 10 нчы ревизия мәгълүматлары да бик кыйммәтле. Ике Кормаш авылы да 19 гасыр башында 18 нче «башкорт» кантонының 11 нче Йортында санала бит. 1855 елгы фәрман нигезендә ике Кормаш авылындагы барча халык, хәтта ясаклы татарлар да «башкорт» булып санала башлый. Ул елда Иске Кормашта 334 ир-ат һәм 331 хатын-кыз исәпкә алына. Ни кызганыч, 1835-1838 елларда ук армиягә алынган Йосыф Сайранов, Шәмсетдин Хәсәнов һәм Габделгали Миндәев турында бер хәбәр дә кайтмый. 1858 елда Хөснетдин Биктимеров атлы берәү чукына да рекрутлыкка китә. Авылларда Мөхәммәтәмин Ихсанов, бертуган Мөхәммәт, Мөхәммәтша һәм Әхмәтша Мәхмүтовлар мулла булып тора.

1870 елга кадәр Иске Кормаш зур үзгәрешләр кичерми, анда 376 ир-ат һәм 365 хатын-кыз (103 хуҗалык) исәпләнә. Авылның мәчете, мәктәп-мәдрәсәсе, 12 лавкасе була, җомга көннәрендә базар үткәрелә.

Яңа Кормашта 1859 елда 167 ир-ат һәм 169 хатын-кыз (69 хуҗалык) «башкорт» катламындагы татар булып яши. Дөресрәге: 86 ир-ат – «башкорт», 76 сы – «башкорт типтәре» булып исәпләнә.

Аңлашылганча, Бүләр волосте җирләрендә тамыр җәйгән Кормаш авылларын данга күмүдә Нократ татарлары, морза Дәүләтьяровлар нәселе, бүгенге Әгерҗе районының Баржы авылыннан күчеп килгән татарлар көч куя. Хөкүмәт 1798 елда «башкорт» кантоннары составына беркетеп чыкса һәм 1855 елгы фәрман нигезендә тулысынча башкортлаштырып бетерергә омтылып караса да, Кормаш авылы халкы асыл татарлыгын җуймый, татар булып яши.

Таһир КӘРИМОВ,
Ш.Мәрҗани исем. Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре.

Чыганаклар:
1. Национальный архив Республики Башкортостан (НА РБ), ф. И-172, оп. 1, д. 20.
2. Татары Уфимского уезда (материалы переписей населения 1722-1782 гг.): справочное издание / Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2020.
3. Российский государственный архив древних актов (РГАДА), ф. 350, оп. 2, д. 3801, л. 514530. Аналогичные сведения в книге: Крестьянская война 1773-1775 на территории Башкирии: Сборник документов. – Уфа: Башк. кн. изд-во, 1975.
4. НА РБ, ф. И-138, оп. 2, д. 51.
5. НА РБ, ф. И-2, оп. 1, д. 1285, т. 1.
6. РГАДА, ф. 350, оп. 2, д. 3801.
7. Кәримов Т. Иске Кормаш // Татарстан. – 1996. – № 7.78
8. РГАДА, ф. 1173, оп. 1, д. 1374.
9. История башкирских родов. Том. 36. Буляр. – Уфа: Изд-во Башк. ун-та, 2020.
10. НА РБ, ф. И-10, оп. 1, д. 1257.

Атнаның сәяси мизгелләре

Серле инцидент

Россия президентының матбугат хезмәте 3 май төнендә ике очучысыз очкычның (ОО) Кремльгә һөҗүм итү омтылышы булуы, хәрбиләр һәм махсус хезмәтләрнең үз вакытында күргән чаралары нәтиҗәсендә аларның бәреп төшерелүе, төшкән җирләрендә исә физик һәм матди яктан зыян күрүчеләр булмавы турында белдерде. Мәскәү әлеге күңелсез вакыйганы, 9 май алдыннан үткәрелгән террор акты һәм Россия президентының тормышына янау, дип бәяләде һәм җавапны үзе кирәк дип тапкан вакытта һәм урында кайтарачагы турында әйтте. Кремльнең матбугат хезмәте башлыгы Д.Песков шулай ук дроннарның Кремльгә һөҗүм итүендә Вашингтонны гаепләде. Аның әйтүенчә, мондый террор актлары турында карарлар Вашингтонда кабул ителә, ә Киевтә кушканны гына эшлиләр. Ак йорт вәкиле Джон Кирби исә АКШның моңа бернинди дә катнашы юклыгы, һич мәгълүмат булмау сәбәпле, вакыйганы хәтта бәяли дә алмавы турында белдерде. Үзенә белдерелгән гаепләүләрне Киев тә кире какты. Ә Франция тышкы эшләр министры Катрин Колонна ООларның Кремльгә әлеге һөҗүмен «сәер вә серле инцидент» дип атады. Мәскәү мэры С.Собянин исә башкалада ООлар җибәрүне тыя торган карар кабул итүе турында да белдерде.

Узган атнада Россиядә шартлатулар тимер юлларда һәм сәнәгать предприятиеләрендә дә булган. Әйтик, Брянск өлкәсенең Снежетьская станциясе янында тимер юлны шартлату нәтиҗәсендә, йөк поезды локомотивы һәм 20 вагонның рельслардан чыгуы мәгълүм булды. Ә Краснодар крае Темрюк районының «Таманьнефтегаз» предприятиесе территориясендәге резервуарларга ОО төшүе нәтиҗәсендә, 1250 кв. метр мәйданда янгын чыккан.Охшаш характердагы башка шундый хәлләр турында да хәбәрләр бар.

Игътибарны инде сәяси атнаның кайбер башка вакыйгаларына да юнәлтик. АКШ дәүләт секретаре Э.Блинкен әйтүенчә, Украина үзенең контрһөҗүмен якындагы атналарда башларга планлаштыра икән. АКШ һәм аның союздашлары Россиягә каршы санкцияләрнең 11 нче пакетын (ул моңа кадәр кертелгән санкцияләрне әйләнеп үтүгә каршы юнәлдерелгән) әзерләүләре мәгълүм. Украина президенты В.Зеленский Финляндиягә һәм Нидерландка сәфәр кылган. ОБСЕ Украинадагы низаг нәтиҗәләре глобаль тотрыклылыкка янавы турында белдергән. Россиянең һәм Кытайның тышкы эшләр министрлары С.Лавров белән Цинь Ган Украинадагы низагны җайга салу мәсьәләсен тикшергәннәр.

Фоат УРАЗАЙ.

Мәдәни җомга
12 май
№18, 2023

Әмирхан ЕНИКИ

Ана һәм Кыз



(Дәвамы. Башы 17 нче санда).

– Әйе, Хәсәнем әтисе мәрхүмгә охшаган. Әтиең мәрхүм бик ипле, бик йомшак күңелле кеше иде. Бервакытта да беркемгә дә авыр сүз әйтмәде. Беркем белән дә сүзгә килеп, бозылышып тормады. Әйтәсе юк, мәрхүм бик сабыр холыклы, чыдам кеше иде... Хәсәнемнең әле үз башына дөнья көтә башлаганы юк. Менә исән-сау кайтыр... эшли башлар...

Шушы минутта Рәхилә почта таратучы Маһирәнең тәрәзә каршысыннан үткәнен күреп калды. Әнисенең нәрсә сөйләгәнен онытып, үз-үзеңә һич исәп бирмәстән, урыныннан торып, ашыга-ашыга ишеккә таба юнәлде. Гадәттә, тирләгән сипкел битле Маһирә, бу йортта бик көтелгән, килгән саен бик якты йөз белән каршы алынган кеше булганга күрә, туп-туры өйгә кереп, кычкырып исәнләшә һәм:

– Менә, Хәмидә җиңги, улыңның үз кулыннан алып китердем, – дип, алып килгән хатын ананың күкрәге өстенә куя иде. Аның һәр килүе бу сагышлы моңсуга, авыру тынлыкка төренгән кечкенә өй өчен чын бәйрәм була иде. Һәм Рәхилә, Маһирәнең килгәнен күреп, бервакытта да каршы чыкмый, алдан ук дусларча елмаю белән, ишектән күзләрен алмыйча, кергәнен көтеп тора иде.

Бүген ул ни өчендер каршы чыкты.

Капкадан кереп өлгергән Маһирә Рәхиләне күрү белән:

– Әһә, Рәхилә апа, күңеле сизеп, көтеп торган икән, – дип, көр тавыш белән кычкырып куйды. Иске күн букчасыннан бер бәйләм хатлар чыгарды һәм алдан ук билгеләп куйган бер ак конвертны җитез генә алып Рәхиләгә сузды.

Рәхилә ак конвертны кулына алды, ләкин шунда ук кире бирәсе килеп куйды. Адресны язган кул һич таныш түгел һәм конверт бик юка иде. Ләкин шик юк: конверт аның исеменә иде. Ул, эчендә хаты барын белергә теләгәндәй, бармаклары белән капшап карады. Соңра ниндидер бер шомлы шикләнү белән ашыгып конвертны ачты. Конверт эченнән урталай бөкләгән кечкенә саргылт кәгазь чыкты. Аның сул почмагында бик үк ачык төшмәгән штамп иде.

Рәхилә бик тизлек белән – хәтта шундый тизлек белән, әйтерсең, йөрәге тибүеннән туктап тора иде – кәгазьне укырга кереште:

«...нчы танковый полк штабы шушының белән сезгә хәбәр итә ки, танк йөртүче сержант Хәсән Гыйльметдин улы Ишаев 1942 елның бишенче июнендә Ватаныбыз өчен немец-фашистларга каршы каты сугышта батырларча һәлак булды. Күмелгән урыны Курск өлкәсе, Рельски районы, Кострова авылы янында, туганнар каберендә...»

Рәхилә кәгазьне ахырына кадәр укый алмады, каты итеп сул кулына йомарлады һәм, кинәт кенә борылып, өй ишегенә таба китте.

Куанычлы хәбәр килү шатлыгын уртаклашуны көтеп торган Маһирә Рәхиләнең болай кинәт борылып китүеннән аптырап калды һәм, артыннан кычкырып:

– Рәхилә апа, бәй, нигә бер сүз дә әйтмәдең, кемнән соң, Хәсәннәнме? – диде.

Рәхилә китеп барышлый, гүя Маһирәгә түгел, һавага ташлагандай, бары:

– Әйе, – дип кенә куйды. Ул кемнәндер кача кебек иде. Маһирәнең: «Йә, нәрсәләр язган соң, тукта әле?» диюеннән котылыр өчен, тиз генә өйалдына кереп югалды. Инде өй ишегенең тоткасына тотынгач, ул ирексездән туктады. Өйгә, ана янына керү аның өчен шундый шомлы, шундый авыр, газаплы иде, әйтерсең, ул хәзер менә баштүбән тирән бер бушлыкка егылырга тиеш. Ничектер кинәт бөтен тәне хәлсезләнгән, күз аллары караңгыланган кебек булды... Ләкин ул бернәрсә дә уйлый алмый иде әле, һәм аның кулы, «керергә кирәк» дигән карардан түгел, ә үзлегеннән ишекне ачты. Өйгә керүгә ул, ананың карашы белән очрашмас өчен туп-туры алдына карап, тәрәзә янына узды. Кызының кергәнен көтеп яткан ана тиз үк:

– Кем бар иде анда? – дип сорады.

– Мәрфуга җиңги. Иләк сорап кергән.

Ни өчен Рәхилә болай дип җавап бирде? – ул һичбер вакытта да әйтеп бирә алмас. Әнисен алдау уе аның башына һич килгәне юк иде; бу шулкадәр көтелмәстән, уйламастан һәм шулкадәр табигый әйтелде ки, Рәхилә ихтыярсыз янә эченнән әле генә әйткән сүзләрен кабатлап куйды. Ана исә, хуҗа булып:

– Үткән бер алуларында ертып керткәннәр иде, әйтеп бирер идең, – диде.

Рәхилә дәшмәде. Әнисенең бу ялганны чынга алуы аны бер минутка ниндидер һәлакәттән коткарган кебек булды. Ләкин ул үзен һаман ялангач хәлдәге кеше сыман тоя, йөрәге аша өшү, калтырау йөри, һәм ана бер дикъкать белән караса, бөтенесен аңлар төсле... Чыннан да, Рәхилә баскан урыныннан кузгалырга курка, ул үз хәлен аңларга көчәнә, каядыр югалган уйлау куәтен табарга тырыша. Бәхетсезлек үзенең бөтен мәрхәмәтсез чынлыгы белән аның аңына барып җитмәгән кебек... Ул иң гади сорауларга җавап бирергә маташа: «Хәсән үлгәнме?» – «Әйе, үлгән». – «Хәсән инде кайтмасмы?» – «Юк, кайтмас». – «Чынмы бу?.. Чынмы бу?..»

Сүзе бүленгән ана:

– Кызым, син мине тыңлыйсыңмы? – ди. Бәлкем, бу аның икенче дәшүедер. Рәхилә күзләрен йома:

– Әйе, әни...

– Менә, кызым... Нәрсә әйтмәкче идем соң? Хәтерләрем бик таркау шул... Әйе, менә, Алла боерса, кайтыр... Эшкә керер... Укуын бетергәннән соң аның беренче башлап эшләве генә бит әле... Яшь, тәҗрибәсез... Кемнәр белән очрашмас, кемнәр белән бергә булмас... Кешенең төрлесе – яхшысы, яманы була... Шуңар күрә, кызым, нытып әйтеп каласым килә: берүк эшендә гадел була күрсен...

Ана ашыкмыйча гына улының эштә, тормышта ничек булырга, үзен ничек тотарга тиешлеген сөйли. Рәхилә исә, кыймылдарга куркып, анасына кырын басып тора һәм күзләрен ачарга көче җитми. Менә Хәсән аның сул кулында... Юк! Хәсән үзе биредә шикелле... Рәхиләнең аңын бер секундка томан каплады, һәм аның йомык күзләре алдына бик ачык булып туганы Хәсән килде: гүя ул шушы ак конвертны тотып ишектән килеп керде. Рәхиләнең колагына аяк тавышы, ишекнең ачылганы ишетелгән кебек булды... Туганы ни өчендер ялан-баш... Ләкин ник бер үзгәрсен... нәкъ әүвәлгечә, ябык, нечкә озын буйлы... Тик йөзе генә, студент вакытына караганда, шактый олыгайган... киң маңгаена алкаланып кара чәче төшкән... Кечкенә күзләре куаныч белән елтырыйлар, ул тарсынып елмая, гүя кинәт, көтмәгәндә килеп керүеннән уңайсызлана төсле (ул шулай һәркайчан кызлар кебек оялчан иде)... Иреннәре аның кыймылдыйлар, ул нәрсәдер әйтә шикелле, тик тавышы ишетелми... Һәм менә кулындагы ак конвертны әнисенә суза...

Рәхилә куркынып күзләрен ачты, башын селкеп куйды, һәм аңына кайту белән башына килгән беренче уй: «Ник элек әни үлеп, соңыннан бу хәбәр килмәде? Ни өчен бу гаделсезлек?» дигән уй булды.

Ул инде хәзер ананың сүзләрен тыңлый алмый, ул сүзләрнең һәртөрле мәгънәсе югалды, тик утлы күмергә акрын гына өргән җил шикелле, йөрәгенең чыдамаслык әрнүен генә үстерә, көчәйтә... Һәм Рәхилә зур булып ачылган күзләре белән тирәюнендә хәлсез ялварып карана. Ана исә һаман сүзен дәвам иттерә:

– Инде миннән соң, кызым, аның белән син каласың. Син аны карап үстердең, үзең аның белән бергә үстең. Сез бик дус идегез. Хәтерендәме, ул, «Рәхилә апай!» дип, артыңнан калмыйча ияреп йөри иде... Инде, кызым, сиңа васыятем шул: бервакытта да аның белән араң бозылмасын, исемегез кешеләр теленә гайбәт булып кермәсен. Син олы була бел. Минем урынга каласың... Ана бул... Бервакытта да ярдәмеңнән, акыллы киңәшеңнән ташлама... Ул бик яшь бит әле... Син инде аңардан күзләреңне алма... Кызым, ник дәшмисең?

Рәхилә әнисенә таба атлады. Кинәт ул үзендә шундый хәлсезлек, – әйтерсең, тәненнән бөтен канын суыргannар, – шундый бер хәлсезлек тойды... Тезләре акрын гына сыгыла кебек... Менә хәзер әнисенең аяклары өстенә ава, күкрәгеннән ярсу ычкына: «Аһ, әни!» – ди, ләкин яшьләренә буыла һәм сүзсез елый, бөтен тәне белән калтыранып елый, елый да елый... Аһ, аңа үзе һәм әнисе шундый кызганыч, алар шундый бәхетсезләр, шундый ялгыз-бәхетсезләр...

Юк, Рәхилә аумады. Бу – берничә секунд башының томан эчендә йөзүе иде, бу – тау кебек газапның бик төптән күтәрелеп бугазга килүе иде. Рәхилә аны кире йота алды, ул турайды, ул тиран-тигез генә сулады, акрын-тыныч кына:

– Ярый, әни! – диде.

Һәм ана үз нәүбәтендә кызына ихтирам тулы күзләре белән карап:

– Рәхмәт, кызым, мин сиңа ышанам! – диде.

Алар арасында тынлык урнашты. Рәхилә, бу сүз бүленүдән файдаланып, тышка чыгарга ашыкты. Ул ананың Хәсән турында яңадан сөйли башлавыннан котылырга, аз гына вакыт ялгыз булырга, ичмасам, бер тулы итеп һава суларга кирәклекне тоя иде. Ләкин ул туп-туры чыгып китәсе урынга, әүвәл өстәл янына килеп, ни өчендер буш стаканны кулына алды, китә башлагач, яңадан борылып, аны кире урынына куйды, соңра ишеккә таба китте.

(Дәвамы киләсе санда).

Татар хорларына яшел юл кирәк...

Татар хор музыкасы 1917 елгы инкыйлабтан соңгы елларда шактый җанланып китә. Татар халкы, бернигә карамыйча, үзенең иҗади көчләрен үстереп, үзенчәлекле милли сәнгатен булдыру өчен көрәшә. Күмәк җырлау киң таралыш ала. Беренче көннәрдән үк күп урыннарда үзешчән хор коллективлары барлыкка килә. Бигрәктә утызынчы елларның беренче яртысында район үзәкләрендә, Татарстан шәһәрләрендә, шулай ук Казанда да хор белән җырлауга игътибар арта, күп санда үзешчән һәм профессиональ хорлар, вокаль ансамбльләр гөрләтеп эшли. Бу коллективлар белән республика хор оешмасы җитәкчелек итә. Кызганыч ки, XX1 гасыр башында хор һәм ансамбльләр саны сизелерлек кимеде. Моны сәнгатькәрләрнең матди хәле начараюы, композиторларыбызның яңа әсәрләр иҗат итмәве, төрле хор фестиваль-конкурсларның, күмәк җырлау бәйрәмнәренең уздырылмавы, уздырылган очракта да хор ассамблеяларында һәр елны бер үк коллективлар җыелуы, аларның да күбесе уку йорты хорлары булып, татар хорлары аз санда булуы һ.б. сәбәпләр белән аңлатып буладыр.

Хор жанры үсешенең алтын чорында Татарстанда эшләп килгән иҗат коллективлары арасында иң күренеклеләреннән 1960 нчы елларда В.И.Ленин исемендәге мәдәният сараенда оешкан татар халык хоры була.

Иң элек ул 1949 елда Горбунов исемендәге клубта Роза Бичурина җитәкчелегендә барлыкка килә. 1956 елдан башлап аның белән дүрт ел Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә хормейстер буларак тәҗрибә туплаган, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Суфия Шаһиева җитәкчелек итә. Ул ансамбль репертуарыннан күп җырларны кертә, коллектив шактый еллар иң күренекле хорларның берсе була. Югары башкару осталыгына ия булган бу ханым, хор белән хезмәт кешеләрен эстетик тәрбияләүдә зур эш башкара. Хор үзешчән коллективлар арасында беренчеләрдән булып иҗади уңышлары өчен М. Җәлил исемендәге яшьләр премиясенә лаек була.

Наил Мәсгуть улы Бариев (театр артисты Шамил Бариевның бертуган абыйсы) үзешчән сәнгатьтә үзенең эшчәнлеген шушы хордан башлый. Коллективка ул армия хезмәтеннән соң килә. Тиз арада үз тырышлыгы белән хор белән җырлау серләренә төшенә, хор белән җырлауны инструмент белән кушу үзенчәлекләрен өйрәнеп ала. Хор җитәкчесе Суфия ханым Шаһиевага хор партияләрен өйрәнергә, концерт программаларын төзергә ярдәм итә.

Армиядә хезмәт итеп кайткач, Наил Бариев Казан Авиация институтын тәмамлый. Көндезләрен заводта эшләсә, кичләрен – баянда уйный. Аның хатыны Сурия ханым белән танышлыгына да шушы хор сәбәпче. Сурия Бариева әле дә булса, олы яшенә карамыйча, әйдәп баручы җырлаучылардан.

1960-1980 елларда хор ел саен уңыш җыю чорында авыл хезмәтчәннәрен ял иттерү максатында концертлар белән кырларга чыга. Н.Бариев эшләгән елларда бу хор республикада гына түгел, Бөтенсоюз буенча танылa, халык хоры исеменә лаек була, 1969 елда Мәскәүдә Татарстан профсоюзларының исәп-хисап концертларында катнаша, Бөтенсоюз фестивальләр лауреаты була.

Н.Бариев бу хорны берничә тапкыр яңадан торгызуга ирешә. Хорның максатларын һәм бурычларын тәгаенләп, ул күптавышка җырлый ала торган коллектив җыеп, аның уставын төзи, күренекле хормейстерларны чакыра һәм хорның һәрдаим була торган дәресләрен җайлый. Киң аудитория өчен дә концерт программалары әзерли. Казаныбызның мәктәп директорлары, санаторий, мәдәният йортлары җитәкчеләре белән эшлекле элемтә оештырып, концертлар куя. Шәһәрнең район хакимияте үткәргән чараларда һәрдаим катнаша һәм хезмәт ветераннары советы өчен махсус программалар әзерли.

Н.Бариев яңадан оештырылган татар хорының җитәкчесе, концертмейстеры, хормейстеры булып бүген музыка факультетын тәмамлаган кызы Алия Минкашева эшли. 23 апрельдә алар «Таныш моңнар» дип аталган бик матур кичә үткәрде. Бик күп кунаклар да чакырылган иде. Ленин исемендәге мәдәният сараендагы Татар халык хорының озакламый билгеләп үтеләчәк 75 еллыгы уңаеннан оештырылган бу кичәдә җырлар килгән кунаклар – күренекле сәнгать осталары Клара Хәйретдинова, Георгий Ибушев, Айгөл Бариева, Фәрит Гафиатуллин, Хәйдәр Сафин, Геннадий Максимов һ.б. котлаулары белән үрелеп барды.

Хорның репертуары да бик бай, элеккеге халык көйләрен, композиторлар С.Сәйдәшев, Р.Яхин, Б.Мөлеков, И.Хисамов, З.Гыйбадуллин, Р.Гатауллин әсәрләрен башкаралар. Коллективта 27 яшьтән алып 83 кә кадәр җырга моңга гашыйк 25 тән артык җырчы катнаша.

«Без гамәлдә бар, исәптә юк, – дип сүзен башлады Наил Мәсгуть улы. – Бөтен эшчәнлегебез энтузиазмга кайтып кала. Шәһәр мәдәният идарәсе дә, республика Мәдәният министрлыгы да безнең хакта белә дип уйлыйм, әмма беркаян да матди ярдәм алганыбыз юк. Без җитәкчеләр дә Ленин мәдәният сараенда штатта түгелбез, ярый әле алар бүлмә биреп тора. Гомумән, хорның элеккечә традицияләрен саклау эше даими алып барылырга тиеш. Бүген бер спортчыга миллионнар түлиләр, шуның кечкенә генә бер өлеше хорларны үстерүгә бирелсә, нинди шәп булыр иде. Халык иҗаты һәм милли гореф-гадәтләр елында безгә бу хакта хыялланырга гына кала...»

Хор сәнгатенең академик кануннары белән иҗат итүче үзешчән коллектив буларак яңа татар хоры мәдәният җитәкчеләренең игътибарына лаек.

Филүсә АРСЛАН.

● «Җиләкле җәй».

ҖИР ҖИЛӘКЛЕ

Картиналар, сәйлән белән чигелгән кул эшләнмәләре, чигүле калфаклар, кәттәҗи, түбәтәй, сөлге, кульяулыклар – һәммәсе күз явын алырдай дәрәҗәдә матур! Минзәлә районының Наратлы Кичү авылында туып үскән Хәния Гәрәева бүген Тукай районының Калмия авылында яшәп иҗат итә. 2014 елдан алып Татарстан Рәссамнар берлегенә кабул ителгән останың инде утыздан артык шәхси күргәзмәсе ачылганга күрә, аның иҗатын якыннан белүчеләр, ошатучылар да күп. Алар күргәзмәләргә останың яңа декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләрен күрергә бик теләп килә һәм моңа кадәр күргән иҗат эшләрен дә карап сокланалар. Алар арасында бер үзенчәлекле иҗат эше аеруча игътибарга лаек. Ул «Әнкәйне сагынган төн» дип атала. Аңа карагач, күргәзмә залыннан үкси-үкси чыгып китүчеләр дә бар... Менә шундый тәэсирле сәнгать. Шуңа күрә әңгәмәбезне дә шушы әсәр тарихыннан башладык.

●«Әнкәйне сагынган төн».



● «Күзге моң».

– Хәния ханым, әлеге эшегез ничек иҗат ителде?

– Бер төнне һәрвакыттагыча кул эше белән утыра идем, уйланып китеп, карашымны төнге тәрәзәгә төбәдем. Шул мәлдә кайнанам, Мөзәнәя әнкәй искә төште. Бу эшем аңа багышланган. Үз әнием Фәния 2000 елда дөньядан киткән иде, ә Мөзәнәя әнкәй 2012 елда вафат булды. Әнкәйләрем бик яхшы күңелле иде, Мөзәнәя әнкәебез шигырьләр дә язды, аның «Күңел мәрҗәннәре» дип аталган китабын да бастырдык әле... Мин әлеге эшләнмәмне ничектер тиз арада ясадым. Аңа ул исән чакта ук үскән яран гөле сурәтен дә өстәдем. Кешеләрнең рухлары якты дөньяга күбәләк булып кайта, диләр бит, шуңа күрә күбәләк ясап та беркеттем. Күргәзмә залы хезмәткәрләре, бу әсәремә карап, елаучылар шактый, диләр шул...

– Сез үз эшләрегез өчен темалар сайлаганда нәрсәгә күбрәк игътибар итәсез?

– Барыннан да бигрәк аларның милли темаларны яктыртуын телим. Чөнки институттагы курс эшләрем, диплом эшем дә милли чигүләр белән бәйле булды. Халык сәнгатен игътибар үзәгенә алган диплом эшен институтта бер мин генә якладым да төсле. Һәр хәлдә шулай истә калган. Борынгы чигешләрдәге композиция төзелешенең камил булуын, бар төсләрнең дә тулы гармониягә китерелүен, тукыма фактураларының да эшләнмә өчен кулай сайлануын искәртә килдем, узганда яшәгән инсаннарның зәвыгына ихлас сокландым.

– Хәния ханым, картиналар ясаучы һөнәри рәссам булып кына калмаячагыгызга кайчан төшендегез?

– Минзәлә педагогика училищесын тәмамлап, 1976 елда Тукай районының Калмия авылында – башлангыч сыйныф укытучысы, аннары 1978-1991 елларда Чаллының 1 нче балалар хастаханәсендә укытучы-тәрбияче булып эшләдем. Рәссам буларак, хастаханә өчен мөһим рәсемнәр, плакатлар да ясадым. Калмияда укытканда ук, булачак ирем Филәрит белән танышкан идем, бер-беребезне ошатып, гаилә кордык. 1987-1992 елларда Чаллы пединститутында педагогика һәм башлангыч белем бирү методикасы белгечлегенә укыдым. 1991-1997 елларда шәһәрнең 52 нче урта мәктәбендә уку-укыту мөдире, рәсем укытучысы булып хезмәт куйдым. 1997 елда янә педагогика институтына укырга кереп, сынлы сәнгать-графика факультетын читтән торып тәмамладым. 1997-2013 елларда Чаллының 1 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбендә укыту-тәрбия бирү мөдире вазыйфаларын үтәдем һәм шул ук вакытта балаларга «декоратив-гамәли сәнгать» дәресләрен алып бардым. Андагы хезмәткәрләр белән дә бер дулкында булдык, әйтик, рәсем мәктәбе хезмәткәрләре Зилә Муллина һәм Рәзифә Бәдретдинова белән аралашып иҗат иттек, хәзер дә хәл-әхвәлләребезне белешеп торабыз.

1992 елдан башлап чигәм. Ә 1997 елдан мин 52 нче урта мәктәптә эшләгән чакта укытучы, чигү остасы Римма Исмәгыйлева белән 1 нче сынлы сәнгать мәктәбе балаларын да чигәргә өйрәтә башладым. Мәктәп директорыбыз Гайнулла Әһәлетдинов безгә булышлык итте, рухи яктан үсендерде. Диплом эшемне иҗат иткәндә ул да, институттагы диплом эше җитәкчем Рауза Латыйпова-Иванова да тырышлыгымны хуплап торды. Остазым, Татарстанның халык рәссамы Мадияр Хаҗиевка мин аерата рәхмәтле. Ул мине зур сәнгать юлына этәрде. 1993-1995 елларда эштән соң аның кичке студиясендә укып, нәкыш ясау нечкәлекләренә төшендем.

Рәсем ясауга сәләтем барлыгы Минзәләдә укыганда ук ачыкланды. Училищедагы рәсем укытучысы беренче рәсемемне күрүгә үк мактады. Ә ул... карга карачкысына карап ясалган бирем эше генә иде әле. Аннары инде рәсемнәрне һәр көн диярлек ясый башладым, училище өчен плакатлар да яздым... Шулай итеп кул остарды. Әйе, баштарак мин картиналар ясадым, 2004 елда ачылган беренче шәхси күргәзмәм «Сандугач җыры» дип аталды... Башка күргәзмәләремне «КамАЗ» һәм «Энергетик» мәдәният йортларында, С.Садыйкова исемендәге концертлар залы бинасында да үткәрдем. Хәзер дә картиналар ясарга алынам. Пандемия елында авылыбызны һәр яклап сурәткә төшердем һәм 9 картинамны клубка бүләк иттем. Моннан кала, рәссам Ленар Әхмәтов җитәкчелегендәге Яр Чаллы рәссамнар бүлегенә кер-

●Хәния Гәрәева гаиләсе белән.

СӘНГАТЬ ОСТАСЫ

гән кылкаләм осталары белән берлектә туган авылым Наратлы Кичүдә дә, Калмиядә дә картина галереяларын ачтык.

Сизелми дә узып киткән тормыш юлыма әйләнеп карасам, милли гамәли сәнгатебезне үстерүгә 30 ел гомеремне багышлаганмын! Иҗат җебе үрелә һәм аңа үз җан җылың, күңел нурың да кушыла бара, әлбәттә. Мин борынгы сәнгатебезгә мөкиббән һәм һөнәремнең милли сәнгатебезгә бәйле булуы белән горурланам. Иске эшләнмәне кулыма алгач та, әбиләребезнең, әниләребезнең бары тик энә-җеп кулланып шулкадәр могҗизаи матурлык тудыра алуларына һәрчак шаккатам, бу матурлык балкышы минем җаныма да тула. Һәр буын үз бизәкләрен барлаган бит. Гомерем буе милли иҗатыбызны кадерләп, аны җентекләп өйрәнеп, яшь буынга тапшыруны изге бурычым дип саныйм.

Мондый тематикадагы иҗат ул һәрчак актуаль. Милли сәнгать дигәч тә, балачагымда күргән эшләнмәләр дә хәтердә яңара, шулардан илһам алып, үзем дә шома чигүләр, тамбур чигүләрен башкардым. Үз фантазия көчем дә җитәрлек. Катнаш техниканы да еш кулланам. Күлмәкләребезне ямьләп торырлык чәчәкле бизәмле заманча изүләрнең әлләничә төрен эшләп карадым инде.

Эшләнмәләрем башка төбәк күргәзмәләрендә дә катнашты. Әйтик, 2021 елда Дагстанның Дербент шәһәрендә ачылган күргәзмәгә 17 эшем куелды. Чаллыда уза торган «Ел рәссамы» бәйгесендә 2002 елдан башлап 20 ел рәттән катнаштым һәм «Халык сәнгатебезне яңарту һәм үстерү өчен» номинациясендә 13 тапкыр җиңеп чыктым. Башка бүләкләрем дә җитәрлек: «Җанлы традиция» фестивале медале (2007), ЮНЕСКО тарафыннан оештырылган «Әйләнә-тирәбездәге дөнья» проекты медале (2012), Ренат Гобәйдуллин исемендәге «Чаллы сирене» сәнгати иҗат шәһәр бәйгесе медале (2022) һ.б. Мин әле Чаллы шәһәр хакименең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге уңышлар өчен тапшырылучы премиясе лауреаты да (2022). Ягъни бәйгеләрдә катнашырга теләүчеләр, милли сәнгать төрләрен алга этәрүчеләр өчен мәдәни чаралар еш уза дияр идем. Бу да, минемчә, осталарны сыйфатлырак иҗат итәргә илһамландыра. Эшләрем Мәскәүдәге зур күргәзмәләрдә дә экспозицияләнде. Аннары милли эшләнмәләрем белән 7 ел рәттән Мәскәү сабантуйларында, андагы зур ярминкәләрдә дә катнаштым. Анда да башка милләт вәкилләре, мәдәният эшлекләре татар декоратив-гамәли сәнгате белән кызыксынды, эшләнмәләремә соклануларын белдерде, онытылмас очрашулар да булды. Милли костюмнарыбызның бер элементы – кәттәҗиләрне чигәргә өйрәтү буенча биш тапшыру әзерләп, Чаллы телевидениесе аша да күрсәттек, гомумән, милли мирасыбызны радио-телевизион тапшырулар, ана телебездәге матбугат аша әле дә пропагандалап торам.

– Оныкларыгыз арасында рәссамлыкка маһирлар бармы?

– Без ике бала үстердек – улыбыз Рамил һәм кызыбыз Ләйсән. Алты оныгыбыз арасыннан Фәргатебез балалар сәнгать мәктәбен тәмамлады, киләчәктә архитекторлыкка укырга тели. Аның минем һөнәргә якын һөнәр сайлавы куандырды. Онықларны мичтә пешкән бар төр милли ризыкларыбыз белән сыйлап торам, каклар да әзерлим.

– Сезнең кул эшләнмәләрегездә – болын чәчәкләре, җир җиләкләре, бер сүз белән әйткәндә, җәй хозуры... Табигать фасылы темасы туган көнегезнең җәй уртасына туры килү белән дә бәйлеме?

– Билгеле! Мин 1957 елның 14 июлендә туганмын. Әмма дөньяга килүем бала табу йортында булмаган. Әнием мине җиләкләр пешеп утырган, хуш исле, матур, якты аланда тапкан. Әтием әниемнең тулгагы башлангач та, аны шул аланда калдырган да, атны күрше авылга куган. Теләге – тиз арада андагы кендек әбисен алып килү. Алар килгәндә, әни инде мине тапкан, кендекне тешләп өзеп бәйләгән, хәтта мине имезә дә башлаган. Балачакта әнием миңа гел: «Син чәчәкле, җиләкле аланда тудың бит, син мул тормышлы булырсың әле!» – дип юрый иде. Чыннан да, мин үзем ошаткан һөнәремдә булдым, уңышка ирештем, шатлык, куанычлар мине урап узмады. Шуңа үз эшләнмәләремдә дә җәйне еш чагылдырам. Сәйләннәр белән күләмле паннолар чиккәндә җир җиләкләре сурәтләре хакында да онытмыйм.

– Чигәргә өйрәтүегезне үтенеп мөрәҗәгать итәләрме?

– Мин яңа эшләнмәмне тәмамлауга ук, аны күрше ханымнарга күрсәтәм. Чигешләр хәзер бик популярлашты бит. Аннары без, төрле яшьтәге туташ-ханымнар белән җыелып, шушы Калмия мәдәният йортында атнага бер тапкыр кич утырабыз, анда кем чигә, кем бәйли... Шунда да киңәшләр сорыйлар, тәҗрибәмнән чыгып, өйрәтәм дә. Кул эше белән вакытның ничек тиз үтеп киткәнен сизми дә калабыз. Без авылда да көне-төне иҗатта... Иң мөһиме: дөньялар тынычлануын телибез.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

● «Яраннар».

Гыйбрәтле фильм

Мостай Кәримнең «Ярлыкау» повесте буенча төшерелгән «Помилование» фильмында вакыйгалар сугыш фонында барса да, режиссер, беренче чиратта, кешеләр язмышын күрсәтүенә басым ясый. «Үлчәүнең бер ягында – закон, икенчесендә – намус, үлчәү кая баса – мәңгелек тема шунда», – диде Казанга фильмны тәкъдим итергә килгән режиссер Айнур Әскәров.

М.Кәримнең «Ярлыкау» повесте буенча төшерелгән фильм киң прокатка чыкты. Узган атнада аны Казанда беренче тамашачылар карый алды. Алар арасында Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм башка рәсми затлар бар иде.

Журналистларга фильмны аның режиссеры Айнур Әскәров, татар/башкорт егете Җантимер Байназаров ролен башкарган Николай Галләмов, Любомир Зух ролен башкарган Александр Новиков, Мария Тереза ролен башкарган Җәмилә Мөдәррисова һәм башкалар тәкъдим итте.

«Мостай Кәримнең шундый әсәренә алыну үзе бер бәхет – илһамланып эшләдек. Миңа калса, көчле драматургия һәм бүгенге көндә дә актуаль булган кызыклы сюжет беркемне дә битараф калдырмас», – диде режиссер.

«Фильмны М.Кәримнең туганнары – кызы Әлфия Мостаевна һәм оныгы – Тимербулат Кәримов белән бергә эшләдек. Мин бернинди оештыру эшләренә катышмыйча, режиссерлык эшен генә башкардым. Алай эшләү рәхәт икән, кофе эчеп, актерларга ничек уйнарга икәнен аңлатып кына утырасың», – дип дәвам итте ул.

Актер Николай Галләмов фильм төшерү барышында үзләренең хәрби киемнәрдә йоклауларын, телефоннар куллану тыелганлыгын әйтте.

«Минем өчен бу фильм мәхәббәт турында. Фильмның герое үземә охшаган – шундый хәлдә калсам, мин дә нәкъ аның кебек эшләгән булыр идем», – диде А. Новиков.

Фильмның үзәк вакыйгасы итеп яшь егет Любомир Зухның, сугышка да кереп өлгермичә, яраткан кызы янына барган өчен дезертирлыкта гаепләнеп, трибуналда атылуы алынган.

«Мостай Кәрим повесте буенча төшерелгән «Помилование» фильмын бик рәхәтләнеп карадым. Карарга киңәш итәм, бик гыйбрәтле тарих», – дип язды Р.Миңнеханов телеграм-каналына.

Тадеуш Мицинский хатларында татарлар

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яшәгән поляк язучысы Тадеуш Мицинскийның татарлар тормышын күтәргән хезмәтләре турында мәгълүмат күп түгел. Мицинскийның Польша-Литва һәм Казан татарлары белән шактый мавыктыргыч очрашуы Мәскәүдә Февраль инкыйлабыннан соң була.

Сүз дә юк, поляклар өчен мөселманнардан иң якыны электән үк татарлар булган. Мицинский бу хакта гомеренең соңгы айларында үз фикерен әйтеп калдырган. Ул берничә ел дәвамында Мәскәүдә яшәгән. 1917 елның май аенда Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда (ул 1-11 майда уздырыла) катнаша, ә Польша матбугаты аны «Татарлар корылтае» дип яза.

Язучы корылтай вакытында чыгыш та ясый әле. Мицинский үзе әйткәнчә, «очраклы импровизация»сендә ул татарларның Польшага күрсәткән игелекле гамәлләрен билгеләп үтә.

Аның чыгышыннан аңлашылганча, монда алар тоткан дин поляклыкны чикләми. Речь Посполитая территориясендә яшәүче татарлар, үз диннәреннән баш тартмыйча да, һәрвакыт Польшаның патриотлары, Бөек Литва кенәзләренә һәм Польша корольләренә хезмәттә кыю сугышчылар булдылар.

Докладчы «Польшаны бүлгәләү вакытында фәкать мөселманнарның намуслылыгы һәм тирән тугрылыгы гына протест белдерде. Моны Польша беркайчан да онытмаячак» дип искә төшереп үтә. Илһамланып ясаган чыгышында Мицинский «мөселманнарның азатителүе уңаеннан үзенең тирән шатлыгын» белдерә һәм поляклар белән татарлар арасындагы бәйләнешләргә генә түгел, югары мәдәни үсеш алган поляк-мөселман мөнәсәбәтләренә дә басым ясый. Үзен тыңлап утыручы татарларга поляк язучыларының (Мицкевич, Словацкий һәм Сенкевичны атый) бик теләп көнчыгыш мотивларга мөрәҗәгать итүләре, шулай ук «даһи мистик шагыйрь»не (сүз Руми турында) тәрҗемә итүләре (тәрҗемәчеләр дигәндә, үзен күз алдында тота) хакында да әйтеп уза. Аның чыгышы озын булмый, шуңа күрә бу документның Польша газетасында басылып чыккан вариантын тулысынча тәкъдим итәргә булдык:

«Мөселман кардәшләр!

Польшада татарлар күп яши, алар барысы да дини һәм граждалык хокукларыннан тигез файдаланалар. Мөхәммәд өммәте булып калсалар да, алар чын күңелләреннән Польшаның патриотлары һәм кыю сугышчылары булып хезмәт итәләр.

XVI гасырда ук инде Польшада «Гөлестан», «Йосыф белән Зөләйха» поэмасы һәм тагын күп кенә әсәрләрнең тәрҗемәләре басылып чыкты. Польша көнчыгыш белән көнбатыш сәүдәсен һәм мәдәниятен бәйләүче буын булды. Без көнчыгыш сәнгатеннән күп үрнәкләр үзләштердек. Безнең өчен тагын шул факт мөһим, Польшаны бүлгәләү вакытында фәкать мөселманнарның намуслылыгы һәм тирән тугрылыгы гына протест белдерде. Моны Польша беркайчан да онытмаячак.

Ә инде ярымай азатлыгы өчен көрәш барганда, поляк полклары сезгә ярдәмгә ашыкты. Поляк әдәбияты көнчыгыш тормышына багышланган әсәрләргә бай. Мицкевич «Фариса»ны язса, Словацкийда кыю Мирза Хәмид Абдулевич тасвирлана, Сенкевич «Сәлимә»не иҗат итә һәм тагын башка күп әсәрләр языла. Җәләлетдин Руминың шигъри әсәрләре поляк теленә тәрҗемә ителә. Бу даһи мистик шагыйрь XIII гасырда, сугыш вакытында Сәмәрканд белән Бохара мәдәнияте тармар ителгән чорда яши, әмма, Кече Азиягә күчеп китеп, дини поэзиянең тирән чагылышын саклап калуга ирешә. Аның поэмаларының берсенә нигезләп, поляк композиторы Шимановский гаҗәеп яңгырашлы музыкаль әсәр иҗат итә.

Сугыш туктауга ук без барыбыз да чистару-сафлану суына чумарга тиеш булабыз. Боларның барысын да безгә бай рухлы дөньясы исән калган Көнчыгыш бирәчәк.

Петроград өстендә мәчетнең сапфир төсендәге гаҗәеп матур гөмбәзе юкка гына балкып тормый. Ул күк йөзен безнең сокландыргыч хисләребезгә күмәчәк. Цивилизациянең бишеген, хәтта иң югары ноктасын тәшкил иткән көнчыгышка, Һиндстанга юл сезнең аша уза.

Көнчыгышта таң атты, һәм без ышанабыз, ул безгә ярдәмгә киләчәк!»

Әйтеп үтелгән чыгышыннан тыш, Мицинский әле корылтай турындагы тәэсирләрен «Татарлар Мәскәүдә» дигән мәкаләсендә дә дәвам итә. Ул анда поляклардан Мәскәүдәге Польша йортының мәдәният эшлеклесе (булачак күренекле геолог) Мечислав Лимановский белән икесе генә катнашуы хакында үкенебрәк яза. Текстында ул Россиядә 26 миллион мөселман (аныңча – «Мөхәммәд өммәте») яшәвен искәртә. Әмма, мәгълүм булганча 1917 елда аларның якынча исәбе 16 миллион чамасы тәшкил итә. Мицинский сүзләренә караганда, корылтайда 800 делегат катнаша, шулардан йөзләп хатын-кыз Мәскәүгә Казаннан турыдан-туры «Тигезлек» корылтаеннан килгән була.

Автор монда нәрсәгә аерым игътибар итә соң? Табигый ки, карашларга, нәкъ менә хатын-кыз күзләренә ул битараф кала алмый: «Алар арасында язучылар бар һәм чуар капланныкы кебек саргылт-бронза яки металлны хәтерләткән кара бәрхет төсендәге гаҗәеп матур күзле чибәркәйләр бар», – ди. Ул вакытларда кабул ителгәнчә, «типажлар»га аерып, мөселманнарның йөз төзелешенә кыскача тасвирлама бирә: «Индуслар тибындагы озын сакаллы, чал чәчле, бөркетнекедәй борынлы шәехләр дә бар. Нигездә алар – чалаган, энергияле, йөз төзелешләре үзенчәлекле, әмма азатлык хисе белән рухланган һәм, нииндидер, тәкъдиргә буйсындырылган дәртле типлар. Дала бөркетедәй чандыр, куркыныч типлар да бар. Күзләре кысык, җәлпәк борынлы калмыкны, Лев Толстой кыяфәтендәге картларны, славяннарны хәтерләткән типлар бар».

Мицинский корылтайның бәйрәм догасы белән башлануын болай тасвирлый: «Мулла, күзләрен йомып, Коръән сүрәсен чыгара. Тамак төбе белән, меланхолик экстазга бирелеп, гадәттә тартык авазлардан торган көйне суза. Барысы да аяк өсте басып, кулларын күкрәкләренә куялар». Ул корылтайда нинди телләрдә чыгыш ясауларына да туктала. Өч телне – татарча, алтай-төрки һәм рус телләрен санап үтә. Ә инде Урта Азиянең төрки телләре турында сүз барганда, үзбәк, кыргыз һ.б. телләрне атый. Мицинскийга кемнәрнең чыгышлары ошаган яки ул кем турында әйтүне кирәк санаган? Беренче чиратта Әхмәт Цаликовны искә ала. Милләте белән осетин Әхмәт Цаликов (1882-1928) – Кавказда танылган сәясәтче, меньшевиклар партиясенең актив әгъзасы. Ул, чыннан да, бик җитди шәхес – Россия номенклатурасы өчен проектлар әзерләүче башкарма комитет әгъзасы була. Берничә айдан соң, 1917 елның ноябрендә ул Ленин хөкүмәте составына керүдән баш тарта.

Корреспонденциясенең соңгы өлешендә Мицинский кабат Цаликовка, тәгълрәге аның «Кавказ турында» дигән әсәренә туктала.

Цаликов әфәнде үз әсәрендә «Прометей әле һаман шунда чылбырланган хәлдә һәм каргалар аның бавырын чукыйлар» дигән гыйбарәне раслап, хакимият түрәләренең законсызлыклары турында сөйли: «таулардагы барлык черкас халкын Төркиягә кудылар, аларның күбесе хәерчелектән һәм авырулардан дөнья куйдылар. Черкасларга милли мәктәпләр ачарга рөхсәт итмәделәр, аларның җирләрен тартып алдылар».

Минемчә, Мицинскийның Россия империясе мөселманнары кичерешләрен тирәнтен аңлавын үз халкының да җәбер-золымга дучар ителүе, суверенлыкларын һәм элементар хокукларын югалткан кавказлыларныкына охшаш булуы белән бәйләргә кирәк. Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында шагыйрь, нинди диндә булуларына карамастан, бу халыкларны активлаштырырга омтыла. Шуңа күрә, поляк шагыйренең әрмән, кыргыз, черкас һәм татарларны тугандаш халык итеп санавы беркемне дә гаҗәпләндерергә тиеш түгел. Ә татарларны Мицинский стереотиплар аша кабул итә, бу аның тарихи повестенда чагылыш таба. Анда ул татарларны «кысык күзле йөзләреннән танып була», дип яза.

ШАГЫЙРЬ

Соңгы елларда үзем өчен татар әдәбиятында яңа Шагыйрь ачтым, ул – шәһәрдәшем Айрат Суфиянов. Дөрес, аның «Кылычлы җил» китабы инде 2006 елда ук чыккан булган, узган ел «Таң калып багам таңнарга» дип аталган шигырьләр җыентыгы дөнья күрде.

Әмма мин аның шигырьләрен интернеттан табып укыдым, тел байлыгына, ихласлыгына сокландым, иҗатында күңел төшенкелеген сизеп, борчылдым, киңәшләремне бирдем. Аннан Айратның Башкортстаннан булуын, милли һәм дини каһарманыбыз Батырша хәзрәтнең якташы икәнен белдем, рухи тамырлары тирәндә икән, дип сөендем. Ул Иске Балтач районының Усман авылында туып-үскән, Нөркә урта мәктәбен тәмамлаган. Әле бу көннәрдә генә тагын бер «ачыш» ясадым – шигъри табышлары белән таң калдырган Шагыйрьнең югары филологик белеме юк, ул заманында Уфа энергетика техникумын тәмамлаган һәм 30 елдан артык Чаллыда, КамАЗның двигательләр заводында эшләгән. Үзе әйткәнчә, «кара», иң авыр эштә... Таш калада, тимер-томыр арасында ничек Айраттагы кебек нечкә тоемлауны, шигъри җанны саклап калып була – монысы әле минем өчен һаман ачылмаган серле могҗиза. Димәк, Аллаһтан аңа шундый көчле рух һәм нечкә күңел бирелгән булган...

Бер караганда, А.Суфияновның махсус филологик югары белеме булмау аны калыплашудан, стандарт кысаларга керүдән саклап калган кебек. Төрле әдәби мәктәпләрне белмичә һәм аларга иярмичә, ул үзендәге «табигый шагыйрьлекне» саклаган. Тукай, Дәрдмәнд, Такташлар да шигъриятькә югары уку йортлары аша түгел, тормышның үзеннән килә бит! Мин Айрат шигъриятендә Такташ символ-чалымнарын һәм якташы Әнгам Атнабаевның тормышчан фәлсәфәсен күрәм.

Әлбәттә, Айрат та яшьлегендә үк шигырьләр язып караган, аларның кайберләре җирле матбугатта басылып та чыккан. Алга таба тормышы бөтенләй башка юлдан китсә дә, ул күңелендәге шигырь утын сүндермәгән, матурлыкка соклануын, хаксызлыкка әрнүен ак кәгазьгә төшерә барган... Һәм менә алар укучыга барып ирешә, үз юлын, үз урынын тапты, халык мәхәббәтен яулады. Айрат Суфиянов шигырьләрен интернетта йөзләгән, хәтта меңләгән кеше укый, дистәләгән комментарий калдыралар, халык аны чын мәгънәсендә, үз шагыйре итеп кабул итә. Югыйсә, холкы буенча ул тыйнак кеше, үзен күрсәтү белән шөгыльләнми, интернетка да «Мәйдан» журналы хезмәткәрләре «җитәкләп» алып кергән, китаплары да бик озак ятып, тилмертеп кенә дөнья күргән. Ә чын шигырь барыбер үз укучысын тапкан! Безнең халык шигъриятне ярата, талантны таный, аңа үз вакытында дөрес бәясен бирә, шунысына мең шөкер!

А.Суфиянов турында матбугатта язмалар аз, иҗатына да әле әдәби тәнкыйтьчеләр тарафыннан тулы бәя бирелмәгән, анализ ясалмаган. Алай да, аның 2007 елда Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителүен, рекомендациясе танылган шагыйрь Равил Фәйзуллин бирүен әйтеп үтәргә кирәк, димәк, Айратның талантын ул вакытта ук таныганнар! Шулай ук «Казан утлары» журналы һәм «Мәдәни җомга» газетасы да аның шигырьләрен бастырып чыгарды, халык аларны яратып кабул итте. «Мәйдан» журналының быелгы март санында язучы Лилия Гыйбадуллинаның каләмдәше турында «Яратыгыз мине!...» дип аталган бик ихлас мәкаләсе дөнья күргән, ул аның яңа китабына шагыйранә бәя биргән. «Шагыйрьнең лирик герое – караңгы чорда, өметсезлек дәверендә кешеләр күңеленә яктылык илтүче, аларны хак сүзе, шигърияте белән яктыртучы буларак чыгыш ясый... Бу китап – шагыйрьнең кадергә сусап тилмерү ачысы да, үзен-үзе тану юанычы да, мәхәббәте дә, сагышы да. Чичәнлек юлы, шагыйрь кадере, миссиясе турында ул үз тормыш-халәте мисалында гына түгел, үзеннән элгәре җирдән үткән каләм әһелләре язмышларына, иҗатларына нисбәтле дә уйлана, нәтиҗәләр ясый».

Автор А.Суфияновның күңел халәтен дөрес тотып алган, ул да, безнең кебек, «караңгылыктан да яктылык эзләүче» Шәхес. Чын шагыйрь, чын кеше башкача була да алмый, «Йөрәгемне ямау итәр идем / Гасырларның каплап ярасын», ди ул үзенең бер шигырендә. Мине Айратның көтелмәгән чагыштырулары, сүзләрдән кабатланмас сурәтләр тудыру осталыгы, акылның әллә нинди тирәнлекләреннән актарып, символ-тамгаларны кузгатып чыгаруы гаҗәпләндерде һәм сокландырды. Мин шигърият белгече түгел, әмма шигырь җаныма һәм аңыма тәэсир иткән икән, ул үз бурычын, миссиясен үтәгән, дигән сүз. Ә моны бары тик талант иясе генә башкара ала.

Чор кагында безнең кайсыбыз соң
Канәгатьлек таба үзеннән?
Канга, яшькә баткан фани дөнья
Карап тора бәгърең күзеннән.
Сәбәпчесе – бәндә, туемсыз зат,
Нәфес колы кайсы чорда да
Тереклекнең аккош муенына
Буар елан булып чорнала, – ди шагыйрь, үзенең «Ямьле, җылы язлар алдадыр» дигән шигырендә. Әйе, кешенең нәфесе – ул «аккош муенына чорналган буар елан» кебек, аңа ирек бирсәң, бар тереклекне харап итәчәк. Һәм шул хәлләр бара да инде. А.Суфияновның бу темага язганнары шактый, аларда кайвакытта өметсезлек тә сизелә, шагыйрь үзе дә җанына терәк эзли.

Океандагы боз тавыдай йөзеп барам,
Ярга – ерак, якынлашмый һаман арам.
Куркам, куркам әрергә дә... туфан басар,
Төпкә китәр Нух көймәсез
тимер гасыр...

Адәм баласы каршына килеп баскан мәңләгән сорау... Күбесенә җавап та юк кебек. Чарасызлык җанны телгәли. Шагыйрь җаны бу хәлләрне бигрәк тә авыр кичерә, ул һәр чорда шулай булган...

Чиксезлектә киңәергә теләп,
Талпынсаң да тарлык тоясың...
Аяусызлык иле – чынбарлыкта
Козгын чукый тургай оясын...

Һәм шушыларны белгәч, бу хәлләр үз башыңнан кичкәч тә, яшәргә кирәк бит әле, каяндыр көч табарга кирәк! Шагыйрь өчен ул көч чыганагы – күктә Аллаһ, җирдә – туган туфрак. Шулар арасында – ул үзе, бөтен вөҗүде һәм иҗаты. Айрат Суфияновның туган авылы турында шигырьләре бик күп, ул аның һәр урамын, һәр куагын, һәр кошчыгын тавсирлап язды бугай инде, әмма язган саен яңача! Әйе, шагыйрьне күңел юанычы үткәннәрдә, җирдә булса, акылы белән ул инде күкләргә ачкыч эзли. Һәм шушы илаһи эзләнү, илаһи табыш аны барлык өметсезлекләрдән коткара, мәңгелеккә нурлы юлын күрсәтә...

... Очраклылык түгел, эзлеклелек
Тудырган да безне кеше иткән.
Мең-мең юллар алда... Бердәнбер юл –
Аллаһ юлы – камиллеккә илткән... –
дип нәтиҗә ясый ул. Татар шагыйреирешергә тиешле бөек хакыйкать, милләткә тапшырылырга тиешле изге әманәт бу! Ни кызганыч, соңгы йөз елда татар шигърияте илаһи юлдан читкә тайпылды, кыйбласын югалтты, нурын җуйды... Бу хәл милләтнең әхлагына да нык тәэсир итте, бүгенге телсезлек, динсезлек, манкортлык шуның да ачы нәтиҗәсе инде. Шөкер, бүгенге татар шагыйрьләренең күпчелеге Аллаһ биргән талантын Аллаһ юлында куллана, милләткә илаһи дөреслекне җиткерә.

Бу көннәрдә Чаллының Татар дәүләт драма театрында А.Суфияновның гомер бәйрәмен билгеләп үттеләр, шулай ук аның яңа китабын да халыкка тәкъдим итү булды. Шәһәребез зыялылары, каләмдәшләре, сәнгать әһелләре шагыйрьгә зур хөрмәт күрсәтте, ул үзе исә шигырьләрен укыды. Ирләрчә җитди, бу хәтле зур игътибарга оялган-уңайсызланган кебек иде ул, әмма балаларча самими куаныч та бар иде аның йөзендә... Мин Айрат өчен куанып утырдым. Кеше кадере, талант кадере, милләт кадере менә шушы була инде ул! Безгә иң җитмәгән һәм иң кирәк нәрсә. Бигрәк тә – бүгенге иң болганчык көннәрдә... бер-беребезнең исән чагында кадерен белик!

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.

«Татар» этнонимын тикшерергә кирәк

Тарих институтында «Урта гасырлар чыганакларында «татарлар»: этнонимның тарихи язмышы» темасына беренче халыкара семинар узды. Фәнни чарада Казан галимнәреннән тыш, видеоэлемтә аша Венгрия, Төркия, Мәскәү, Санкт-Петербург, Улан-Удэ, Томск институтларының фәнни хезмәткәрләре катнашты.

«Татар этнонимы 1600 ел элек язылган Кытай чыганакларыннан килүе мәгълүм. Аннан тыш, ул гарәп, фарсы, төрки, рус, латин һәм башка чыганакларга кергән. Татар сүзе төрле гасырларда, төрле язма традицияләрдә кулланылган. Әйтергә кирәк, ул традицияләр бер-берсе белән бәйле дә түгел, әмма бу исемне алар барсы да кулланганнар. Бу исем халыклар, идарәчеләр турындагы язмаларда күренә, географик атамалар буларак кулланыла. Әлеге терминның нәрсә аңлатканы төгәл билгеле түгел», - диде Тарих институтының Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге җитәкчесе Илнур Миргалиев .

Аның сүзләренчә, борынгыдан килгән күпкырлы «татар» сүзен тулысынча беркем өйрәнмәгән. Тарих институты аны төрле яклап өйрәнеп, киләчәктә монография әзерләргә җыена. Моның өчен халыкара семинарлар аша төрле төбәкләрнең, илләрнең галимнәре җәлеп ителәчәк. Апрель ахырында узган семинар – шуларның беренчесе иде.

XIII йөз гарәп тарихчысы Ибне әл-Асирда азмы-күпме тәфсилле тасвирлама бирә. Ул монгол явы вакытында серле кавемнең каян килеп чыкканын белергә теләп килә, аны төрки халыклар: кыргызлар, төрекмәннәр, кыпчаклар төркемена кертеп теркәп калдыра.

«Урта гасырларда татар исеме астында безнең халык барлыкка килә. Ул төрки халыкларны берләштерә торган атама булган. Без шуннан үсеп чыкканбыз. Алтын Урда чорына кадәр булган тарих тиешенчә өйрәнелмәгән. Монгол яуларын оештырган халыкның ни өчен татар дип аталуы да төгәл билгеле түгел. Дискуссияләр бүген дә бара. Рус чорында татар сүзе политонимга әверелеп, рус булмаган бөтен халыклар татар дип йөртелгән вакытлар да була. Татар атамасы киң мәгънәдә кулланыла алырлык универсаль термин вазыйфасын үтәгән. Казан ханлыгы чорында чын мәгънәсендә татар милләте формалаша», – диде Илнур Миргалиев.

Рифат КАЮМОВ.

Җәберләнгән татар

Татар җәмгыяте, күп гасырлар буе үзенең асылын, тамырларын саклап калу өчен көрәшеп, алга таба үсү мөмкинлекләрен эзләп яшәде. Татар зыялылары халыкның мәгарифкә, югары мәдәнияткә, әхлакка ия булса гына дөньяның алга киткән илләрендәге кебек, заман таләпләренә җавап бирә алырлык, югарылыкта сакланачагын аңлап эш иткән. Шул максатта татарның игелекле байлары мәгарифкә ярдәмнәрен кызганмыйча, белемгә омтылган яшьләргә теләктәш булган. «Татарда уңганлык белән тырышлык бар, диләр. Менә шулар өстенә югары белем, югары культура, югары әхлак та булырга тиештер инде, – дип язган иде аксакал әдибебез Әмирхан ага Еники. – Шул сыйфатларга ия булган чакта гына ул үзен дөнья мәйданында таныта алачак... Әмма моның өчен ике нәрсә – байлык белән мәгърифәт кирәк. Шушы ике нәрсә безне революциягә кадәр көтелмәгән югарылыкка күтәргән дә инде... Россиядәге төркиләр арасында без бик хаклы рәвештә иң алга киткән халыктан санала да башлаган идек» (Мәдәни җомга. 2004. 17 декабрь).

● **Әхмәтгәрәй Хәсәни.**

Инде халыкны шундый югарылыкка күтәргән мәгарифне һәм андагы шәхесләрнең революциядән соңгы язмышларына күз салыйк. Ни кызганыч, Октябрь инкыйлабыннан соң ук большевиклар хакимияте зыялыларга карата репрессияләрне башлап җибәрә. Дәлилләү өчен 162 галимне (философларны), пароходка утыртып, илдән куып җибәрүләрен генә искә алыйк. Куылганнар арасында Казан университеты галимнәре – ректор Овчинников (1874–1936), психиатр Г.Трошин (1874–1937), профессор И.Стратонов (1881–1942) та булган. 1922 елның көзендә тагын 200 кеше (бу юлы галимнәр генә түгел, ә инженерлар, әдәбиятчылар, агрономнар, табибләр һ.б.) куыла. Болар гына аз тоелгандыр, күрәсең, илнең баш чекисты Ф.Дзержинский шушы вәзгыятьтә үзенең ярдәмчесе И.Уншлихтка: «На каждого интеллигента должно быть дело», дигән күрсәтмә бирә (Знамя. 1992. №3. С.133). Бу күрсәтмәнең ничек тормышка ашырылганын олуг әдибебез Ф.Әмирхан бик ачык итеп язып калдырган. «Турысын әйтергә кирәк, – ди ул. – ЧК – пожалуй, бөтен Совет аппараты эчендә иң кызу, иң тизлек белән һәм үзенчә иң мөсаһәләсез эшли торган бер аппараттыр. Әгәр төзү, гыймарәт (төзелеш), эшләп чыгару, халыкның тормышын җиңеләйтү юлында эшли торган аппаратларның берсенә шушы ЧКга бирелгән кадәр әһәмият бирелсә, бәлки РСФСРда шактый нәрсә төзелер, халыкның тереклеге дә шактый җиңеләер иде» (Ф.Әмирхан. Әсәрләр: Дүрт томда. IV том. – ТКН, 1986. Б.191.).

Мәгълүм булганча, татар халкына җиңеллек килмәгән шул. 1917–1925 еллардагы Татарстан тарихына күз салсак, халык өстенә төшкән бәла-казалар санап бетерерлек түгел: гражданнар сугышы, тиф эпидемиясе һәм безнең җиребездә аеруча киң җәелгән 1920–1921 еллардагы коточкыч ачлык. Республика мәгарифе бу чорда бюджетта каралып бирелергә тиешле булган ярдәмне дә ала алмаган.

1918 елның 21 гыйнварында Совет хөкүмәте диннең – мәктәптән, ә мәктәпнең диннән аерылуы турында декрет кабул итә. Бу декрет гомер буе милли мәгарифне, халыкның яшәеш тәртибен саклап килгән дин әһелләрен төрлечә мыскыллауга, түбәнсетүләргә юл ача, законлаштыра. 1918 елның июнь аенда чыккан декретта болай диелә: «Кызыл Армиядә хезмәт итүдән азат булган 18 яшьтән алып 45 яшькә кадәрге барлык гражданнар тыл ополчениеләренә чакырыла». Бу законга барлык дин әһелләре эләгә. Алардан юл салу һәм ремонтлау, утын әзерләү, төяү һәм бушату өчен хезмәт батальоннары төзиләр. Күп җирдә мәчетләр эшләүдән туктарга мәҗбүр ителә.

Тоталитар режимның репрессияләре дә халыкның иҗат эше белән шөгыльләнгән өлешенә, иҗтимагый фикердә һәм милли-мәдәни хәрәкәттә мөһим роль уйнаган хөр карашлы катлавына юнәлә. Милли хәрәкәтнең иң күренекле вәкилләре Г.Исхакый, С.Максуди, Ф.Туктаров һ.б. илдән китәргә мәҗбүр була. Чит илгә китәргә үгетләүләргә дә карамастан, «Советларга минем зыяным тимәде», дип, үзен ышандырырга тырышкан «Иттифак» фиркасен оештыручыларның берсе, аның Үзәк Комитеты әгъзасы, «Азат» газетасы мөхәррире (1905), Печән базары мәчете мулласы, үз акчасына мәдрәсә ачкан Габдулла Габделкәрим улы Апанаев 1919 елның 28 июнендә үк кулга алына һәм 25 сентябрьдә атып үтерелә. Шундый олуг зат, халык тормышында мәртәбәле урын тоткан абруйлы галимне хаксызга гаепләп юк иткән залимнәрнең җәзасыз калуы алдагы репрессияләргә, нахак хөкем карары белән меңнәрчә зыялыларның гомерләре киселүгә, концлагерьларга озатылуга, Себер тайгаларында, кырыс табигатьле төньяк өлкәләрендә авыр кол хезмәтенә тартылуга, кыйнау-рәнҗетелүләргә юл ачып җибәрә. Татар халкы биргән бу корбаннарның төгәл санын хәзер ачыклап бетереп тә булмый. Ә бит аларның күбесе калебләре, ягъни эчке рух камиллеге белән Совет хөкүмәтен бөтенләй кабул итә алмаса да, революция вәгъдә иткән якты киләчәк һәм милли үсеш хакына иҗади эшләрен дәвам иттерергә тырышкан, аңа карата лояль мөнәсәбәт саклаган зыялы кешеләр була. 20 нче елларда ук аларның иҗат мөмкинлекләре чикләнә башлый. Гарәп хәрефен латин әлифбасына күчерү мәсьәләсендә (1925–1926 еллар) бу чикләүләр бөтен кискенлеге белән алга чыга. Гарәп шрифтын яклап чыгучылар, мәгариф, мәдәният тарихы язмышы күзлегеннән чыгып түгел, «татар буржуасының сыйнфый интересы белән» бәйләнгән сәяси вакыйга итеп бәяләнә. Гарәп әлифбасын яклап матбугатка мөрәҗәгать белән чыккан татар зыялылары (барысы 82 имза) «пролетариат диктатурасына, марксизм идеологиясенә каршылар, бу хәрәкәтне үзләренең контрреволюция оешмалары өчен файдаланырга тырышучылар» дип бәяләнә. Кул куючылар арасында 28 мәгариф хезмәткәре дә бар. Аларның киләчәк язмышлары ни белән беткәне инде ачык.

1926 елда бер төркем зыялылар, «Яңа китап» нәшрияты төзеп, татар классикларының әсәрләрен нәшер итүне җайга салмакчы була, бигрәк тә Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд әсәрләрен, Коръәнне нәшер итү теләге белән йөри. Нәшрият төзергә хакимияттән ризалык алынган булса да, 1930 елда наширларның барысы да кулга алына. Алар арасында Әхмәтгәрәй Хәсәни (революциягә кадәр чыккан әдәби-иҗтимагый «Аң» журналы мөхәррире), Шиһаб Әхмәров («Мәктәп» журналы мөхәррире), Ибраһим Бикколов (Идел-Урал төбәгендә генә түгел, хәтта Урта Азиядә танылган әдәбиятчы, укытучы, милли хәрәкәттә актив катнашучы), Галимҗан Шәрәф (тарихчы-галим, педагог), Хәбибрахман Зәбири (укучылар өчен дәреслекләр авторы, «Сабах», «Өмет» нәшриятлары хуҗаларыннан берсе) һәм атаклы мәгърифәтче Фатиха Аитованың улы, Мәскәү коммерция институтын тәмамлап, нәшриятны оештыруны башлап йөрүчеләрнең берсе Ибраһим Аитов һ.б. кулга алына. «Мәктәп» журналының кулга алынган редакторы Шиһаб ага Әхмәрев төрмәдә үзләренең нинди газапларга дучар булганлыгын язып калдырган. Архивта саклана.

1930 еллар башында ук мәдрәсәләрдә укыту белән бергә, фәнни хезмәтләре белән дә дан казанган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең уку-укыту эшләре бүлеге мөдире Әхмәтҗан Мостафин, Уфадагы «Галия», «Әнәсия» мәдрәсәләре мөдәррисе, фәлсәфи хезмәтләр авторы Зыя Камали (Парвазетдин Камалетдинов), «Хөсәения» мәдрәсәсе мөдире, Мәрҗани мәчете имамы, ачлык елларында Төркиягә барып Татарстан халкына ярдәм җыйган Таһир Ильяси (1933 елда сөргендә ачтан үлә), Казандагы 6 нчы таш мәчет имамы, ачлык хакына шул ук 1921 елда Төркестанга барып ярдәм җыйган, оста каллиграф, рәссам Садыйк әл-Иманколый, Уфадагы «Госмания» мәдрәсәсе мөдәррисе, «Ислам мәҗәлләсе» журналы мөхәррире, Диния нәзарәтенең ачларга һәм ятим балаларга ярдәм итү комиссиясе (ул Мәскәүдә урнашкан була) рәисе Кашшафетдин Тәрҗемани, Оренбургтагы атаклы кызлар мәдрәсәсе җитәкчесе Багбостан Мөэминова һ.б. бик күпләр кулга алына, төрмәләргә ябыла, үтерелә.

Шушы хәвефле 1930 елларның мәгариф өлкәсендәге хаксызга рәнҗетелгән корбаннарын саный китсәк, исемлек коточкыч озын килеп чыгар иде. Татарстан мәгариф халык комиссарлары – Микъдәт Борындыков (1922–1924 еллардагы), Нәсыйх Мөхетдинов (1924–1928), Исхак Рәхмәтуллин (1928–1931), Галиәсгар Биктаһиров (1932–1934) исемнәрен әйтеп үтәм. Аларның тормыш юлы бераз өйрәнелде кебек. Нинди талантлы, затлы зыялы шәхесләр булганнар! Алар язган фәнни хезмәтләрне укыганда фикер тирәнлегенә сокланмый калып булмый. Исән булсалар, татар мәгарифе, фәне никадәр алга китәр иде. Алар язган хезмәтләрне укучылар да башкачарак фикерләү сәләтләре дә күпкә югарырак булыр иде. Аларның фаҗигасе – безнең фаҗига, татар халкы фаҗигасе.

Шушы ук фикерләрне Казан педагогика институты галимнәре хакында да әйтәм. Безнең Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институтының мәгариф тарихы һәм теориясе бүлеге хезмәткәрләре, «Татар педагогик фикер антологиясе» өстендә эшләп, күп кенә педагогларыбызның тормыш юлын, педагогик хезмәтләрен

мәгарифе

● Ибраһим Бикколов.

● Хәбибрахман Зәбиров.

өйрәнде. Нинди генә талантлы педагогларыбыз булган һәм юк ителгән икән! Алар, бүгенге кайберәүләр кебек, кеше хезмәтләреннән, компьютердан күчереп, фәнгә ямау салмаган, үзләре язган, үз сәләтләрен, үз талантларын эшкә биргән. Минә ирле-хатынлы Илһамия апа белән Якуб абый Богдановичлар. Якуб абыйның татар һәм башкорт балаларына рус телен өйрәтү буенча язган методик хезмәтләре бүген дә үз кыйммәтен югалтмаган. Ә Илһамия апа – 1927 елларда ук «Мәктәптән тыш тәрбия» темасына фәнни мәкаләләр язган талант иясе. 1937 елда икесе дә кулга алына. Якуб абыйның төп гаебе – Петербург университетын тәмамлауда, җитмәсә, чыгышы белән дворян булуда, ул шунда ук атып үтерелә. Илһамия апа 17 ел төрле төрмә, концлагерьларда тилмерә. Аның хакында «Ил язмышын салып иңнәренә» дигән китабымда яздым. 1921 елда Богдановичларны Симферопольдән Мәскәүгә, РСФСР Мәгариф комиссариатында эшләргә А.Луначарский үзе чакыртып кайтара. Бу – аларның хезмәтенә бирелгән зур бәя. 1927 елда алар Татарстан хөкүмәте чакыруы буенча Казанга кайта һәм мәгариф системасын төзүгә искиткеч зур өлеш кертә.

Казан финанс институтында укыткан, бер үк вакытта Казан мәгариф хезмәткәрләре белемен күтәрү институты ректоры (1925–1935) булып эшләгән Зәйнулла Нигъмәтуллин 1934 елда ук югары уку йортлары өчен «Аналитик геометрия» дәреслеген язган. Тәрҗемә итеп түгел, татар балалары өчен махсус язган, аның әлеге хезмәте галимнәр арасында иң югары бәяне алган. 1937, 1949 елларда бу талант иясе ике тапкыр кулга алынган. Кайчан гомере өзелгәне билгеле түгел.

Арон Әхмәтовның да тормыш юлы ахыргача өйрәнелмәгән. Казан педагогика техникумы укытучысы булган ул. 1921 елгы ачлыкта Татарстан балалары чит өлкәләргә озатыла башлагач, Тула шәһәренә татар балаларын озата барган һәм, әлеге калада калып, балалар өчен татар мәктәбе ачкан һәм үзе үк укыткан да (!). Балаларны Казанга кире алып кайта алган олы йөрәкле сирәк кешеләрнең берсе булган бу изге зат. Кайткач, укытучылар институтында укыткан, татар мәктәпләрендә сүзлекләр белән эшләү хакында фәнни мәкаләләр язган. Хәзерге Яшел Үзән районы Күгеш авылында туган бу шәхеснең безгә билгеле булган тормышы 1936 елда өзелә. Бәлки, бүген дә аның хакында белүчеләр бардыр әле.

Совет хөкүмәте юлламасы белән Германиягә барып, Берлин университетында укыган (1923–1925), кире әйләнеп кайтканнан соң, Мәскәү педагогика институтын тәмамлаган, Казан педагогика институтында укыта башлаган, диссертациясен төгәлләү алдында җиткән Мәрьям Мозаффарова 1938 елда кулга алына. 1941 елның 11 сентябрендә Орел төрмәсеннән чыгарылып, урманда атылган 161 тоткын арасында татарның бу талантлы кызы да була. Үлгәнче Казан, Ярославль, Владимир, Орел төрмәләрендә бары бер сүз әйткән бичара: «Мин гаепле түгел!» Аны еш кына сулы карцерларга утырталар, үлем күлмәге кидертеп җәзалыйлар. Сулы карцерда кычкыргач, резин карцерга тыгалар. Туберкулез белән авырый башлагач та, бернинди дә ярдәм күрсәтмиләр.

Мондый язмышлар томнарга язсаң да бетәрлек түгел. Укыганда йөрәк кенә чыдасын! Хәер, хәзер архивлар ябык инде, тарихыбызда алтын багана булырлык шәхесләребез язмышының юкка да чыгуы бик мөмкин. Мәгарифебезнең бүгенге хәле белән чагыштырганда милли җанлы мондый шәхесләребезне югалту фаҗигасе тагын да тирәнәя төшә. Бүген татар мәктәпләренең ябылуын, укучы балаларның юлларда күргән михнәтләрен ничек аклап булыр икән? Шул бер сәясәтнең дәвамы бит инде бу.

2011 елда Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институтында репрессияләнгән татар мөгаллимнәре язмышына багышлап фәнни конференция үткәрелгән иде. Олы дәрәҗәле галимнәр катнашында үткәрелгән әлеге чара тарихыбызда беренче мәртәбә булды. Чыгыш ясаучыларның да, журналистларыбызның да теләкләре бер төрле иде: татарның бер генә мәгърифәтчесе дә онытылмасын, илдә 30 нчы еллар фаҗигасе бүтән кабатланмасын иде!

Педагогика институтының репресияләнгән татар галимнәрен исемнәрен хөрмәт белән искә алыйк әле, рухлары шатлансын:

Җамал Вәлиди (1887-1932)
Газиз Гобәйдуллин (1887-1937)
Сәлах Атнагулов (1893-1937)
Әхәт Әхмәтов (1898-1938)
Нури Йосыпов (1888-1937)
Газыйм Касыймов (1891-1937)
Гаяс Максудов (1891-1942)
Зыя Насыйров (1889-1937)
Галимҗан Нигъмәти (1897-1941)
Мирсәет Сафин (1893-1937)
Фатих-Сәйфи Казанлы (1888-1937)
Нигъмәт Хәким (1889-1937)

Тәэминә БИКТИМИРОВА,
тарих фәннәре кандидаты.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

13 май (шимбә). ***Шәүвәл аеның 23 нче көне.23 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 12.02 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.07 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Язгы ширбәт

Яшь тузганак яфракларын юып, суын саркыталар, турыйлар. Пыяла банкага шикәр белән аралаштырып һәм агач тукмак белән төя-төя тутыралар. Шикәре эреп бетеп согы чыкканчы тәрәзә төбендә тоталар, аннан соң суыткычта саклыйлар. Мондый ширбәтне чәйгә салып эчү бик файдалы. Яңа җыелган тузганак яфракларын исә салатка кушарга була.

14 май (якшәмбе). ***Шәүвәл аеның 24 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 3.11 сәгатьтә калка, 13.37сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.11 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмау зарур.

Майда җыеп кал!

Май аенда бака яфрагы үләнен тамыры белән казып алалар, яхшылап юып, киптерәләр, иттарткычтан чыгаралар. 200 г үләнгә 100 г бал кушып, карасу төстәге пыяла савытта 3-4 көн тотәтәләр. Ашказаны җәрәхәтен дәвалау өчен, көн саен иртән ач карынга һәм кичен 1 әр аш кашыгы кабалар.

15 май (дүшәмбе). ***Шәүвәл аеның 25 нче көне.25 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 3.20 сәгатьтә калка, 15.08 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.14 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Гайморитттан – йодлы су

Бер стаканга якын кайнаган җылы суга 1 тамчы йод, 1 бөртек марганцовка салып болгаталар да, 3-5 көн дәвамында мөмкин кадәр ешрак итеп һәр борын тишегенә 2-3 әр тамчы тамызалар.

16 май (сишәмбе). ***Шәүвәл аеның 26 нчы көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 3.28 сәгатьтә калка, 16.38 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.18 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Сирень сихәте

Тромбофлебит интектергәндә, сирень яфрагын изеп, җәрәхәтләргә ябалар. Беренче 2 көндә яфракны 3 тапкыр, аннары

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

1 тапкыр алыштыралар. Баш өянәге (мигрень) вакытында маңгайга сирень яфрагы куеп бәйлиләр, 2-3 сәгатьтән соң яңасын ябалар.

17 май (чәршәмбе). ***Шәүвәл аеның 27 нче көне.27 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында,3.36 сәгатьтә калка, 18.07 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.22 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Фасоль дәвалый

Кандагы шикәр микъдарын киметү өчен, 3 данә ак фасоль борчагын ярты стакан кайнаган салкын суга салып, төнгелеккә калдыралар, иртән фасолен ашыйлар, суын эчәләр. Болай дәвалану диабет белән чирләүчеләрнең канындагы шикәр микъдарын да киметә ала.

18 май (пәнҗешәмбе). ***Шәүвәл аеның 28 нче көне.28 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 3.46 сәгатьтә калка,19.36 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.25 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Кычыткан чәе

Яңа җыелган бер уч яшь кычыткан яфрагын 2 л кайнап торган суга салалар, яхшылап томалап, 10 минут төнәтәләр. Үлән аска утыргач, сөзәләр. 2 атна буе, көн саен, 15-19 сәгать аралыгында эчәләр (шушы 2 л төнәтмә 2 атналык курска җитәргә тиеш). Аннан соң 2 атна ял итәләр һәм кабат шулай дәваланалар. Кычыткан суы кандагы холестерин микъдарын киметә, организмны витаминнарга һәм минераль матдәләргә баета, бөер, бәвел куыгы, ашкайнату әгъзалары эшчәнлеген җайга сала.

19 май (җомга). ***Шәүвәл аеның 29нчы көне.29 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 3.58 сәгатьтә калка,21.04 сәгатьтә бата. 18 сәгать 53 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 16.28 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Берниди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур. Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый.

Тозлы печенье

250 шәр г он, атланмай һәм брынза (яки башка тозлы сыр), 1 йомырка сарысы кирәк. Май, эре угычтан уылган брынза һәм оннан йомшак кына камыр басып, җәяләр, төрле формада печенье кисеп, күпертелгән йомырка сарысы белән майлыйлар, эре тоз сибәләр дә, газ мичендә пешереп алалар. Яраткан кеше борыч сипсә дә була.

Истәлекле җыелыш

Озак еллар Татарстан энциклопедия институтында эшләгән дустым Марс Гаитовның чакыруы буенча, Татарстан Фәннәр академиясендә уздырылган җыелышта катнашырга туры килде. 1994 нче елда республиканың Фәннәр академиясе составында Татарстан энциклопедия институты оештырыла. Академия президенты Мансур Хәсәнов бу институтның директоры, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган фәнни хезмәткәре Гомәр Сабирҗанов аның урынбасары һәм институтның җаваплы редакторы булып билгеләнә. 2017 елга кадәр, 25 ел эшләү дәверендә, 600-700 әр битле энциклопедиянең 6 томы рус телендә, 7 томы татар телендә нәшер ителә. Бу энциклопедия китапларында Татарстан тарихында катнашы булган 9685 күренекле шәхесләребезнең исемнәре теркәлгән.

1960 нчы елларда союздаш республикаларда үзләренең энциклопедияләрен яза башлый. Автономияле республикаларга андый хокук бирелмәгән була. Шулай да, 1970 нче елларда Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Ф.А.Табиев партиянең үзәк комитет секретаре М.Сусловка бу турыда мөрәҗәгать итеп карый. Аның мөрәҗәгате, Ф.А.Табиевка «Партийная нескромность» дигән хурлыклы бәһа бирелеп, кире кагыла.

Үзгәреш заманнары башланып киткәч, күренекле галимнәребездән Казан дәүләт педагогика институты ректоры Мирфатыйх Зәкиев һәм Гомәр Сабирҗанов үз энциклопедиябезнең кирәклеге турында республика җитәкчелегенә мөрәҗәгать итә. Тәкъдим кабул ителеп, Гомәр Сабирҗанов җитәкчелегендә институт үзенең эшен башлап җибәрә.

Гомәр Салих улы 1955 елда Ульяновск шәһәрендәге педагогика институтының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң, Тува Республикасына эшкә җибәрелә. Анда 13 ел эшләү дәверендә республика халкы өчен изгелекләр кылуын күреп алып, Тува башкаласы Кызыл шәһәрендә партиянең бүлек җитәкчесе итеп билгеләнә. 1961 елда 29 яшьлек Гомәр Сабирҗановны Тува өлкә комитеты бренче секретаренең ярдәмчесе итеп куялар.

1968-1971 нче елларда, Гомәр Салих улы Мәскәүдә Үзәк комитет карамагындагы Академиядә укып белем ала, кандидатлык диссертациясен яклый. Укуын тәмамлап кайткач, Татарстан хөкүмәте составында бүлек җитәкчесе булып эшләгәндә, аны Казан дәүләт мәдәният институтында яңа ачылган кафедраның җитәкчесе итеп билгелиләр.

Гомәр әфәнденең Тува Республикасында башкарган игелекле хезмәте искә алынып, 90 яшьлек юбилее уңаеннан Казанның Халыклар дуслыгы йортында Тува Республикасының иң дәрәҗәле бүләге – «Буян – Бадыргы» ордены тапшырыла.

Татарстан Фәннәр академиясендә Гомәр Сабирҗановның 90 яшьлек юбилеена һәм аның институт эшчәнлегенә багышлап язылган «Татарская энциклопедия: краткий очерк истории создания» китабы тәкъдим ителде. Җыелышны институт директоры Искәндәр Гыйләҗев алып барды. Күп галимнәр катнашкан әлеге җыенда Гомәр Салих улының хезмәтенә зур бәһа бирелеп, аңа Татарстан Фәннәр академиясенең иң дәрәҗәле бүләге – Алтын медаль тапшырылды. Гадәттә, мондый медаль белән академикларны гына бүләкләүләр югыйсә.

Аксакал галим кунакларга үз китапларын бүләк итеп өләште. Аны лаеклы хөрмәтләгән бик истәлекле кичә булды.

Рәфкать ИБРАҺИМ.
Казан.

МК тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

12 май – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
13 май – «Рәшә» (Ә.Еники).
14 май – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).
15 май – С.Сайдәшев исемендәге дәүләт зур концерт залы бинасында – Камал театры оркестрының «Әрем исе, әрем тәме...» дип исемләнгән концерты. Солист – Әсхәт Хисмәт.
16 май – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров).
17 май – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
18 май – Кече залда 18.00 – Буа Татар дәүләт драма театрының «Дәрвиш» спектакле (Н.Хәсәнов). Зур залда 19.00 – «Сөясеңме, сөймисеңме...» (Ф.Бүләков).
19 май – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

12–30 май – Р.Нуриев исемендәге халыкара классик балет фестивале.
12 май – «Спящая красавица» (П.Чайковский).
14 май – «Лебединое озеро» (П.Чайковский).
15 май – «Корсар» (А.Адан).
17 май – «Алтын Урда» (Р.Ахиярова).
19 май – «Анюта» (В.Гаврилин).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

12 май – «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев).
14 май – «Гомер буе сине көтәм» (И.Гали).
15 май – «Мәдинә» (И.Зәйниев).
16 май – «Хыялый» (С.Әбүзәров).
17 май – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
18 май – «Идегәй» (татар халык дастанына нигезләнгән).
19 май – «Ашина» (Р.Зәйдулла).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

12 май – «Ак чәчәкләр кебек...» (Р.Мухина).
13 май – «Тапшырыл...ган хатлар» (Г.Кутуй).
14 май – «Әлифба» (Әхмәтҗанова, Э.Яруллина, Ф.Насыйбуллин). 20.00 – Премьера. «Яралу» перформансы. (Е.Музеева).
16 май – Сәхнә арты буенча сәяхәт.
17 май – 12.00 – «Хәтер» исемле язгы концерт. 18.30 – «Ләйлә вә Мәҗнүн» (Н.Ганҗәви, Ю.Тупикина инсценировкасы).
18 май – 13.00 – Сәхнә арты буенча сәяхәт. 18.30 – «Йосыф» (Кол Гали).
19 май – «Сөннәтче бабай» (Г.Исхакый).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

12 май – 12.00 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әсәре буенча). 19.00 – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).
13 май – Зур залда – «Золушка» (Е.Шварц). Кече залда – «Котбетдин мажаралары» (Н.Гернет).
14 май – Фойеда – «Тыпырдык» (И.Зәйниев). Зур залда – «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин).
17 май – Зур залда – «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин). Кече залда – «Я люблю Вас, Надя!» (А.Чехов).
18 май – «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин).
19 май – «Аладдин» (гарәп әкиятләренә нигезләнгән).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

12 май – Үзбәкстанның «Бахор» дәүләт бию ансамбле концерты.
16 май – Танылган композитор Сергей Рахманиновның 150 елыгына багышланган камера-вокаль музыкасы концерты.
17 май – «Бразилиядән сәлам» дип исемләнгән джаз концерты.
18 май – «Туган йортка илткән юл» исемле вокаль музыкасы концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

12 май – Р.Абзаов җитәкчелегендәге La Primavera Казан камера оркестрының танылган композитор Сергей Рахманиновның 150 еллыгына багышланган «Ак сирин рыцаре» исемле концерты.
13 май – С.Рахманинов исемендәге XII халыкара «Ак сирин» фестивале кысаларында Татарстан дәүләт симфоник оркестры концерты. Дирижер – Хаожань Ли. Солист – Константин Хачикян.
17 май – С.Рахманинов исемендәге XII халыкара «Ак сирин» фестивале кысаларында Татарстан дәүләт симфоник оркестры концерты. Дирижер – Эдуард Топчин. Солист – Иван Бессонов.

Кирам САТИЕВ кытыклары

Татарлар һәркайда

Татарлар дөньяның төрле төбәкләрендә яши. Хәтта Америкада – татар сүзе – Әмир ага. Кыктән җиргә төшеп дигәндәй, Россиягә кайтыйк. Себер якларында күп йөргә туры килде. Себер үзе үк татар сүзе – «себерә»дән алынган. Анда булганнар буранның ничек себергәнен белә. Татарлар иң күп яшәгән төбәкләрнең берсе – Төмән өлкәсе. Декабристларны Себергә каторгага сөрәләр, ягъни катарга, өшергә. Каторжаннар – катар җаннар ул. Тундрасы да татар сүзе – туңдыра. Төмән өлкәсендә инде ул татар сүзләре, татар атамалары! «Төмән»не «томан»нан алынган диләр.

Себердәге татар сүзләрен махсус эзләмәдем, бары – күзләдем генә: Барнаул – борынгы авыл. Надым – Назыйм шәһәре, Салехард – Салих карт. Тобольск – тубал – савыт. Бер баруда Обь елгасының да халкыбызның «Әби» сүзеннән алынганлыгын әйттеләр. Ангара елгасын «аңгыра» диләр, чөнки Байкалга 300 елга коя, ә берсе генә – аңгырасы гына агып чыга, алып чыга. Байкал үзе үк татар сүзе – Бай күл. Ә күл атамалары буа буып, үзе бер күл ясарлык: Иссык куль – эссе күл, Чебаркуль – чибәр күл, Каракулино – каракүл, Сарапул – сары күл...

Телевизорда «яңа» кешеләр пәйда булды, әйтик, Максим Салюков – Мәгъсүм Салихов, Руслан Цаликов – Арслан Салихов инде ул асылда. Ныклап тикшерсәң, бәлки туганнардыр да әле. Җырчы Газманов – Госманов, Еримеев – Ярымаев, Еникеев – Җаныкаев, Ермолаев – җор малай, Емельянов – Гыйлемҗанов (Җәмилҗанов), бәлки, Сәлимҗановтыр. «Чук и Гек»ны язган А. Гайдар – Хәйдәр. Колонтай – колын тай дигәннән чыккан. Спортчы – Лев Яшин – чынлап та яшен иде бит! Кемдер әйткән: урысны тырнасаң – татарны табарсың, диген. Хак сүзләр. Алай гына да түгел, әйтик, Л. Вайкуле – Бай күлле (Балтыйк буенда күлләр күп). Профессор Осипов – Хасипов, галим Курчатов – корыч ат (Курчаков). Хәтта җигүле атны туктату да татарча: тр-р-р, туктап тор, басып тор. «Жигули» сүзе дә «Җигүле ат»тан алынган лабаса.

Мәскәүдәге «Арбат»ның арбалы ат икәне күпләргә һәм күптән мәгълүм. Чит ил сүзләре – татар сүзләре: немесләрнең «хайл», инглизләрнең «хеллоу»лары татардан алынган: сүзнең тамыры – беренче өч хәрефе – хәл белешү, ягъни мәсәләп, ни хәл дигәнне аңлата. Телефон трубкасын алгач, дөньядагы барлык кешеләр дә беренче сүзне татарча әйтә: алло – алам, алдым...

Афоризмнар – кирамизмнар

** Төркемдә артистлар, язучылар, җитәкчеләр һәм кешеләр бар иде.*

** Башка килмәгәнне язып булмый, башкага килгәнне язып була.*

** Акыллы булу өчен акыл гына җитми.*

** Үткән гомер әрәм түгел, әрәм үткән гомер әрәм.*

** Аракы зыянлы, агу, диләр. Елан агуы белән кешене дәвалыйлар. Хикмәт микъдарда.*

** Аю корбаның исен берничә километрдан, ГАИ хезмәткәре берничә сантиметрдан сизә.*

** Юл бер генә, юнәлешләр – күп.*

** «Үз илемдә – үз көем» гыйбарәсенең дөресрәге: үз өемдә – үз көем.*

** Хатын-кыз җитәкче түгел, җитәкләүче булсын.*

** Киңәшне йә дошман бирә, йә – юләр.*

** Чүп чиләгенә чиста су салмыйлар.*

** Җаваплылыктан котылу ысуллары: шулай дип әйттеләр, кемнәндер ишеттем, югарыда хәл ителгән, халык соравы буенча, һәм... «мин» диясе урында «без» сүзен еш куллану.*

** Һәр милләттә ике аяк, ә татарда ул өч – анысы татарга аяк чалыр өчен.*

** Кыйммәтле машинада, гадәттә, арзан кешеләр йөри.*

** Дәрәҗәле урында дәрәҗәсезләр утыра.*

** Татар телен яклаучы, саклаучы – күз буяучы. Әгәр ул чын-чынлап моңа тотына икән, аны йә тәрәп аталар,йә Магаданга озаталар.*

** Бер галим мең наданнан артыграк.*

** Бер юләрнең соравына мең акыллы җавап бирә алмаска мөмкин.*

** Бары тик елан гына туры юлда боргалана.*

** Елгасы кипкәч, ярлар кушыла.*

** Кичә эшендә гаделлек эзләгән кеше, бүген яңа эш эзли.*

** Исеңдә тот: артыгын кыланма, сикерсәң дә күпме, тишә алмассың күкне.*

** Үлгән артыннан үлеп булмый, диләр. Дөрес түгел. Үлгән алдыннан үлем булмый – монысы хак.*

** 100 гә кадәр яшә, диләр бәйрәмдарга. Дөрес түгел. 100 дән соң да яшә, дияргә кирәк.*

Шакиров шаяруы

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә Минхәмәт Гыйләҗев белән Ө. Хәмидуллинның «Сөйгәнем күрше авылда» җырын өйрәнеп утырабыз: «Сөйгәнем күрше авылда ерак икәнен беләм, ерак димим, барып җитәм караңгы төшү белән». Җырлап бетергәч, ишек шакып, әдәп-әхлак нормаларына туры китереп, И. Шакиров килеп керде. Хәл-әхвәл сорашкач, сүзләрен дөрес җырламыйсыз, диде. Ничек язылган, шулай өйрәнәбез. Һәм Илһам абый үз вариантын җырлап күрсәтә: ...«Ерак димим, барып җитәм, бәрәңге пешү белән»...



Алмазга тапшырдык!

Радиога яңа җыр яздык: А. Хәмзин җырлады, мин уйнадым.

– Сине өеңә, подъезд төбеңә кадәр илтеп куям, – диде җырчы һәм өстәп куйды: кайда Кирам, шунда – ихтирам.

Җылы машинага кереп утыргач, белгән юл догаларымны укыдым һәм «Алмазга тапшырдык», – дидем.



Әҗәл

Хәлем бик тә начарлангач, «скорый» белән алып киттеләр. Юлда барганны хәтерләмим. Урын булмау сәбәпле, коридордагы топчанга сузып салганнар. Саташам, алмашам...

Шулчак кемдер: әҗәл килә, диде. Тапкан шаярыр вакыт!... Күземне ачсам: Равил Шәрәфи басып тора!

– Менеке пүчтәк кенә, бүсернең җепләрен алдырырга килдем. Бар көчемне җыеп торып утырдым.

– Борчылма, – диде Равил абый. – Яшибез әле. Әҗәл мәсьәләсен үзем хәл итәм, – диде һәм бер мәзәк сөйләде.

Бу юлы да әҗәл мине урап узды. Равил абый күңелемне күтәреп, яртылаш терелтеп китеп барды.

Япь-яшь бүреләр

Узган гасырның 80 нче еллар башы. Армия хезмәте беткәч, филармониягә кире эшкә кайттым. Яшьләр бригадасы оештырып, гастрольгә җибәрделәр. Концерт беткәч, сәхнә артына бер тамашачы кереп, бүреләрне мактап җырлаганны беренче ишетәм, диде.

– Сез дөрес аңламагансыз, – диде жырчы һәм кабат җырлап күрсәтте: бөреләр, бөреләр, нинди яшь бөреләр...

Миңнуллин – тамада

Концертның өченче бүлегеп – чәй эчү, диләр артистлар. Р.Миңнуллин – тамада, мин – баянчы. Зал зур, кеше күп (ашаганда, гадәттә, кеше күп була инде ул). Кемнең кайда икәне күренми. Роберт абый исемлек буенча сүз бирә. Торып баскан ораторны тамада күреп алды һәм шаярып әйтеп куйды: коллегабызның чәйнәп йотканын көтәбез һәм ул күп тә үтмәс бер сәгатьтән сөйли дә башлар, диде.

Ялгызлар озак яши

Җирдә барлыгы 8 миллиардд 75 миллионнан артыграк кеше яши, әмма шулардан берничә йөзе генә 110 яшькә җитә алган. Аларның озак яшәү сере нидә? Кайберләре, мәсәлән, Шотландиядән 110 яшенә җитеп дөнья куйган Джесси Галлан, үзенең озын гомерле булуын ир-атлардан башка, гомере буе ялгыз яшәвеннән күргән. Ул 1906 елда бик ярлы гаиләдә туган һәм 13 яшеннән эшли башлаган – башта фермада сыер сауган, аннары кунакханәдә хезмәтче, ресторанда официант булып көн күргән. 109 яшендә бакыйлыкка күчкән британияле Мэделайн Дай да шул фикердә булган. Ул Шеффилд шәһәрендә туган, әнисе һәм апасы белән туган йортында яшәгән (әтисе Беренче бөтендөнья сугышында һәлак булган). Китап төпләүче булып эшләгән, бәйләргә, бакчада казынырга яраткан. Кияүгә чыкмаган, бәби тапмаган. Әмма туганнары фикеренчә, аның озын гомер сере – физик активлыгында: көн саен җәяү эшкә барганда, Мэделайн шактый текә тауга менә торган булган. Бик олыгайгач кына, ул картлар йортына күченгән. Италиядә 118 яшендә вафат булган Эмма Морано да ялгыз яшәүне файдалыга санаган. Унтугызынчы гасыр азагында туып, монархияне бәреп төшерү, Муссолини хакимлеге, ике бөтендөнья сугышы һәм җитмешенче еллардагы террорчылык котыруына шаһит булган бу хатын-кыз 55 яшенә кадәр джут фабрикасында капчык тегә, аннары 20 ел буе католиклар интернатында ашарга пешерә. Галлан һәм Дай кебек үк, Морано да гомеренең күп өлешен ялгыз үткәрә, әмма, алардан аермалы буларак, ул кияүгә чыгып ала. Яраткан егете Беренче бөтендөнья сугышында һәлак булгач, 26 яшьлек Эмманы көчләп кияүгә бирәләр. 1937 елда баласы үлгәч, ул яратмаган ирен куып чыгара, шуннан соң инде рәхәтләнеп ялгыз яши.

(“The Local”).

Эскимослар ризыгы

“Эскимос” сүзе “чи ит ашаучы” дип тәрҗемә ителә, шунлыктан алар үзләрен “инуит” дип атауны мәслихәтрәк күрә, бусы исә “чын кеше” мәгънәсендә йөри. Чукотка ярымутравында, Гренландия утравында һәм АКШ белән Канаданың иң салкын төбәкләрендә яшәүче әлеге аз санлы төньяк халкының кайбер гадәтләре һәм ризыклары цивилизацияле дөнья вәкилләрен гаҗәпкә калдыра. Халыкның төп ризыгы – кит, морж, тюлень, болан, ак аю ите, аларны чи килеш тә, пешереп, каклап, туңдырып, тозлап та ашыйлар. Эскимослар көн саен диярлек тюлень каны эчә, аның исләнгән маен, шулай ук чи кит маен ашый, һәм бу организмнарын сәламәтләндерә, каннарын түкландыра, дип ышана. Ә иң деликатес ризыклары кивиак – эченә 400 ләп акчарлак тутырылган тюлень түшкәсе икән. Кошларны йолкымыйча, чистартмыйча тутыралар, аннары тюлень корсагындагы бөтен һаваны кысрыклап сытып чыгарып, түшкәне май катламы белән каплыйлар һәм барлыкка килгән “ярымфабрикатны” 3-18 айга таш белән бастырып куялар. Кырыс шартларда яшәргә күнеккән эскимослар А һәм D витамины запасын балык һәм хайван бавыры ашап тутыра, С витаминын исә суүсемнәрдән, тюленьнең баш миеннән, кит тиресеннән ала. Ирләр туктаусыз тәмәке тарта, хатыннар һәм балалар аны чәйни, хәтта елаган имчәк баласын тынычландыру өчен дә тәмәке яфрагын чәйнәп каптыралар.

(“Die Presse”).

Бавыр төнлә эшли

Төнлә йоклаганда организмда нинди үзгәрешләр була соң? Кичке сәгать унда канда лейкоцитлар саны икеләтә арта, тән температурасы төшә. Биологик сәгать сигнал бирә – йокларга вакыт. Сәгать унбердә тәндәге киеренкелек тагын да кими, әмма һәрбер күзәнәктә торгызылу процессы бик актив бара. Сәгать уникедә аңны төш күрүләр баса, ә баш мие исә хезмәтен дәвам итә – көн буена тупланган мәгълүматны кирәкле “киштәләргә” урнаштыра. Бер тулганда, йокы бик сизгер. Шунлыктан бу вакытта теш сызлый башласа, таңга кадәр йоклап булмый. Сәгать икедә барлык әгъзалар ял итә, бавыр гына тулы куәтенә эшли – йоклаган организмны шлаклардан чистарта. Өч тулганда, физиологик төшенкелек күзәтелә: артериаль кан басымы – түбәнгә чигендә, пульс һәм сулыш алу бик акрын бара. Иртәнге сәгать дүрттә баш миенә кан бик аз килә, ә менә ишетү сәләте нык сизгерләнә. Сәгать биштә бөерләр, мускуллар ял итә, матдәләр алмашы бик нык әкренәя. Алты тулганда, канга адреналин бүленеп чыга, организм уянырга әзер, тик аң йокымсырый әле. Иртәнге сәгать җиде – дарулар иң шәп үзләштерелә торган вакыт.

(“The Washington Post”).

Истәлекле фото

Бу фотодагы иң кечкенә сабый – Боряны (үзәктә) Бөек Ватан сугышы вакытында немец муенындагы шарфына асып куячак, әмма әнисе соңгы мизгелдә баласын коткарып калачак. Сугыштан соң ул эшче һөнәре алачак һәм радиолампалар заводында эшләячәк. Ике кырыйда баскан ике өлкән баланы немецлар Германиягә куып алып китәчәк, әмма алар юлда барганда качып, Кызыл Армия гаскәрләренә килеп кушылачак. Сугыштан соң Валентин балта остасы һөнәрен сайлаячак, Зоя исә, шәфкать туташлары курсларын тәмамлап, Гжатск шәһәрендәге балалар хастаханәсендә эшләячәк. Ә менә урындыкта утырган энекәшләре - Юра – 1961 елның 12 апрелендә кешелек тарихында беренче булып космоска очачак һәм бөтен дөньяны таң калдырачак. Клушино авылы, 1938 ел. Валентин, Борис, Зоя һәм Юрий Гагариннар.

(“t.me/dmitrynikotin”).

Дөге суы үстерә

Кытайның көньягындагы тауларда урнашкан Хуанлу “Озын чәчлеләр авылы” буларак танылган һәм Гиннесснең рекордлар китабына кертелгән. Биредә яшәүче хатын-кызларның сумаладай кара чәченең уртача озынлыгы 2,1 метр тәшкил итә, һәм ул картайгач та агармый. Сере гади – биредә шампуньнең нәрсә икәнен дә белмиләр, борынгыдан калган гадәт буенча, чәчне дөге пешкәннән соң калган су белән юалар. Элек заманда Хуанлуда хатын-кызның тузган чәчен күргән һәркемне аның гаиләсенә кол иткәннәр һәм өч ел эшләткәннәр. Бу закон 1980 еллар азагында гына юкка чыгарылган, чөнки озын чәчле гүзәлләрне күрергә килүче туристлар хәерче авыл өчен төп керем чыганагына әйләнгән. Авылда 400ләп кеше яши. Хатын-кызлар туристлар каршында чәчләрен туздырып бии һәм акча эшли – аена 300 доллар

чамасы җыела. Хуанлуда кызларның чәчен нибары бер тапкыр – 18 яшь тулгач кисәләр, әбиләре шуннан декоратив баш киеме ясап бирә, аннары аны иренә бирнә сыйфатында бүләк итәләр. Җирле “шампунь” бик җиңел ясала: дөге пешкәннән соң калган суны бүлмә температурасында тәүлек буе әчетәләр дә, тагын бер тапкыр кайнатып чыгарып, берничә тамчы эфир мае өстиләр, шуның белән чәчне юалар.

(“Интересно.cc”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

15 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «СТАЛИННЫ ЮК ИТҮ ЯШЕРЕН ОПЕРАЦИЯСЕ». 12+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татар халык җырлары».
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00, 0.25 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Көчтәнәч».

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.40, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.40 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.30 «Калеб». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «МОЛОДАЯ ГВАРДИЯ». 16+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
14.50 «История русской еды». 12+
15.20 «Романовы. Царское дело». 12+
16.20 «ПРАКТИКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ТРЕЙДЕР». 16+
23.55 Подкаст.лаб «Пусть не говорят, пусть читают». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР. ВОСЕМЬ ЛЕТ СПУСТЯ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Всеволод Крестовский.
7.35 «Блеск и слава Древнего Рима».
8.35 «Жизнь и судьба».
8.55 «Забытое ремесло».
9.10, 22.15 «КОРОЛЕК - ПТИЧКА ПЕВЧАЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.15 «Роботы... роботы... роботы...»
11.50, 21.50 «Феодосия. Дача Стамболи».
12.20 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».
12.45 Новости. Подробно. АРТ.
13.00 Линия жизни. Мира Кольцова.
14.00 «ЛЮБИМАЯ ДЕВУШКА».
15.25 «Алгоритм Берга».
15.55 «Агора».
17.15 «Бег». Сны о России».
17.55 Симфонические шедевры России XIX-XX веков. Н. Мясковский. Симфония №17.
18.45 Острова. Владимир Трошин.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Мой мастер Класс».
23.05 «Кинескоп» с Петром Шепотинником.
23.45 «Магистр игры». «Свидетельство портретов».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БОРЩИ». 16+
22.15, 0.00 «ЧИНГАЧГУК». 16+

Сишәмбе

16 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СТАЛИННЫ ЮК ИТҮ ЯШЕРЕН ОПЕРАЦИЯСЕ». 12+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Төймә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Татар халык җырлары».
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Көчтәнәч».

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Нәсыйхәт». 16+
12.05, 18.20, 21.25 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «МОЛОДАЯ ГВАРДИЯ». 16+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
14.50 «Дворянские деньги». 12+
15.20 «Романовы. Царское дело». 12+
16.20 «ПРАКТИКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ВОСТОК-ЗАПАД. СЕЗОН 2». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ТРЕЙДЕР». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР. ВОСЕМЬ ЛЕТ СПУСТЯ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 14.15 «Блеск и слава Древнего Рима».
8.35 «Жизнь и судьба».
8.55, 17.40 «Забытое ремесло».
9.15, 22.15 «КОРОЛЕК - ПТИЧКА ПЕВЧАЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.15, 23.45 «Мужчина и женщина. Мстислав Запашный».
12.00 «Испания. Теруэль».
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00 «Влюбиться в Арктику».
13.30 «Игра в бисер» «Алексей Толстой. «Гиперболоид инженера Гарина».
15.05 «Ускорение. Пулковская обсерватория».
15.30 «Сати. Нескучная классика...»
16.15 «Приключения Аристотеля в Москве».
17.15 «Передвижники. Иван Шишкин».
17.55 Симфонические шедевры России XIX-XX веков. С. Рахманинов. Симфония №3.
18.45 Острова. Кир Булычев.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.30 «Белая студия».
22.55 Цвет времени. Микеланджело Буонарроти. «Страшный суд».
23.05 «Москва глазами... Владимира Гиляровского и Михаила Пыляева».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БОРЩИ». 16+
22.15, 0.00 «ЧИНГАЧГУК». 16+

Чәршәмбе

17 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СТАЛИННЫ ЮК ИТҮ ЯШЕРЕН ОПЕРАЦИЯСЕ». 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
15.45 «Татар сүзе». 6+
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем…». 12+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
21.00, 0.25 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.40 «Йөрәктән-йөрәккә». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
20.30 «Гаилә учагы». 16+
22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК-ЗАПАД. СЕЗОН 2». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
14.50 «Дворянские деньги». 12+
15.20 «Романовы. Царское дело». 12+
16.20 «ПРАКТИКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ТРЕЙДЕР». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР. ВОСЕМЬ ЛЕТ СПУСТЯ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Раскрытие тайн Вавилона».
8.35 «Жизнь и судьба».
8.55 «Забытое ремесло».
9.10, 22.15 «КОРОЛЕК - ПТИЧКА ПЕВЧАЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.15, 23.45 XX век. «Праздник оперетты. Имре Кальман».
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00 «Влюбиться в Арктику».
13.30 «Вся жизнь. Мария Кнебель».
14.15 «Блеск и слава Древнего Рима».
15.05 «Властелины кольца. История создания синхрофазотрона».
15.30 «Белая студия».
16.15 «Поездка для души. Кто упрям - тому на Валаам».
17.15 «Библейский сюжет».
17.45 Симфонические шедевры России XIX-XX веков. А. Скрябин. Симфония №3 «Божественная поэма».
18.35 Цвет времени. Леонид Пастернак.
18.45 Острова. Евгений Леонов.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.30 Власть факта. «Россия в судьбе Монголии».
23.05 «Москва глазами... Андрея Белого и Михаила Булгакова».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БОРЩИ». 16+
22.15, 0.00 «ЧИНГАЧГУК». 16+

Пәнҗешәмбе

18 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». 16+
10.00, 0.15 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.20 «СТАЛИННЫ ЮК ИТҮ ЯШЕРЕН ОПЕРАЦИЯСЕ». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.10 «Сөенеч».
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
15.45 «Татар сүзе». 6+
16.00, 18.00, 21.10, 22.10 «Семь дней+. Казаньфорум». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.25 «Безнең Республика - безнең гамәл». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 16+
15.25 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
22.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК-ЗАПАД. СЕЗОН 2». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
14.50 «Дворянские деньги». 12+
15.20 «Романовы. Царское дело». 12+
16.20 «ПРАКТИКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ТРЕЙДЕР». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.

9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР. ВОСЕМЬ ЛЕТ СПУСТЯ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 14.15 «Раскрытие тайн Вавилона».
8.20 Дороги старых мастеров. «Лоскутный театр».
8.35 «Жизнь и судьба».
8.55, 15.05 «Забытое ремесло».
9.10, 22.15 «КОРОЛЕК - ПТИЧКА ПЕВЧАЯ».
10.15 «Наблюдатель».
11.15, 23.45 «По ту сторону рампы. Сентиментальное путешествие Владимира Сошальского».
12.20 Цвет времени. Карандаш.
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00 «Влюбиться в Арктику».
13.30 Искусственный отбор.
15.20 «2 Верник 2».
16.15 «Верея. Возвращение к себе».
17.15 Пряничный домик. «Облачные ткани Узбекистана».
17.45 Симфонические шедевры России XIX-XX веков. П. Чайковский. Симфония №5.
18.30 «Первые в мире».
18.45 «История одного МИРа».
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Александр Ливергант. «Агата Кристи: свидетель обвинения».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Кавказская пленница». Это же вам не лезгинка, а твист!»
21.30 «Энигма. Азиза Садыкова».
23.05 «Москва глазами... Марлена Хуциева и Саввы Кулиша».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БОРЩИ». 16+
22.15, 0.00 «ЧИНГАЧГУК». 16+

Җомга

19 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.20 «СТАЛИННЫ ЮК ИТҮ ЯШЕРЕН ОПЕРАЦИЯСЕ». 12+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
15.15 «Татар сүзе». 6+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00, 20.15, 21.00, 22.10 «Семь дней+. Казаньфорум». 16+
18.00 «Родная земля». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
23.20 «ПОНАЕХАЛИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 15.25, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30, 16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Йөрәктән-йөрәккә». Фуад Вәлиев турында телеочерк. 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
18.20 Концерт «Җырларымда син генә». 16+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК-ЗАПАД. СЕЗОН 2». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ПЛЮС ОДИН». 16+
14.35 «Наукограды». 12+
15.00 «Дворянские деньги». 12+
15.30 «Романовы. Царское дело». 12+
16.20 «ПРАКТИКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «ГОЛОС». 12+
23.50 «Вызов. Первые в космосе». 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Удивительные люди. Новый сезон». 12+
23.35 «Истории Большой Страны». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 16.15 «Гатчина. Свершилось».
8.20 Дороги старых мастеров. «Вологодские мотивы».
8.35 «Жизнь и судьба».
8.55 «Забытое ремесло».
9.15 «ЦВЕТ БЕЛОГО СНЕГА».
10.20 «НАСРЕДДИН В БУХАРЕ».
11.45 Цвет времени. Владимир Татлин.
12.00 Открытая книга. Александр Ливергант. «Агата Кристи: свидетель обвинения».
12.45 «Первые в мире».
13.00 «Влюбиться в Арктику».
13.30 Власть факта. «Россия в судьбе Монголии».
14.15 «Раскрытие тайн Вавилона».
15.00 «По следам космических призраков».
15.30 «Энигма. Азиза Садыкова».
17.15 Письма из провинции.
17.45 Симфонические шедевры России XIX-XX веков. Д. Шостакович. Симфония №10.
18.45 «Билет в Большой».
19.45 Искатели. «Либерея: в поисках потерянной библиотеки».
20.30 Линия жизни. Мария Александрова.
21.30 «МОНОЛОГ».
23.05 «2 Верник 2».
23.55 «СИНЕВА В СИНЕВЕ».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «БОРЩИ». 16+
22.15 «ЧИНГАЧГУК». 16+

Шимбә

20 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.10 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Синең Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 Концерт «Мирас». 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 «Вдовы». Видеоверсия спектакля театра «Форма Т». 16+
16.40 «Уроки истории». 6+
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КВН РТ-2023». 16+
23.00 «ЖМОТ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Бәхетем башкаласы». 6+
7.00, 15.00 «Синең Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина концерты. 6+
17.20 «Казаннан Казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Рәхмәт, тормышымда булган өчен». Айгөл Бариева концерты. 16+
22.10 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». 16+

«ЭФИР»

5.00 «Наукограды». 12+
5.30 «Великие полководцы». 16+
6.00 «Тайны нашего кино». 12+
6.30 «Русь». 12+
7.00 «Белка и Стрелка. Тайны космоса».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Тайные механизмы природы. Сезон 2». 12+
8.30, 14.40 «Забытое ремесло». 12+
8.45 «КОГДА НАСТУПИТ РАССВЕТ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «СРОЧНО! ИЩУ МУЖА». 16+
14.55 «А дома лучше». 12+
15.45 «ПЕТЛЯ ВРЕМЕНИ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «МЫ КУПИЛИ ЗООПАРК». 12+
23.10 «СВЕТ И ТЕНЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ 5». 12+
16.10 «Байконур. Первый на планете Земля». 12+
17.00 «Прыжок из космоса». 12+
18.20 «Кто хочет стать миллионером?»
19.20 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.50 «ДЕВЯТЫЙ КАЛИБР». 18+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.40 «Доктор Мясников». 12+
12.45 «ПАРОМЩИЦА». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «СТАРАЯ РАЗВАЛИНА». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.55 «РАСПИСАНИЕ НА ПОСЛЕЗАВТРА».
9.20 «Мы - грамотеи!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Лесной дворец Асташово».
10.45 «НАЧАЛО».
12.10 Больше, чем любовь.
12.55 «История одного МИРа».
13.40 «Передвижники. Иван Шишкин».
14.10 «Даты, определившие ход истории».
14.40 «Зебры - черная полоска, белая полоска».
15.30 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.40 «Забытое ремесло».
17.00 «НЕ БОЙСЯ, Я С ТОБОЙ!»
19.45 Линия жизни.
20.35 «ОТЕЦ».
22.00 «Агора».
23.00 «БЕСПЛОДНАЯ КУКУШКА».

«НТВ»

5.00 «Жди меня». 12+
5.45 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Модный vs Народный». 12+
14.20 «Своя игра».
15.20 «Игры разумов».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.25 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 18+

Якшәмбе

21 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Болгар радиосы» бәйрәм концерты. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Туган авылым». 12+
10.00 «Тархан». 12+
10.20 «Изге Рамазан». 6+
10.45 «Изге Болгар җыены-2023».
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Музыкаль мәйдан». 16+
13.55 «Сөенеч».
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 «Патриаршия Божественная литургия из собора Казанской иконы Божией матери». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ТРАНЗИТ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Гомеремнең бер елы». Ришат Төхвәтуллин концерты. 16+
9.00, 15.25 «Йөрәктән-йөрәккә». 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.45 «Изге Болгар җыены». 6+
12.05, 0.50 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.45 «Кайда сез, яшьлек еллары». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 0.00 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 «Зур туган көн концерты». Гөлназ Сәфәрова. 16+

«ЭФИР»

5.00 «Наукограды». 12+
5.30 «Великие полководцы». 16+
6.00 «Тайны нашего кино». 12+
6.30 «Русь». 12+
7.00 «Белка и Стрелка. Тайны космоса».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Тайные механизмы природы. Сезон 2». 12+
8.30 «Забытое ремесло». 12+
8.45 «ПЕТЛЯ ВРЕМЕНИ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ТЕТЯ КЛАВА ФОН ГЕТТЕН». 16+
14.45 «Блин. Ком». 16+
15.45 «КОГДА НАСТУПИТ РАССВЕТ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЛЮБОВЬ И СТРАСТЬ. ДАЛИДА». 16+
23.10 «СВЕТ И ТЕНЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Космические истории». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.10 Концерт «Felicita на бис!» 12+
15.55 «Польша. Отравленные ненавистью». 16+
16.55 «Мариуполь. Возвращение домой». 16+
19.00 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.45 «Арт и Факт». «Призрак». 16+

«РОССИЯ»

6.10 «ХРАНИ ЕЁ ЛЮБОВЬ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.40 «Большие перемены».
12.45 «ПАРОМЩИЦА». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Мультфильмы.
7.40 «НЕ БОЙСЯ, Я С ТОБОЙ!»
10.10 Диалоги о животных.
10.55 «ОЧЕРЕДНОЙ РЕЙС».
12.30 Невский ковчег. Теория невозможного. Леонид Тарасюк.
13.00 М/ф «Храбрый портняжка». «Капризная принцесса».
13.50 «Игра в бисер» «Сказки братьев Гримм».
14.30 «Коллекция».
15.05 «РАСПИСАНИЕ НА ПОСЛЕЗАВТРА».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Забытое ремесло».
17.25 «Пешком...»
17.55 «Миры профессора Бобровского».
18.35 «Романтика романса».
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 «Глеб Панфилов. Своя тема».
21.15 «НАЧАЛО».
22.45 «Создавая сегодня». Гала-спектакль современной хореографии на сцене Парижской оперы.

«НТВ»

4.55 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер! 60+». 6+
23.00 «Звезды сошлись». 16+

Эчкендә янгын – милли фаҗига

Курган өлкәсендә котырынган урман янгыннары Шадрин районындагы Йолдыз (элекке атамасы – Эчкен) исемле татар авылын тулысынча диярлек юк итте. 400ләп хуҗалыктан 90 йорт кына исән калган.

Инде 7 майдан бирле Курган, Төмән һәм Сверловск өлкәләрендә урманнар яна. Көчле җил һәм көннәр эссе тору сәбәпле, алар тиз арада зур мәйданнарга таралды. Курган өлкәсендә гадәттән тыш хәл режимы игълан ителде. Табигать бәла-казалары адәм балаларын аз гына да кызганып тормый.

Бай тарихлы, бик борынгы Йолдыз авылы бу дәрәҗәдәге куркыныч фаҗигане үз гомерендә беренче тапкыр күрә. Урман ягыннан килгән ут өермәсе кырык минут эчендә гөрләп яшәп яткан авылны көлгә әйләндергән. Иң авыры – өйләреннән чыгып өлгермичә һәлак булган кешеләр дә бар.

«Урал арты татарлары» җәмгыяте рәисе Марат Юнысов сүзләренчә, янгыннар Курган өлкәсенең ике татар авылына зыян салган. Изге күл дигән авылда ике йорт янган. Бу – бары тик татарлар гына яши торган авыл, анда татар мәктәбе дә бар. Авылны саклап кала алганнар.

«Янгын Йолдыз авылына күршедәге рус авылыннан өске яклап, агач башлары буенча килде. Дистә чакрым чараны 2-3 минут эчендә үтте. Җилнең тизлеге секундына 40 метрга кадәр җитте. 40-45 минут эчендә бөтен авылны ут ялмап алды. Авылдагы 360 торак йорттан 90 йорт кына исән калган (бу гараж, сарай, мунча кебек корылмаларны санамыйча). Биредә меңләп кеше яши иде, шуларның җиде йөзләбе өйсез калды.

Мәчеткә янгын килеп җитмәгән. Мәктәп бинасын да коткарып кала алдылар. Мәктәп хәзер каза күрүчеләргә гуманитар ярдәм күрсәтү пункты буларак хезмәт итә. Авылның күпчелек халкы шунда урнашты. Документларын да алмыйча, йортларыннан көчкә чыгып өлгергән кешеләр дә бар. Халыкны биредә җылы ризык белән тәэмин итәләр. Электр энергиясе генераторлар хисабына бирелә. Тирә-күрше авыллардан, шәһәрләрдән, башка төбәкләрдән күпләп гуманитар ярдәм төягән машиналар килә. Безнең татар үзәге дә иң беренчеләрдән булып янган кешеләргә ярдәм җыюны оештырды, мәгълүмат та тараттык, – ди М.Юнысов.

«Йолдыз (Эчкен) авылына 1525 елда ук нигез салынган. Белүебезчә, аның тарихында мондый янгынның беркайчан да булганы юк. Йолдыз – Курган өлкәсендәге иң бай, иң зур татар авыл иде. Ул Екатеринбург, Төмән, Курган юлларының нәкъ уртасында утыра. Гомер-гомергә анда тырыш кешеләр торды, бай, төзек йортларда яшәде.

Йолдыз авылы мәктәбе укытучысы, мәктәп автобусы йөртүчесе Рауш Галиев авыл халкын янгыннан эвакуацияләргә ярдәм итә. Авылдашларын куркынычсыз урынга илтеп кайтып кергәндә алар яшәгән урам, шул исәптән үзенең дә йорт-җире, каралты-курасы җир белән тигезләнгән була инде.

«Авылыбыз, йортыбыз янды… 55 ел торган йортыбыз. Әле ярый, үзебез, балаларыбыз исән-сау калдык. 83 яшьлек әниебез әлегә күрше авылдагы бер ерак туганыбызда. Абыем да өйсез, мин дә урамда. Хәтта әниебезне алып кайтыр урыныбыз да юк. Беребезнең генә йорты торып калган булса да, барыбыз да шунда сыеныр идек. Кая яшәрбез икән, белмим. Мал-туар, кош-кортның берсе дә калмады. Әлегә мәктәптә яшәячәкбез. Без – тормыш иптәшем белән икебез дә укытучылар. Балаларны бик матурлап Җиңү бәйрәменә әзерләгән идек. Укучыларым белән хәрби җыеннарга барырга ниятләп тордык. Хәзер менә мәктәп вакытлыча яшәү урыныбызга әйләнде», – дип сөйләде Рауш Галиев.

Эчкен-Йолдыз – танылган җырчы Ярамир Низаметдиновның да туып-үскән авылы. Авылдашлары, янгын сүндерүчеләр тырышлыгы белән аның туган нигезе, әти-әнисе исән-сау калган. Тик Ярамир авыл халкы өчен бик борчыла.

«Кичәдән бирле дусларым янгынның видеоларын җибәрә. Шушы хәлләрне видео аша күреп тәннәрем чымырдый, үзеннән-үзе күз яшьләрем ага. Әле бүген шушы йөрәктәге таш белән спектакльдә уйныйсым бар. Еракта булып, шәхсән берничек тә ярдәм итә алмавым аеруча кыен… Авылымны бик яратам. Сайтлар аша ярдәм җыю турында мәгълүмат таратырга, кулымнан килгән кадәр акчалата да ярдәм итәргә тырышырмын. Шулай ук отпуск вакытында, Санкт-Петербургта булса да, хәйрия концертлары ясарга ниятем бар.

Әни ягыннан ерак туганым шушы янгында һәлак булды. Аның аяклары авырта иде. Янгын башланганны күреп, качып котыла алмаячагын аңлагандыр инде, базга төшеп яшеренгән һәм йорты янганда тончыгып үлгән… Күз алдына китерүе дә авыр бит боларны. Әнисенең кайда булганын белмим, ул өлкән яшьтә инде. Үләр алдыннан әнисенә шалтыратып: «Һава җитми, сулый алмыйм», – дип әйтергә өлгергән.

Авылларның яклаучысыз булуына йөрәк әрни. Әгәр дә бу фаҗига авылларыбызның гөрләп яшәп яткан вакытында булса, бәлки Йолдызны коткарып та калып булыр иде. Мин мәктәпне тәмамлаган 2005 елда авылда әле ике мең кеше яши иде. Шуның кадәр халык янгын сүндерергә күтәрелсә? Ә хәзер авылда калган кешеләрнең күбесе өлкән яшьтә. Шул килеш тә авылның үзәге булган мәчет, мәктәп, мәдәният йортын саклап кала алганнар бит. Мин аларның һәрберсенә чиксез рәхмәтле. Видеолардан карыйбыз, чиләкләр белән су ташып сүндерәләр янгынны…

Аллаһка шөкер, авылыбызда халык тату, бердәм. Төбәктәге башка татар авыллары кешеләре дә безнең кайгыга битараф калмаган. Бүгенге көндә зур йөк машиналары белән гуманитар ярдәм китерәләр. Шуларны күреп күңелем җылына. Бөтен кеше моның коточкыч зур кайгы икәнен аңлый. Андый авыр чакларда татарлар бер-берсен ташламый. Әле Әлмән авылыннан Әнвәр абый шалтыратты: «Без татарлар бер-беребезгә ярдәм итәргә тиеш. Болай да рус өлкәсендә ничә генә татар авылы калды, алар алга таба яшәргә тиеш», – ди.

Чыннан да, бу йортсыз калган аерым кешеләр фаҗигасе түгел, бу әле милли фаҗига дә. Әгәр дә татар авыллары бетсә, безнең мәдәниятебез дә, татар сәнгатебез дә, телебез дә бетәчәк. Урамда калган кешеләрнең йортлары торгызылмаса, ярдәм күрсәтелмәсә, алар рус авылларына, шәһәрләргә күченәчәк. Анда башка милләтләр белән гаилә корырлар. Бу бик зур проблема», – дип сөйләде ул.

Мессенджерларда авылның имам-хатыйбы Әхмәдулла хәзрәт Хәбибуллин яздырган видео таралган иде. Дин әһеле анда янгын җир белән тигезләгән авылны күрсәтеп: «Аллаһ Тәгалә безгә җәза бирә. Динне дә, телне дә онытабыз. Халыклар бозылды. Шуңа Аллаһ Тәгалә безгә сабак бирергә уйлаган», – дип сөйли.

«Искиткеч ямьле иде авылыбыз. Төштән соң 16.00 сәгатьләрдә чыккан янгын кыска вакыт эчендә юк итте аны. Өслән килгән янгыннан бернәрсәне коткарып калу да мөмкин түгел икән. Үземнең дә, кызымның да, барлык якын туганнарымның да хуҗалыклары янып бетте. Мин фермерлык белән шөгыльләнәм. Бөтен чәчүлек материалларын саклаган складлар да, сарайлар да, бернәрсә дә калмады. Аллаһ Тәгалә рәхмәте белән мәчеткә җитәрәк янгын туктады. Мәчетебез исән калды», – диде ул.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Марс Тукаев фикеренчә, Курган өлкәсенең Эчкен (Йолдыз) авылындагы янгын – татар халкы өчен зур югалту.

«Эчкенне Курган төбәгенең татар башкаласы дип тә атыйлар. Ул иң зур татар авылларының берсе, тарихи авыл. Ул сөйләм ягыннан да үзенчәлекле. Заманында аңа Себер ханлыгы авылларыннан да, казанлылар да күчеп утырган. Тарихи, милли үзәк», – диде М.Тукаев.

«Аллаһка шөкер, яман хәбәр таралуга, ярдәм килә башлады. Телефон тынып тормый. Удмуртиядән Фәрит абый 20 тонна чәчүлек бәрәңге бирә алам, ди. Аны илтүне хәл итәчәкбез. Шыгырданнар, Кукмаралар, Чаллылар ярдәм итәргә әзер... Бөтен әйберне торгызып та булмас, әмма аларның ялгыз түгеллекләрен күрсәннәр өчен кулыбыздан килгәнчә ярдәм итик», – ди М. Тукаев.

Бөтендөнья татар конгрессы янгында зыян күргән Эчкен татарларына ярдәм җыю штабы оештырды. Аның конгресс башкарма комитеты Данис Шакиров җитәкли.

Бөтендөнья татар конгрессында ярдәм җыю штабының кайнар элемтәсе дә оештырылган. Телефон – (843) 236-59-16 номеры аша белешеп була.

Йолдыз авылы халкына финанс ярдәмен җыюда төп җаваплы кеше итеп «Урал арты татарлары» җәмгыяте рәисенең урынбасары Алена Ковригина билгеләнгән.

Гөлназ ХӘБИБУЛЛИНА
intertat.tatar

«1881 елның 16 маенда Олуг Манчыл авылында ут казасы булып, бөтен авыл диярлек (160 йорт) янды. Бу вакытта Нигъмәтулла хаҗи хаҗ сәфәрендә булып, янып торган ут өстенә кайтып төште. Ошбу вакыт Нигъмәтулла хаҗи үзенең кардәшләре Рәхмәтулла, Хәбибулла белән 30 мең сумлык агач алдылар вә бөтен авылны бер фасадта үз кесәләреннән салдылар. Фәкыйрь вә гаҗизләр өчен 175 йорт бина төзелгәне мәгълүмдер», – дип яза Риза ФӘХРЕТДИН .

Хәзер милләттәшләребез арасында Нигъмәтулла хаҗидан күпкә баерак кешеләр бер-ике түгел, дистә-йөзләгән, тик дәһшәтле янгынга дучар булган Эчкен (Йолдыз) авылы өчен алар ярдәм кулы сузармы?

Мәдәни җомга
12 май
№18, 2023

Чәчәк бәйләмнәре җәйгә дәшә

Ләйсән Исламгәрәеваның болын чәчәкләре бәйләмле картиналарына күз салгач та, тамашачылар әүвәл җете төсләргә бай, кояшлы җәйне искә төшерә!

Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы, «Ел рәссамы – 2021» бәйгесенең «Яр Чаллы. Тарих һәм хәзерге заман» номинациясендә җиңү яулаган Ләйсән үзе дә Чаллы каласында туган. Гаилә сәнгать белән бәйле түгел: әнисе Глүзә «КамАЗ»да эшләгән, әтисе Ирек юллар салган. Ләйсән дә сәнгать мәктәбенә дә йөрмәгән, йөзү белән шөгыльләнгән, спорт ярышларында актив катнашкан. VIII сыйныфтан соң педагогика училищесына укырга кергән. 6 ел башлангыч сыйныф укытучысы булып эшләгән һәм шул ук вакытта читтән торып Чаллы дәүләт педагогика институтының педагогика факультетын тәмамлаган. «Мәктәптә укытуымны дәвам иткән дә булыр идем, әмма ул елларда укытучыларның хезмәт хакы бик аз иде, шуңа күрә башка өлкәдә хезмәт куя башладым. Гаилә кордым, ирем белән өч бала да үстердек, улларыбыз инде зурлар, алар машина төзү өлкәсен үз итте, кызыбыз әлегә мәктәптә укый. Без ятимнәр йортыннан 5 яшьлек кыз бала алган идек, ул да хәзер мәктәп укучысы.

Гомер агышы үзгәрә, минем өчен дә шундый вакыт килеп җитте, рухи халәтем үзгәрде, – ди иҗатчы. – Яхшы хезмәт хакы түләнә торган эшемнән үз теләгем белән киттем, тормыш мәшәкатьләре дә арта төште, әмма күңелем шулчак ниндидер яңалыкка омтылды. Рәсем ясый башлыйсым, җаным тарткан өлкәдә генә буласым килде. Рәссамлыкка мин 40 яшемдә килдем.

2015 елда педагогика институтының квалификация күтәрү курсларын тәмамлап, сәнгать укытучысы дипломын алдым. Ике балалар бакчасында сәнгать түгәрәкләрен алып бара башладым. Ләкин миңа бу вазыйфалар гына аз булып тоелды. Шул ук 2015 елны яңашәдәге 1 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбенә кердем дә: «Биредә олыларга да белем бирелмиме?» – дип сорадым. Ни гаҗәп, нәкъ шул айда рәссам-мөгаллим Мәдияр Хаҗиев шушы мәктәптә олылар өчен дәресләр башлаячак икән. Ул минем иҗат потенциалымны, тырышлыгымны күреп, киңәшләр бирде, осталыгымны камилләштерде, мин аңа бик рәхмәтле! Аннары Мәдияр Шәрип улы Чаллы Рәссамнар берлеге каршындагы иҗат студиясендә эшли башлады. Мин дә шул студиядә иҗат иттем.

Беренче шәхси күргәзмәмне 2017 елда ачкан идем, Г.М.Хәкимова исемендәге картина галереясында яңа гына тәмамланган «Гади бәхет» дип аталган шәхси күргәзмәм – инде бишенчесе. Бернечә картинам шушы галереябызда саклана, ә берникадәре – шәхси тупланмаларда.

Кызыбыз Римма балалар сынлы сәнгать мәктәбенә йөри һәм рәсемнәрен күбесенчә заманча программалар кулланып ясый. Мин төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләрдә, бәйгеләрдә катнашуга да өстенлек бирәм, осталык дәресләрен теләп үткәрәм, Чистайда узган өч арт-симпозиумда да катнаштым. «Спас ярминкәсе»н дә үз итәм. Андагы осталарның эшләре, милли киемле халык белән танышу күңелгә илһам өсти».

«Күргәзмәләремне ачканда тантанага килүчеләр өчен арт-лотерея уздырмыйча калмыйм! Март аенда ачылган күргәзмәмдә дә шундый лотерея оештырып, алты тамашачыга картиналарымны бүләк иттем, – ди Ләйсән Ирек кызы. – Чаллыбыздагы галерея рәссамнарның һөнәри осталыкларын, яңа алымнарын һәм үзенчәлекле иҗади фикерләүләрен ассызыклар өчен, күргәзмәләрне даими рәвештә үткәрә, шуңа күрә мондагы бар иҗатчыларның яңа әсәрләре белән танышып барабыз!»

Л.Исламгәрәева киндерләрендә Яр Чаллыга багышланган эшләреннән кала, Алабуга күренешләре сурәтләнгәннәре дә байтак. Аның хезмәтләрендә Мөслим районы табигате дә чагылыш тапкан. «Әнием Уразмәт авылыннан иде. Балачактагы иң бәхетле көннәремне Мөслим районының Октябрь авылында, әбием Хәбибҗамал янәшәсендә, туганнарым белән аралашып үткәрдем! Хәзер дә анда кайткалыйбыз. Әниемнең туган яклары – күңелем түрендә, – дип аңлатты рәссам ханым. – Болардан кала, хатын-кызлар иҗатына хас тагын бер темам бар әле – чәчәк бәйләмнәре ясарга яратам! Аларның гадиләрен, кырда үскәннәрен дә, купшыларын, бакчадагыларын да... Ә менә алдагы көннәрдәге милли гореф-гадәтле атмосфера тоемланган, катлаулы композицияле картиналарымны татар бәйрәмнәре белән бәйләргә телим!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 12.05.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2617

16+